**Г.Р. ГАЛИУЛЛИНА, Э.Н. ДЕНМӨХӘММӘТОВА,**
**Г.Р. МӨГЪТӘСИМОВА, К.С. ФӘТХУЛЛОВА**

# ТУГАН (ТАТАР) ТЕЛДӘН
# ДӘҮЛӘТ ЙОМГАКЛАУ АТТЕСТАЦИЯСЕНӘ ӘЗЕРЛӘНҮ ӨЧЕН
# КУЛЛАНМА

**9 СЫЙНЫФ**

**(81, 82, 83 нче кодлар)**

**КАЗАН – 2023**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ**

**Галиуллина Г.Р., Денмөхәммәтова Э.Н., Мөгътәсимова Г.Р., Фәтхуллова К.С. Туган (татар) телдән дәүләт йомгаклау аттестациясенә әзерләнү өчен кулланма. 9 нчы сыйныф**. – Казан: Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгы, 2023. – 228 б.

Кулланма 9 нчы сыйныф укучыларына туган (татар) телдән дәүләт йомгаклау имтиханына әзерләнергә ярдәм итү максатыннан төзелде. Кулланмада 81, 82, 83 нче кодлар буенча биремнәр, биремнәрне бәяләү критерийлары һәм биремнәрнең җаваплары урын ала. Һәр кодка 10 вариант бирем тәкъдим ителә. Биремнәрнең эчтәлеге Татарстан Ресрубликасы мәгариф һәм фән министрлыгы сайтында урнаштырылган кодификатор һәм спецификациягә туры килә.

# 81 НЧЕ КОД БУЕНЧА БИРЕМНӘР

## Туган телдә белем бирү оешмалары укучылары өчен 2023 нче елда туган (татар) телдән дәүләт йомгаклау аттестациясе уздыру МАТЕРИАЛЛАРЫ

### 1 нче вариант
### Эш үтәү өчен күрсәтмә

Татар телендә гомуми белем бирү оешмаларының 9 нчы сыйныфын тәмамлаучы укучылар өчен, туган (татар) телдән дәүләт йомгаклау аттестациясенә 3 сәгать 55 минут (235 минут) вакыт бирелә. Биремнәр 3 бүлектән тора.

**Беренче бүлек** 1 биремнән тора. Анда 2 тапкыр **тыңланган** текстның кыскача эчтәлеге (изложение) языла. Бирем 2 нче номерлы җавап бланкында эшләнә.

**Икенче бүлек** 7 биремнән тора (2-8 биремнәр). Биредә сүз, җөмлә, текстка төрле типтагы анализ күзаллана.

2-8 нче биремнәрнең җаваплары сүз яки цифрлар белән бирелә. Аларны 1 нче номерлы җавап бланкына язарга кирәк.

**Өченче бүлектәге** биремнәр укучылар 2 нче бүлектә укыган текст нигезендә башкарыла. Эшли башлаганчы, тәкъдим ителгән (9.1 һәм 9.2) биремнәрнең берсен сайларга һәм үз фикереңне дәлилләп, эзлекле рәвештә киңәйтелгән җавап бирү кирәк. Бирем 2 нче номерлы җавап бланкында эшләнә.

Биремнәрне үтәгәндә, орфографик сүзлекләрдән файдаланырга рөхсәт ителә.

Биремнәрне эшләгәндә, караламадан файдаланырга мөмкин, әмма андагы язулар тест эшенә билге куйганда исәпкә алынмый.

Биремнәрне тәкъдим ителгән эзлеклелектә эшләргә киңәш ителә. Җавап бирергә авырсынган бирем очраса, аны калдырып, башкаларын эшли торырга мөмкин. Вакыт кала икән, аларны яңадан уйлап, эшләп карарга мөмкинлек туа.

Үтәлгән биремнәр өчен куелган баллар бергә кушыла. Мөмкин кадәр күбрәк биремгә дөрес җавап биреп, югарырак балл җыярга тырышыгыз.

Эшне тәмамлагач, һәр җавапның 1 нче һәм 2 нче номерлы бланкларга дөрес номер белән куелганлыгын тикшерергә онытмагыз.

## I бүлек

***Текстны тыңлагыз һәм 1 нче биремне 2 нче номерлы җаваплар бланкында эшләгез. Башта биремнең номерын, аннары изложение текстын языгыз.***

**1** Текстны тыңлагыз һәм кыска изложение языгыз.

Текстны тыңлагач, микротемаларны билгеләгез.

Тулы текстның һәм андагы микротемаларның төп эчтәлеген бирергә кирәклеген истә тотып эшләгез.

Изложениенең күләме 70 сүздән ким булмаска тиеш.

Изложениене чиста һәм танырлык итеп языгыз.

## II бүлек

***2 – 8 нче биремнәрнең җавабы сүз яки цифрлар булырга мөмкин. Башта җавапны текстта күрсәтегез, соңыннан 1 нче номерлы бланкка <u>буш ара калдырмыйча, тыныш билгеләрсез, башка өстәмә символларсыз</u> күчереп алыгыз. Һәр хәрефне һәм санны, бланктагы үрнәктә күрсәтелгәнчә, аерым шакмакка языгыз.***

**2** Текстны укыгыз.

1) Мин кыш көннәрендә төнлә яланаяк, күлмәкчән килеш тышка чыгам да бераздан, өйгә кермәкче булып, ишеккә киләм икән. 2) Кыш көне авыл ызбаларының ишекләрен ачу балага түгел, шактый үсмер кешеләргә дә мәшәкать вә көч булганлыктан, мин, ишекне ача алмыйча, ишек төбендә көтеп торам икән.... 3) Анам бервакыт мине үзе янына Саснага алып киткән. 4) Ул авылга ничек барып җиткәнмен, ни рәвешле бардым, мине кемнәр каршылады – аларын белмим. (*Г. Тукай*)

Җөмләләрнең **оештыручы үзәкләре (грамматик нигезләре, баш кисәкләре)** дөрес күрсәтелгән очракны билгеләгез. Җавап номерын языгыз.

1) ишеккә киләм икән (1 нче җөмлә)
2) авыл ызбаларының (2 нче җөмлә)
3) мин көтеп торам икән (2 нче җөмлә)
4) Саснага алып киткән (3 нче җөмлә)
5) аларын белмим (4 нче җөмлә)

Җавап: ________________ .

**3** Текстны укыгыз.

**Тел арты ассимиляциясе күзәтелгән** сүз кулланылган җөмләне табыгыз. Җавап номерын языгыз.

1) Кичә Әлфия шәһәрдән әбисенә кунакка кайтты. 2)Иртән әбисе аны каймак салынган тәмле катык белән сыйлады. 3) Аннары Әлфия, бакчага кереп, кура җиләге, карлыган ашады. 4) Шуннан соң әбисе аңа чиләк бирде дә:
– Кызым, бар әле, казларга, тавыкларга җим болгатырга алабута башы җыеп кайт, – диде. (*Ф. Садриев*)

Җавап:_____ _ ____________ ________________ .

**4** Текстны укыгыз.
**Сызык** куелырга тиешле җөмләләрне табыгыз. Җавап номерларын языгыз.

1) Урман аланчыкларында юл буйларында кисентеләрдә очлы башлы кәҗә гөмбәләре җир астыннан калкып чыкты. 2) Кәҗә гөмбәсе үзенчәлекле хуш исле гөмбә. 3) Ул көнбатыш гурманнарның иң яраткан азыгы. 4) Исегездә тотыгыз бу гөмбәләрнең агуын бетерү өчен аларны ун-унбиш минут кайнап торган суда тотарга кирәк. (*Г. Хәсәнов*)

Җавап: _______.

**5** Текстны укыгыз.
**Сыйфат фигыльне** табып языгыз.

1) Дөньяда спорт һәм көч сынашу төрләре бик күп. 2) Аларның төгәл санын белүче дә юк. 3) Шулай да бүген кайсы спорт төре иң популяр санала? 4) Әйтә алмыйсызмы? 5) Дөньяда бүгенге көндә иң популяр спорт – футбол. 6) Аны кайда гына уйнамыйлар: салкын котыпта да, Африканың эссе чүлләрендә дә. (*Вакытлы матбугаттан*)

Җавап: ________________ .

***Текстны укыгыз һәм 6-9 нчы биремнәрне үтәгез.***

1) Нәсимнең талдан бөгеп ясалган бик шәп җәясе бар иде. 2) Ай-һай, шәп иде җәя! 3) Нечкә кыл җебен зыңгылдатып тартып җибәргән чакларда, тыкрык малайларының күзләре дүрт була иде.

4) Беркөнне шул җәя юкка чыкты. 5) Бик нык кайгырды, ут йотты Нәсим. 6) Ике көн буена җәясен эзләде. 7) Баскыч асларын, кар базын, кыяр түтәлләрен актарды. 8) Юк, җәя табылмады.

9) Нәсим, аптырауның соңгы чигенә чыккач, чормага менеп китте. 10) Тик чормада бабасының киез эшләпәсе бар – җәя юк. 11) Мич торбасы янында иске бишек аунап ята – җәя... ә?.. 12) Тукта, тукта! 13) Әллә күзенә күренәме Нәсимнең? 14) Бишек эчендә авызы чүпрәк белән ябылган балчык чүлмәк утыра түгелме соң? 15) Кайдан килгән ул? 16) Кем куйган? 17) Үткән атнада менгәндә генә, бишектә этисенең иске киез итегеннән башка әйбер юк иде бит.

18) Нәсим, аптырап торды-торды да, чүлмәк янына чүгәләп утырды. 19) Чирткәләп алды. 20) Кызык, эчендә ни икән, ә? 21) Беләсе иде. 22) Нәсим чүлмәкнең авызын чиште. 23) Чиште дә өнсез-авазсыз булды. 24) Карау белән һушны ала торган сап-сары кәрәзле бал! 25) Нәсимнең авызыннан сулар килде. 26) Нишләргә соң, ә? 27) Әллә тәмен генә белеп караргамы? 28) Тәм белүдән кемгә ни зыян. 29) Бөтенләй ашап бетерми лә Нәсим. 30) Ул як-ягына ялт-йолт каранып алды. 31) Аннан тиз генә балга бармаган тыкты. 32) Тәмле-е! 33) Чүт телен йотмады... 34) Әмма.... әмма нәрсә соң ул бер бармак! 35) Кече телгә дә йокмады. 36) Нәсим, аны-моны уйлап тормады, бөтен дөньясын онытып, балны өч бармак белән сыптыра башлады. 37) Сипкел бит Фәхрүш әйтмешли, ярылганчы бал ашады Нәсим. 38) Ашавын ашады. 39) Ләкин соңга таба бал да әче була башлады, Нәсимнең дә йөрәгенә шом төште. 40) Барыбер сизеләчәк. 41) Әнисе сизәчәк инде аны. 42) Хәзер нишләргә? 43) Эх, шунда ашамаган гына булса! 44) Нәфесенә баш була алмады. 45) Егет эше түгел инде бу. 46) Инде эш үткән шул. 47) Хәйләсен табарга кирәк.

48) Нәсим каш җыерып, никадәр генә уйланса да, үч иткәндәй, бер хәйлә дә табылмады. 49) Әһә, әгәр болай итсә... 50) Аның әнисе курыкмаска, үз хатаңны таный белергә кирәк, ди бит. 51) Әгәр балны ашап бетергәч, бөртек тә яшерми, бөтенесен сөйләп бирсә? 52) Әнисе ни дияр иде икән? 53) Әгәр эш шома гына үтсә, әнисе гафу итсә, Гөлсәрия белән Ирек алдында Нәсимнең дәрәҗәсе бермә-бер күтәрелә инде...

(Газиз Мөхәммәтшиннан*)

**Газиз Мөхәммәтшин** (1932 - 1972) – татар язучысы, драматург.

**6** **Текстның эчтәлегенә туры** килгән җөмләне күрсәтегез. Җавап номерын языгыз.

1) Нәсим бал ярата.
2) Нәсимнең җәясе белән мактанасы килде.
3) Нәсим чормадан җәясен тапты.
4) Нәсимнең туганнары алдында мактанасы килде.
5) Рөхсәтсез, качып эшләгән начар гамәл егетлек булмый.

Җавап: _______________ .

**7** **Фразеологик әйтелмә** кулланылган җөмләне күрсәтегез. Җавап номерын языгыз.

1) Бик нык кайгырды, ут йотты Нәсим.
2) Тик чормада бабасының киез эшләпәсе бар – җәя юк.
3) Кызык, эчендә ни икән, ә?
4) Эх, шунда ашамаган гына булса!
5) Хәйләсен табарга кирәк.

Җавап: ________________ .

**8** 1-8 нче җөмләләрдән ***яхшы*** сүзенең синонимын табып, күчереп языгыз.

Җавап: __________ .

***2-8 нче биремнәрнең җавапларын, тестны үтәү өчен күрсәтмәдә әйтелгән тәртиптә, 1 нче номерлы бланкка күчереп язарга һәм җавапның бирем номеры күрсәтелгән юлга язылуын тикшерергә онытмагыз.***

## III бүлек

***2 нче бүлектә укылган текстны файдаланып, 9.1 яки 9.2 нче биремнәрнең бары тик берсен генә сайлап алып, 2 нче номерлы бланкта биремне үтәгез. Яза башлар алдыннан сайланган биремнең номерын күрсәтегез.***

**9.1** **“Анның әнисе курыкмаска, үз хатаңны таный белергә кирәк, ди бит.”** җөмләсендә әйтелгән фикерне ничек аңлыйсыз? Шулар турында языгыз. Фикерегезне раслау өчен, укылган тексттан **2 мисал** китерегез.

Файдаланган җөмләләрнең номерларын языгыз яки тексттан цитата китерегез.

Сочинениенең күләме **70 сүздән** дә ким булмаска тиеш.

Укылган текстка таянып язылмаган эшкә билге куелмый.

Бирелгән текстны күчереп яисә анның эчтәлеген аңлатмаларсыз язган өчен ноль балл куела.

Сочинениене чиста һәм таныrлык итеп языгыз.

**9.2** **Нәфескә баш булу** әйтеменең мәгънәсен ничек аңлыйсыз? “**Кырын эш кырык елдан соң да беленә**” темасына сочинение языгыз. Фикерегезне языгыз. Раслау өчен, укылган тексттан **1 мисал**, үзегезнең тормыш тәҗрибәсеннән **1 мисал** китерегез.

Сочинениенең күләме **70 сүздән** дә ким булмаска тиеш.

Укылган текстка таянып язылмаган эшкә билге куелмый.

Бирелгән текстны күчереп яисә аның эчтәлеген аңлатмаларсыз язган өчен ноль балл куела.

Сочинениене чиста һәм танырлык итеп языгыз.

## I бүлек

| ***Тыңлау өчен текст*** |
|---|

### Матурлык дөньясы

1) Болын чишмәсе аны, гадәттәгечә тын гына, тыныч кына каршы алды. 2) Көянтә-чиләген куюга, Нәҗия су алырга ашыкмады, яшел чирәмгә тезләнеп, тыныч торган су өстенә иелде. 3) Тешләре камашканчы, сусавы басылганчы, тәмләп салкын су эчте, бит-кулларын юды.

4) Яраткан бер гадәте бар Нәҗиянең. 5) Яз җиттеме, чишмәгә килсә, тал песиләре җыеп кайта. 6) Чәчәк вакытында бәллүр вазалары шомырт, балан чәчәге, болын чәчәкләреннән бушап тормый. 7) Көзгә кергәч, кочагы белән өрәңгенең ут кебек кызыл, лимон кебек сары яфракларын җыя. 8) Бүген дә шомырт чәчәкләре алып кайту өчен килгән иде ул. 9) Чишмә янында үскән ялгыз шомырт башына да бик тиз менеп җитте Нәҗия.

10) Менә кайда икән  матурлык дөньясы! 11) Табигать үзенең бар хәзинәсен бергә җыйган да, туйганчы карап сөенсен дип, бөтен матурлыгы белән аны кызның алдына китереп салган. 12) Тау астындагы шомырт куаклары ак күбектәй күпереп торган тәлгәшләргә күмелгән. 13) Болын ягындагы өем-өем таллардан күзне алырлык түгел. 14) Мин монда барыгыздан да өлкән, бөтенегездән дә күбрәк беләм, тыңласагыз, бик борынгы серләрне дә сөйләргә кодрәтем җитә, дигән кебек, салмак кына агып яткан Идел – үзе бер хикәя.

*(Ләбибә Ихсановадан)* ***(175 сүз)***

### 1 вариант җаваплары

| **Кыска изложение өчен текст турында белешмә** | |
|---|---|
| **Абзац номеры** | **Микротемалар (мәгънәви кисәкләр)** |
| 1 | Нәҗия чишмәгә килде. |
| 2 | Нәҗия елның төрле фасылында чишмәгә килә. |
| 3 | Табигать матурлыгына карап, сокланып туярлык түгел. |

## II бүлек
## 2 – 8 нче биремнәр

| **Биремнәр** | **Җаваплар** |
|---|---|
| 2 | 3 |
| 3 | 2 |
| 4 | 2, 3 |
| 5 | белүче |
| 6 | 5 |
| 7 | 1 |
| 8 | шәп |

## 2 нче вариант

### I бүлек

***Текстны тыңлагыз һәм 1 нче биремне 2 нче номерлы җаваплар бланкында эшләгез. Башта биремнең номерын, аннары изложение текстын языгыз.***

**1** Текстны тыңлагыз һәм кыска изложение языгыз.

Текстны тыңлагач, микротемаларны билгеләгез.

Тулы текстның һәм андагы микротемаларның төп эчтәлеген бирергә кирәклеген истә тотып эшләгез.

Изложениенең күләме 70 сүздән ким булмаска тиеш.

Изложениене чиста һәм таныրлык итеп языгыз.

### II бүлек

***2 – 8 нче биремнәрнең җавабы сүз яки цифрлар булырга мөмкин. Башта җавапны текстта күрсәтегез, соңыннан 1 нче номерлы бланкка <u>буш ара калдырмыйча, тыныш билгеләрсез, башка өстәмә символларсыз</u> күчереп алыгыз. Һәр хәрефне һәм санны, бланктагы үрнәктә күрсәтелгәнчә, аерым шакмакка языгыз.***

**2** Текстны укыгыз.

1) Апрель безгә бөек Тукайны бүләк итте. 2) Тукай исә безнең рухыбызны кузгатты, зиһенебезне баетты. 3) Шагыйрь үзе үлсә дә, еллар узса да, Тукай иҗаты һич тә искермәде, һич тә үзгәрмәде, ул һаман да безнең белән. 4) Бу нәрсә белән аңлатыла соң? 5) Чөнки Тукайның кодрәтле таланты кешенең табигате, оригиналь ысул-чаралар һәм стиль ярдәмендә гәүдәләндереп калдырды. *(Хатыйп Миңнегулов)*

Җөмләләрдә **аергыч** дөрес күрсәтелгән очракны билгеләгез. Җавап номерын языгыз.

6) безгә бүләк итте (1 нче җөмлә)
7) зиһенебезне баетты (2 нче җөмлә)
8) ул безнең белән (3 нче җөмлә)
9) нәрсә белән (4 нче җөмлә)
10) кодрәтле таланты (5 нче җөмлә)

Җавап: ________________ .

**3** Текстны укыгыз.

**Авазлар саны хәрефләр санынннан артыграк булган** сүз кулланылган җөмләне табыгыз. Җавап номерын языгыз.

| |
|---|
| 1) Минем әти авылда тракторчы булып эшли, акчаны көрәп ала. 2) Чоланыбызда он, шикәр, ярма, макарон ише азык-төлекләр капчыгы-тартмасы белән тора. 3) Чиләк кадәр калай савытларда кайнатмалар утыра, чүмеч белән ашасаң да, сүз әйтмиләр. (*Рәмзия Габделхакова)* |

Җавап: ________________ .

**4** Текстны укыгыз.

**Өтерләр** куелырга тиешле җөмләләрне табыгыз. Җавап номерларын языгыз.

| |
|---|
| 1) Гомер мизгелләрен болытсыз явымсыз гына узасы иде. 2) Болытлар көтеп алган җәйге яңгыр төсле хушландырып салават күперенең барлык төсләрен күңелгә салып тиз генә таралсын иде! 3) Яшәвебезнең мәгънәсен аңлар өчен генә җибәрелгән яшеннәргә дә түзәргә мөмкин. 4) Өмет кояшын гына кара болытлар капламасын. |

Җавап: ________________ .

**5** Текстны укыгыз.

**Ясалма фигыльне** табып языгыз.

| |
|---|
| Кешеләр җирдә яңа матурлык тудыру өчен эзләнәләр, максатларына ирешү өчен күпме көч куялар. Ә аяк астында ярдәм сорап яткан чиксез бай хәзинәнең йөзенә басып йөриләр. Менә сине дә бик күп кешеләр көтә бит, чишмә! Син булмагач, бу дөньяда нинди зур сихри гүзәллек җитми. |

Җавап: ________________ .

***Текстны укыгыз һәм 6-9 нчы биремнәрне үтәгез.***

1) Яшәгән, ди, бер колын. 2) Ул Йолдызкай атлы икән, ә әнкәсенең исеме Чуаралма булган.

3) Көннәрдән бер көнне Йолдызкайның әнисе Чуаралманың туган көне килеп җиткән. 4) Туган көн җиткәч, котларга кирәк бит инде. 5) Ә котлар өчен бүләк кирәк. 6) Йолдызкай, әнкәсен туган көне белән котларга нинди бүләк алып кайтыйм икән дип, бик уйланган, ди. 7) Озак кына уйлана торгач, ул: «Чәчәктән дә яхшысы булмас», – дигән.

8) Йолдызкайның әнкәсе Чуаралма бигрәк тә шәмәхә төсендәге кыңгырау чәчәкләрен ярата икән. 9) Муенындагы җиз кыңгыравы да, яңгырларда шәмәхәләнеп, шул чәчәккә охшап тора, ди. 10) Ул аны матурлык өчен генә түгел, ә бәлки колынкае адашканда шул кыңгырау тавышына килсен дип асып йөрткән.

11) Шулай итеп, Йолдызкай үз әнкәсенең туган көненә бүләккә атап, кыңгырау чәчәкләре җыярга чыгып киткән.

12) Кыңгырау чәчәкләре болында үскән. 13) Болын исә елганың аргы ягында, ди. 14) Йолдызкай әллә кайдагы күперне эзләп йөрмәгән. 15) Елганы йөзеп кенә чыккан да бик күп итеп фирүзә, шәмәхә кыңгырау чәчәкләрен җыйган. 16) Җыйган чәчәкләре колынның кочагына көчкә-көчкә сыйган инде менә.

17) Йолдызкай үз өенә кайтырга чыккан. 18) Кочагындагы кыңгырау чәчәкләре аның атлаган көенә чең дә чең, челтер дә челтер килеп барган.

19) Кайта торгач, ул әлеге дә баягы елга ярына килеп җиткән. 20) Йолдызкайның үзе җыйган чәчәкләрне әнисенә тизрәк бүләк итәсе килгән. 21) Шуңа күрә ул күперне эзләп йөрмәгән, елганы туп-туры йөзеп чыгарга уйлаган. 22) Чәчәкләрне башына куеп, суга кергән дә йөзеп киткән. 23) Йөзә торгач, арый башлаган. 24) Арый башлагач, бата башлаган, бата башлагач, кычкыра башлаган.

25) Шул чакны әлеге су буена зәңгәр канатлы бер Күбәләк килеп чыккан. 26) Ул, гадәтенчә, елганың аргы ягында үскән кыңгырау чәчәкләргә кунып, баллы су эчәргә теләгән булган. 27) Караса, суда бер кочак кыңгырау чәчәкләре бәйләме йөзеп йөри икән. 28) Күбәләк озын-озак уйлап тормаган, канатларын киң иттереп җәеп җибәргән дә, әлеге чәчәкләрне күтәреп алып, югарыга күтәрелгән. 29) Шулай итеп зәңгәр канатлы Күбәләк шәмәхә кыңгырау чәчәкләрен яр буена чыгарып куйган. 30) Ә Йолдызкай шул чәчәкләргә ябышып тотынган булган икән.

31) - Рәхмәт яусын сиңа, зәңгәр канатлы Күбәләк! 32) Син коткарып калмасаң, бүген минем әнием туган көнсез кала иде бит, - дигән колынкай. 33) Ул бер чәчәкне Күбәләкнең чәченә кыстырган да, кушаяклап чабып, кош тоткандай, өйләренә кайтып киткән.

*(Ә. Гаффардан *)*

**Әхәт Гаффар* (1948-2021) – танылган язучы, драматург.

**6** **Текстның эчтәлегенә туры** килгән җөмләне күрсәтегез. Җавап номерын языгыз.

1) Тиздән Йолдызкайның туган көне җитә.
2) Йолдызкай әнисенең туган көннә чәчәк җыярга киткән.
3) Йолдызкай елга ярында чәчәкләр җыя.
4) Чуаралма Йолдызкайны эзләп йөри.
5) Күбәләк елгага йөзәргә килгән.

Җавап: ________________ .

**7** **Чагыштыру** кулланылган җөмләне күрсәтегез. Җавап номерын языгыз.

1) Туган көн җиткәч, котларга кирәк бит инде.
2) Болын исә елганың аргы ягында, ди.
3) Йөзә торгач, арый башлаган.
4) Ә Йолдызкай шул чәчәкләргә ябышып тотынган булган икән.
5) Ул бер чәчәкне Күбәләкнең чәченә кыстырган да, кушаяклап чабып, кош тоткандай, өйләренә кайтып киткән.

Җавап: ________________ .

**8** 1-44 нче җөмләләрдән ***исемле*** сүзенең синонимын табып, күчереп языгыз.

Җавап: ____________ .

***2-8 нче биремнәрнең җавапларын, тестны үтәү өчен күрсәтмәдә әйтелгән тәртиптә, 1 нче номерлы бланкка күчереп язарга һәм җавапның бирем номеры күрсәтелгән юлга язылуын тикшерергә онытмагыз.***

## III бүлек

***2 нче бүлектә укылган текстны файдаланып, 9.1 яки 9.2 нче биремнәрнең бары тик берсен генә сайлап алып, 2 нче номерлы бланкта биремне үтәгез. Яза башлар алдыннан сайланган биремнең номерын күрсәтегез.***

**9.1** **- Рәхмәт яусын сиңа, зәңгәр канатлы Күбәләк! Син коткарып калмасаң, бүген минем әнием туган көнсез кала иде бит, - дигән колынкай. Ул бер чәчәкне Күбәләкнең чәченә кыстырган да, кушаяклап чабып, кош тоткандай, өйләренә кайтып киткән.** - җөмләләрендә әйтелгән фикерне ничек аңлыйсыз? Шулар турында языгыз. Фикерегезне раслау өчен, укылган тексттан **2 мисал** китерегез.

Файдаланган җөмләләрнең номерларын языгыз яки тексттан цитата китерегез.

Сочинениенең күләме **70 сүздән** дә ким булмаска тиеш.

Укылган текстка таянып язылмаган эшкә билге куелмый.

Бирелгән текстны күчереп яисә аның эчтәлеген аңлатмаларсыз язган өчен ноль балл куела.

Сочинениене чиста һәм таныргык итеп языгыз.

**9.2** **Әнине шатландыру** төшенчәсен ничек аңлыйсыз? “**Әниемнең туган көне**” темасына сочинение языгыз. Фикерегезне языгыз. Раслау өчен, укылган тексттан **1 мисал**, үзегезнең тормыш тәҗрибәсеннән **1 мисал** китерегез.

Сочинениенең күләме **70 сүздән** дә ким булмаска тиеш.

Укылган текстка таянып язылмаган эшкә билге куелмый.

Бирелгән текстны күчереп яисә аның эчтәлеген аңлатмаларсыз язган өчен ноль балл куела.

Сочинениене чиста һәм танырлык итеп языгыз.

## I бүлек

| ***Тыңлау өчен текст*** |
|---|

### Ике дус

Биологиядән “икеле” алуына һич тә үкенмәде Камил. Чөнки бу фәнне ул башкаларга караганда яхшырак белә. “Икеле” алуының сәбәбе дә көлке сыман: контроль эш дәфтәрен тапшырмаган. Эшен беренче булып төгәлләгән иде дә, янәшә партада утыручы Сәриянең биремен эшли алмаганын күреп, укытучы сизмәгәндә генә, дәфтәрен аңа сузды. Дәрес бетеп, тәнәфескә кыңгырау шылтырагач, укытучы үзе йөреп җыйды дәфтәрләрне. Минем дәфтәр Сәриядә дип әйтмәс бит инде!

Укытучы Галия Нуровна икенче көнне иртән дәфтәрләрне өләшеп чыкты да журналдан Камилнең фамилиясен эзләде.

- Шәкүров, синең эшеңә “икеле”, – диде.
- Ни өчен “икеле” соң ул, Галия Нуровна? – дип сорады Камил елмаю катыш.
- Дәфтәреңне тапшырмагансың!

Сыйныф бүлмәсендә тынлык урнашты. Мин Камилнең белгәнен дә, контроль эшен беренче булып язып бетерүен дә яхшы беләм. Без Камил белән дуслар, бер партада утырабыз.

Сәрия гафу да үтенмәде, Камил дәфтәреннән күчереп язган контроль эшенә “бишле” алды.

Мәктәптән без икебез генә кайттык. Авылга өч чакрым юл. Камил миңа табигатьтәге үсемлекләр, бөҗәкләр, кошлар, җәнлекләр дөньясы турында сөйләде. Каян барысын да истә калдыра ул!

*(Ә.Еникидән)* ***(148 сүз)***

## 2 вариант җаваплары

| **Кыска изложение өчен текст турында белешмә** | |
|---|---|
| **Абзац номеры** | **Микротемалар (мәгънәви кисәкләр)** |
| 1 | Камил контроль эш дәфтәрен Сәриягә бирде. |
| 2 | Камил биологиядән “икеле” билгесе алды. |
| 3 | Сәрия гафу үтенмәде. |

## II бүлек
## 2 – 8 нче биремнәрне тикшерү

| **Биремнәр** | **Җаваплар** |
|---|---|
| 2 | 5 |
| 3 | 2 |
| 4 | 1, 2 |
| 5 | эзләнәләр |
| 6 | 2 |
| 7 | 5 |
| 8 | атлы |

**3 нче вариант**

**I бүлек**

***Текстны тыңлагыз һәм 1 нче биремне 2 нче номерлы җаваплар бланкында эшләгез. Башта биремнең номерын, аннары изложение текстын языгыз.***

**1** Текстны тыңлагыз һәм кыска изложение языгыз.

Текстны тыңлагач, микротемаларны билгеләгез.

Тулы текстның һәм андагы микротемаларның төп эчтәлеген бирергә кирәклеген истә тотып эшләгез.

Изложениенең күләме 70 сүздән ким булмаска тиеш.

Изложениене чиста һәм таныклык итеп языгыз.

**II бүлек**

***2 – 8 нче биремнәрнең җавабы сүз яки цифрлар булырга мөмкин. Башта җавапны текстта күрсәтегез, соңыннан 1 нче номерлы бланкка буш ара калдырмыйча, тыныш билгеләрсез, башка өстәмә символларсыз күчереп алыгыз. Һәр хәрефне һәм санны, бланктагы үрнәктә күрсәтелгәнчә, аерым шакмакка языгыз.***

**2** Текстны укыгыз.

1) Әле уңга сугылган ул, әле сулга, әле алга йөгергән ул, әле артка. 2) Атлый-йөгерә торгач, эзли торгач, ярты кәрзин җиләк җыйган Таңсылу, тик җиләккә мавыгып, караңгы төшкәнен сизми калган. 3) Исенә килеп кайтырга чыкканда, төн үзенең кара җәймәсен күктән җиргә кадәр җәеп куйган булган. 4) Кыз, ятьмәгә эләккән балыктай бәргәләнгән, тәмам адашкан. 5) Тегендә чабып, монда чабып хәле беткән. *(Фәнис Яруллиннан)*

Җөмләләрнең **оештыручы үзәкләре (грамматик нигезләре, баш кисәкләрен)** дөрес күрсәтелгән очракны билгеләгез. Җавап номерын языгыз.

11) уңга сугылган (1 нче җөмлә)
12) караңгы төшкәнен сизми калган (2 нче җөмлә)
13) кара җәймәсен җәеп куйган булган (3 нче җөмлә)
14) кыз адашкан (4 нче җөмлә)
15) тегендә чабып (5 нче җөмлә)

Җавап: ________________ .

**3** Текстны укыгыз.

**Рәт гармониясе сакланмаган** сүзләр кулланылган җөмләне табыгыз. Җавап номерын языгыз.

| |
|---|
| 1) Кыш көне су асты дөньясында караңгылык, төссезлек хакимлек итә. 2) Кыш ахырларына таба балыклар, авызларын ачып, көчкә-көчкә кыймылдыйлар. 3) Һава җитми, суларга кыен аларга. 4) Боз астында һава бетеп килә, ә боз өстендә һава керердәй бер ярык, тишек тә юк. (*Николай Сладковтан*) |

Җавап: _______________ .

**4** Текстны укыгыз.

**Сызык** куелырга тиешле җөмләләрне табыгыз. Җавап номерларын языгыз.

| |
|---|
| 1) Шулай берзаман кәгазьдән ясалган Чәчкә белән хуш исле Бакча чәчкәсе сөйләшәләр икән. 2) Кәгазь чәчкә тәрәзә төбендәге бәллүр вазада ә бакча чәчкәсе тәрәзә каршында бакчада үскән ди. 3) Алар үзара бәхәсләшеп тә алалар кем яхшырак та кем матуррак?<br>4) Бакча чәчкәсе көз җиткәч орлыкларын тирә-юньгә очырган. 5) Көзге җилләр исүгә аның сабаклары, яфраклары кипкән. 6) Моны күреп Кәгазь чәчкә бик масаеп әйткән аңа:<br>- Бакча чәчкәсе синең гомерең бик кыска ә менә мин мәңгелек!<br>(*Нәкыйп Каштаннан*) |

Җавап: _______________ .

**5** Текстны укыгыз.

**Саф кушма исемне** табып языгыз.

| |
|---|
| Борын-борын заманда булган, ди, бик матур бер гөлбакча. Бу бакчага әле кеше аягы басмаган икән. Анда бик күп чәчәкләр үскән. Биредә туктаусыз сандугачлар сайраган, чәчәкләр вальс биегәннәр, аллы-гөлле асыл күбәләкләр очып йөргән. (*С. Гаффаровадан*) |

Җавап: ________________ .

| |
|---|
| ***Текстны укыгыз һәм 6-9 нчы биремнәрне үтәгез.*** |

1) Ландышлар чәчәк аткан чакта, Камил әтисе белән урманга барды. 2) Әтисе юлда ук кисәтте:

– Урман зур ул, серле ул, күңел күзе белән карасаң гына бөтен нәрсәне күрерсең, – диде.

3) Камил көлеп җибәрде:

– Кешенең күзе маңгаенда гына була. 4) Күңелнең күзе кайда булсын, шаяртасың, – диде. 5) Әтисе бәхәсләшеп тормады. 6) Әйтеп кенә куйды:

– Анысы шулаен шулай, тик күңел күзе белән карамасаң, маңгай күзе берни күрми ул. 7) Шуңа күрә борынгылар: «Маңгай күзе – ботак тишеге», – дигәннәр дә инде.

8) Урман аларны тын гына каршылады. 9) Биек-биек наратлар, каеннар тын гына утыралар. 10) Камил башын артка чөеп, өскә карады. 11) Агач башлары сизелер-сизелмәс кенә селкенәләр иде. 12) Әйтерсең лә, алар үзара ни турындадыр серләшәләр иде. 13) Алардан өстә – зәп-зәңгәр күк. 14) Урман өстенә зәңгәр чатыр корганнар диярсең. 15) Ни турында болай серләшәләр икән бу агачлар? 16) Камилнең шуны беләсе килде. 17) Ул әтисенә карады. 18) Улының соравын ишеткәч, әтисе елмаеп куйды, башыннан сыйпады, аннары туктап калды:

– Яле, икәүләп тыңлыйк. 19) Әнә, ишетәсеңме? 20) Агачлар безгә әйтәләр: «Рәхим итегез, хуш киләсез урманга, – диләр. 21) – Тик мәрхәмәтле булыгыз, агачларны сындырмагыз, чәчәкләрне йолкымагыз, үләннәрне таптамагыз. 22) Юкса, урманга зарар итәрсез».

23) Камил моңа ышанырга да, ышанмаска да белмичә тыңлап торды. 24) Никадәр тырышса да, агачларның сүзен аңлый алмады. 25) Малайның кәефе китте. 26) Әтисе улының кичерешләрен аңлый иде.

27) – Борчылма, улым, агачларның теле чынлап та юк, аларны аңлар өчен синең күңел күзең булуы кирәк, – диде.

28) Камил озак кына уйланып барды, аннары әйтеп куйды:

– Әти, агачлар кошчыкларны да, киек җәнлекләрне дә кыерсытмаска кушалардыр әле, әйе бит?

29) Аннары әтисенә охшатып баш бармагын өскә күтәрде. 30) – Чү, әйдә тагын тыңлыйк.

*(Роза Хафизовадан*)*

****Роза Хафизова*** (1929-2005) – татар балалар язучысы.

**6** **Текстның эчтәлегенә туры** килгән җөмләне күрсәтегез. Җавап номерын языгыз.

1) Камил кечкенәдән урманны ярата.
2) Язгы урман шаулап каршы ала.
3) Агачлар Камил белән сөйләшәләр.
4) Урманны сакларга кирәк.
5) Камил агач башына үрмәләде.

Җавап: ________________ .

**7** **Мәкаль** кулланылган җөмләне күрсәтегез. Җавап номерын языгыз.

1) Кешенең күзе маңгаенда гына була
2) Шуңа күрә борынгылар: «Маңгай күзе – ботак тишеге», – дигәннәр дә инде.
3) Камил башын артка чөеп, өскә карады.
4) Агачлар безгә әйтәләр: «Рәхим итегез, хуш киләсез урманга, – диләр.
5) Аннары әтисенә охшатып баш бармагын өскә күтәрде.

Җавап: ________________ .

**8** 18-22 нче җөмләләрдән ***зыян*** сүзенең синонимын табып, күчереп языгыз.

Җавап: ____________ .

***2-8 нче биремнәрнең җавапларын, тестны үтәү өчен күрсәтмәдә әйтелгән тәртиптә, 1 нче номерлы бланкка күчереп язарга һәм җавапның бирем номеры күрсәтелгән юлга язылуын тикшерергә онытмагыз.***

## III бүлек

***2 нче бүлектә укылган текстны файдаланып, 9.1 яки 9.2 нче биремнәрнең бары тик берсен генә сайлап алып, 2 нче номерлы бланкта биремне үтәгез. Яза башлар алдыннан сайланган биремнең номерын күрсәтегез.***

**9.1** **– Борчылма, улым, агачларның теле чынлап та юк, аларны аңлар өчен синең күңел күзең булуы кирәк, – диде. -** җөмләсендә әйтелгән фикерне ничек аңлыйсыз? Шулар турында языгыз. Фикерегезне раслау өчен, укылган тексттан **2 мисал** китерегез.

Файдаланган җөмләләрнең номерларын языгыз яки тексттан цитата китерегез.

Сочинениенең күләме **70 сүздән** дә ким булмаска тиеш.

Укылган текстка таянып язылмаган эшкә билге куелмый.

Бирелгән текстны күчереп яисә аның эчтәлеген аңлатмаларсыз язган өчен ноль балл куела.

Сочинениене чиста һәм танырлык итеп языгыз.

**9.2** **Урман – безнең байлыгыбыз** әйтеменең мәгънәсен ничек аңлыйсыз? **"Урман – матурлык һәм сәламәтлек чыганагы"** темасына сочинение языгыз. Фикерегезне языгыз. Раслау өчен, укылган тексттан **1 мисал**, үзегезнең тормыш тәҗрибәсеннән **1 мисал** китерегез.

Сочинениенең күләме **70 сүздән** дә ким булмаска тиеш.

Укылган текстка таянып язылмаган эшкә билге куелмый.

Бирелгән текстны күчереп яисә аның эчтәлеген аңлатмаларсыз язган өчен ноль балл куела.

Сочинениене чиста һәм танырлык итеп языгыз.

## I бүлек

| *Тыңлау өчен текст* |
|---|

### Яңа укучы

Беренче чирек тәмамланганда, классыбызга яңа укучы килде. Фәрит дип таныштырды ул үзен. Чегәннекедәй чем-кара бөдрә чәч, зур янып торган күзләр... Аны иң арткы партага утырттылар. Гадәттә, яңа килгән укучының урыны гел соңгы партада була.

— Кайсы мәктәптән? — дип сорадым мин аннан.

— Без башка шәһәрдән күченеп килдек, — диде ул.

Дәрестә Фәрит бик актив, укытучыларның һәр сүзен тыңлап, сорауларына дөрес итеп җавап та кайтара. Алдагы партада утыручылар дәрес барганда көлеп җибәргәннәр иде.

— Тыңларга комачауламагыз, — дип, шундук аларга кисәтү ясады.

Мин борылып карадым.

— Нинди кыю, беренче көнне үк үз тәртипләрен кертергә маташа! Мондый булса, эләгер әле үзенә, — дип куйдым, эчтән генә.

Физика укытучыбыз:

— Әйдә әле, Фәрит, такта янына чыгып, әлеге мәсьәләне аңлатып чишеп күрсәт, — диде.

Фәрит, кыю гына, кулына акбур алып, әлеге мәсьәләне чишеп тә куйды. Шундый аңлаешлы итеп формуланы аңлатты. Аның тулы итеп җавап бирүе, тиз фикерләве ошады миңа.

Укытучыбыз да:

— Күрәсезме, балалар, менә шулай җавап бирергә өйрәнергә кирәк сезгә дә, — дип, Фәритне мактады.

(*Дания Гайнетдиновадан*) ***(151 сүз)***

### 3 вариант җаваплары

| **Кыска изложение өчен текст турында белешмә** | |
|---|---|
| **Абзац номеры** | **Микротемалар (мәгънәви кисәкләр)** |
| 1 | Классыбызга яңа укучы килде. |
| 2 | Дәрестә Фәрит бик актив. |

| | |
|---|---|
| 3 | Анының тулы итеп җавап бирүе, тиз фикерләве миңа ошады. |
| 4 | Укытучыбыз Фәритне мактады. |

## II бүлек
## 2 – 8 нче биремнәр

| **Биремнәр** | **Җаваплар** |
|---|---|
| 2 | 4 |
| 3 | 1 |
| 4 | 2, 6 |
| 5 | гөлбакча |
| 6 | 4 |
| 7 | 2 |
| 8 | зарар |

## 4 нче вариант

### I бүлек

***Текстны тыңлагыз һәм 1 нче биремне 2 нче номерлы җаваплар бланкында эшләгез. Башта биремнең номерын, аннары изложение текстын языгыз.***

**1** Текстны тыңлагыз һәм кыска изложение языгыз.

Текстны тыңлагач, микротемаларны билгеләгез.

Тулы текстның һәм андагы микротемаларның төп эчтәлеген бирергә кирәклеген истә тотып эшләгез.

Изложениенең күләме 70 сүздән ким булмаска тиеш.

Изложениене чиста һәм танырлык итеп языгыз.

### II бүлек

***2 – 8 нче биремнәрнең җавабы сүз яки цифрлар булырга мөмкин. Башта җавапны текстта күрсәтегез, соңыннан 1 нче номерлы бланкка бүш ара калдырмыйча, тыныш билгеләрсез, башка өстәмә символларсыз күчереп алыгыз. Һәр хәрефне һәм санны, бланктагы үрнәктә күрсәтелгәнчә, аерым шакмакка языгыз.***

**2** Текстны укыгыз.

1) Бервакыт урманда Әхмәтша карт, ауган агач өстендә аю баласы уйнап йөргәнен күреп, иссез-акылсыз булып торган. 2) Үзләре түгәрәк, үзләре сөйкемле, ди, мер-мер килеп, берсен-берсе төртешеп уйныйлар икән. 3) Авызын ачып торган Әхмәтша картның шул вакытта уң яңагына шундый итеп китереп салганнар. 4) Ул, сөрлегә-сөрлегә алты-җиде метр йөгереп барып җиргә сеңгән. 5) Нәрсә булганын аңламыйча сикереп торса, каршында арт аякларына баскан аю тора, ди.. *(М. Мәһдиевтән)*

Җөмләләрдә **рәвеш хәле** дөрес күрсәтелгән очракны билгеләгез. Җавап номерын языгыз.

16) бервакыт урманда (1 нче җөмлә)
17) төртешеп уйныйлар икән (2 нче җөмлә)
18) Авызын ачып торган (3 нче җөмлә)
19) ул җиргә сеңгән (4 нче җөмлә)
20) арт аякларына баскан аю (5 нче җөмлә)

Җавап: ________________ .

**3** Текстны укыгыз.

**Ирен гармониясе күзәтелгән** сүзләр кулланылган җөмләне табыгыз. Җавап номерын языгыз.

| |
|---|
| 1) Аны-моны уйлап бетергәнче, аю Әхмәтша картның яңагына тагын берне шундый итеп бәргән – карт бөтенләй әллә кая очып китеп барып төшкән. 2) Ана аю үз балаларын карап торганны әнә шулай ошатмаган. 3) Урман шундый хәлләргә бик бай иде. *(М. Мәһдиевтән)* |

Җавап:_____________ _________________ .

**4** Текстны укыгыз.

**Сызык** куелырга тиешле җөмләләрне табыгыз. Җавап номерларын языгыз.

| |
|---|
| 2) Табигать безне үз бишегендә тирбәтеп үстергән әйләнә-тирә мохит. 2) Ә без кеше үзе табигать баласы булуын да онытып җибәрәбез. 3) Табигатьне күбесенчә суларга һава эчәргә су өйләребезне җылытырга утын күмер газ биреп торучы чимал склады итебрәк кенә карыйбыз. 4) Табигать безнең яшәешебез киләчәгебез. |

Җавап: ______________ .

**5** Текстны укыгыз.

**Иялек килешендәге исемне** табып языгыз.

| |
|---|
| Бераздан Галәү бабай, малайлар белән бергәләп, Идел ярындагы карама төбенә йокларга ятты. Болын җиле тәмле печән исе алып килде. Караманың яфраклары, ашыга-ашыга, нәрсәдер пышылдашып алдылар. Моңсу гына тулы ай күтәрелде. |

Җавап: ______________ .

| |
|---|
| ***Текстны укыгыз һәм 6-9 нчы биремнәрне үтәгез.*** |

1) Әй, бу сагыш дигән нәрсә адәм балаларын ничек кенә яндырмый, көйдерми икән?.. 2) Олыгая төшкәч, бу хис аеруча көчәя генә бара. 3) Күрше фатирда яшәүче Бибигайшә әби дә, калага күчеп килгәннән бирле, җанына тынгылык тапмый... 4) Авылын, ялгыз калган йортын сагына. 5) Төннәрен дә йокы керми аның күзләренә... 6) Һәркемне эшкә киткәндә озатып, кайтканда каршы алып хәлен сорашмый калмый ул.

7) Аннан соң ул кырт кына авыл тормышына күчә дә, күңел эчкәресендәге иң нечкә кыллар тибрәнүеннән булса кирәк, ихластан дулкынланып сөйләп китә:

– Ишеткәнсеңдер инде, сеңелем, быел авыл халкы игеннәрне вакытында җыеп ала алмады. 8) Яңгырлар комачаулады бит. 9) Безнең район да артта калган дип ишеттем әле...

10) Аның төсе уңа төшкән коңгырт күзләрендә очкын кабына, киң маңгаендагы җыерчыклары язылып киткәндәй була. 11) Матур булып картайган бу әбинең йөзендә карап туймаслык елмаю балкый...

12) Таң тынлыгын ярып кычкырган әтәчләр дә, язларын яңа гына шытып чыккан яшел чирәм өстендә тәгәрәшкән каз бәбкәләре дә, яшь бозауның шуклыктан арт аякларын атып йөгереп китүе дә, сәрви куакларының чәчәкләрендә безелдәгән бал кортларының гөжләве дә бик еракта калган хатирә сыман тоела аңа. 13) Кое сиртмәсен чүктереп су сосулар, болынга чыгып чалгы кайраулар, көзге мәлне каз өмәләренә җыелып гөр килүләр... 14) Тагын әллә ниләр күз алдына килә Бибигайшә әбинең...

15) Бу кала җирендә аның әйтерсең лә шәүләсе генә. 16) Җаны белән ул үзенең туган-үскән җире, үзе белән картайган йортында...

17) Һавада кыр казларының моңсу гына тонык тавышлары ишетелде. 18) Бибигайшә әби, сискәнеп, утырган урыныннан торды, кулын маңгаена куеп:

19) – Әй-й, кайталар, җанкисәккәйләрем, кыйгач сафларга тезелешеп! 20) Әй-й, аваз салган булалар, бәгырькәйләрем, туган якларга тагын кайттык, диләр. 21) Сагынганнар безнең якларны... 22) Кош булып кош туган илләренә кайтуына сөенеп бетә алмый, адәм баласы ничек җирсемәсен дә, ничек моңсуланмасын?..

23) Киек казлардан да биегрәк булып сагыну-сагышларын куды ул. 24) Җыерчыклар баскан битендә елмаю чаткылары күренде. 25) Әйтерсең лә күңеле белән сагышланып көткән иске йортының терәүле капкасын ачып керде Бибигайшә әби бу минутта. 26) Шулай гына була күрсен...

(Дания Гайнетдиновадан*)

**Дания Гайнетдинова* (1952) – татар шагыйрәсе, язучы.

**6** **Текстның эчтәлегенә туры** килгән җөмләне күрсәтегез. Җавап номерын языгыз.

1) Бибигайшә әби авылда яши.
2) Авылга яз килде.
3) Әби капка төбендә бәбкәләр саклый.
4) Калада яшәүче Бибигайшә әби авылны сагына.
5) Әбинең балалары авылга кайтты

Җавап: ________________ .

**7** **Күчерелмә мәгънәле сүзләр** кулланылган җөмләне күрсәтегез. Җавап номерын языгыз.

1) Авылын, ялгыз калган йортын сагына.

2) Безнең район да артта калган дип ишеттем әле...

3) Аның төсе уңа төшкән коңгырт күзләрендә очкын кабына, киң маңгаендагы җыерчыклары язылып киткәндәй була.

4) Сагынганнар безнең якларны...

5) Шулай гына була күрсен...

Җавап: ________________ .

**8** 1-5 нчы җөмләләрдән ***арта*** сүзенең синонимын табып, күчереп языгыз.

Җавап: ___________ .

***2-8 нче биремнәрнең җавапларын, тестны үтәү өчен күрсәтмәдә әйтелгән тәртиптә, 1 нче номерлы бланкка күчереп язарга һәм җавапның бирем номеры күрсәтелгән юлга язылуын тикшерергә онытмагыз.***

## III бүлек

***2 нче бүлектә укылган текстны файдаланып, 9.1 яки 9.2 нче биремнәрнең баары тик берсен генә сайлап алып, 2 нче номерлы бланкта биремне үтәгез. Яза башлар алдыннан сайланган биремнең номерын күрсәтегез.***

**9.1** **“Кош булып кош туган илләренә кайтуына сөенеп бетә алмый, адәм баласы ничек җирсемәсен дә, ничек моңсуланмасын?..”** җөмләләрендә әйтелгән фикерне ничек аңлыйсыз? Шулар турында языгыз. Фикерегезне раслау өчен, укылган тексттан **2 мисал** китерегез.

Файдаланган җөмләләрнең номерларын языгыз яки тексттан цитата китерегез.

Сочинениенең күләме **70 сүздән** дә ким булмаска тиеш.

Укылган текстка таянып язылмаган эшкә билге куелмый.

Бирелгән текстны күчереп яисә аның эчтәлеген аңлатмаларсыз язган өчен ноль балл куела.

Сочинениене чиста һәм танырлык итеп языгыз.

**9.2** **Сагыш** төшенчәсен ничек аңлыйсыз? **“Иленнән аерылганның канаты каерылган”** темасына сочинение языгыз. Фикерегезне языгыз. Раслау өчен, укылган тексттан **1 мисал**, үзегезнең тормыш тәҗрибәсеннән **1 мисал** китерегез.

Сочинениенең күләме **70 сүздән** дә ким булмаска тиеш.

Укылган текстка таянып язылмаган эшкә билге куелмый.

Бирелгән текстны күчереп яисә аның эчтәлеген аңлатмаларсыз язган өчен ноль балл куела.

Сочинениене чиста һәм танырлык итеп языгыз.

## I бүлек

| *Тыңлау өчен текст* |
|---|

### Әтиемнең эш бүлмәсе

Бөтен җир ап-ак. Авыл кышы бигрәк күңелле икән. Таулардан, урманнардан кайтып кергән юк. Чаңгы белән әллә кайларга барабыз, әллә нинди текә тау башларыннан коштай очып төшәбез. Кыш бабай кебек агарып беткәнче әүмәкләшәбез. Уйныйбыз, көләбез.

Без Гәрәй белән гел бергә, йоклаганда гына аерылабыз. Ул мине физкультурадан шефка алды. Усал укытучы шикелле генә йөри. Сикертә, йөгертә, чаңгыда чаптыра.

Без аның белән бергә түгәрәкләргә йөрибез, бергә дәрес әзерлибез, бергә укытучыбыз Шамил абый янына барабыз. Ул хәзер терелә инде. Көлеп кенә тора. Яз көне санаторийга җибәрсәк, бөтенләй аякка басар, ди әни. Әни белә инде. Ул һәркөн аларга керә, тырыша-тырыша дәвалый. Чөнки әни хәзер врач.

Әнигә эш кенә кирәк булган икән. Эшли башлагач, икенче кеше булды да куйды. Бөтенләй танымассың. Әти белән миңа әз генә дә кычкырмый. Башы авыртмый, өянәге кузгалмый. Көн буе авыл арасында, кешеләрдә, фермаларда йөри. Тышта да көлә, өйдә дә көлә. Әни көлгәч, без көләбез. Өчебез дә көлешеп яшибез. Шулкадәр рәхәт!

*(Газиз Мөхәммәтшиннан)* ***(149 сүз)***

### 4 вариантның җаваплары

| **Кыска изложение өчен текст турында белешмә** | |
|---|---|
| **Абзац номеры** | **Микротемалар (мәгънәви кисәкләр)** |
| 1 | Авылга кыш килде. |
| 2 | Без Гәрәй белән гел бергә. |
| 3 | Гаиләдә көлешеп яшибез. |

## II бүлек
## 2 – 8 нче биремнәр

| **Биремнәр** | **Җаваплар** |
|---|---|

| | |
|---|---|
| 2 | 2 |
| 3 | 1 |
| 4 | 1, 4 |
| 5 | караманың |
| 6 | 4 |
| 7 | 3 |
| 8 | көчәя |

**5 нче вариант**

**I бүлек**

***Текстны тыңлагыз һәм 1 нче биремне 2 нче номерлы җаваплар бланкында эшләгез. Башта биремнең номерын, аннары изложение текстын языгыз.***

**1** Текстны тыңлагыз һәм кыска изложение языгыз.

Текстны тыңлагач, микротемаларны билгеләгез.

Тулы текстның һәм андагы микротемаларның төп эчтәлеген бирергә кирәклеген истә тотып эшләгез.

Изложениенең күләме 70 сүздән ким булмаска тиеш.

Изложениене чиста һәм танырлык итеп языгыз.

**II бүлек**

***2 – 8 нче биремнәрнең җавабы сүз яки цифрлар булырга мөмкин. Башта җавапны текстта күрсәтегез, соңыннан 1 нче номерлы бланкка <u>буш ара калдырмыйча, тыныш билгеләрсез, башка өстәмә символларсыз</u> күчереп алыгыз. Һәр хәрефне һәм санны, бланктагы үрнәктә күрсәтелгәнчә, аерым шакмакка языгыз.***

**2** Текстны укыгыз.

1) Минем әтием– сезгә таныш композитор Салих Сәйдәшев. 2) Аның бала чагы турында мин әбиемнән сөйләтә идем. 3) Ул миңа әтиемнең бик тере, әмма тыңлаучан һәм мәктәптә теләп укый торган малай булуы турында сөйли иде. 4) Бервакыт ул күгәрченнәр очырту белән мавыгып алган. 5) Хәзер төгәл генә әйтә алмыйм: ни сәбәптәндер, аны бу шөгыленнән бик тиз туктатканнар. 6) Шулай да әтием бөтен гомере буе кош-корт һәм хайваннарны яратып караган. (*А. Сәйдәшев*)

Җөмләләрнең **оештыручы үзәкләре (грамматик нигезләре, баш кисәкләре)** дөрес күрсәтелгән очракны билгеләгез. Җавап номерын языгыз.

21) әтием - Салих Сәйдәшев (1 нче җөмлә)
22) бала чагы турында (2 нче җөмлә)
23) тыңлаучан малай (3 нче җөмлә)
24) күгәрченнәр очырту белән (4 нче җөмлә)
25) хайваннарны яратып караган (5 нчы җөмлә)

Җавап: ________________ .

**3** Текстны укыгыз.

**Рәт гармониясе сакланмаган** сүз кулланылган җөмләне табыгыз. Җавап номерын языгыз.

| |
|---|
| 1) Кай көннәрне Казандагы элекке өебез искә төшә дә, кызганып куям. 2) Ничек булса да туган-үскән өй бит. 3) Ә икенче көзгә аны сүтәләр, ди, урынына сигез катлы таш йорт салалар икән. 4) Безнең элекке урам бик зур, матур проспект була икән. (*Г. Мөхәммәтшин*) |

Җавап:_____ .

**4** Текстны укыгыз.
**Сызык** куелырга тиешле җөмләләрне табыгыз. Җавап номерларын языгыз.

| |
|---|
| 1) Сабан туе элек-электән татар халкының яраткан бәйрәме. 2) Сабан туе язгы кыр эшләрен уңышлы башкарып чыгу булачак уңыш бәйрәме. 3) Элек татарлар язгы чәчү эшләрен “сабан” дип атаганнар. 4) “Туй” сүзе татарча мәҗлес бәйрәм дигәнне аңлата. 5) Борынгы чорларда Сабан туе яз һәм табигатьнең җанлануы бәйрәме булган. (*Г. Хәсәнов*) |

Җавап: _______________ .

**5** Текстны укыгыз.
**Саф кушма фигыльне** табып языгыз.

| |
|---|
| Без, җәй көне, Казанга экскурсиягә барырга әзерләнәбез. Әни әйтә, мин дә йортым, бакчаларым белән саубуллашып кайтырмын, ди. Синең иптәшләреңне үз бакчабызның алмалары белән соңгы тапкыр сыйлармын, туйганчы ашасыннар, ди. (*Г. Мөхәммәтшин*) |

Җавап: __________ .

| |
|---|
| ***Текстны укыгыз һәм 6-9 нчы биремнәрне үтәгез.*** |

1) Болыт-шәүләсез, ап-аяз, тымызык бер көн. 2) Күк йөзен биләп баш очында сабыр июнь кояшы балкый. 3) Әлегә ул һәркемгә дә тансык – назлап кына иркәли. 4) Урак өстендәгедәй әлсерәтми дә, алҗытмый да. 5) Аның җылысыннан җанга рәхәт, ә тәнгә сихәт кенә. 6) Шуңа күрә дә тирә-юньдәге барлык җан иясенең бик тә дәртле чагы. 7) Яшелләнеп утырган бодай басуларында төрле кош-кортларның, бөҗәкләрнең шат авазлары ишетелә.

8) Күк бияне атлатып кына без Иртәк үзәне буйлап кайтып киләбез. 9)

Юлдашым Шаһиәхмәт абзыйның никтер авылга ашыгыр исәбе юк әле бүген. 10) Ә каршыга аккан Иртәк суы да әле тал-туйралар арасына кереп югала, әле чоңгыллы күл булып җәелеп тагын алга килеп чыга. 11) Үрле дә таулы, керәле дә чыгалы бу үзән буе элек безнең авылны олы юл белән тоташтырган бердәнбер юл иде. 12) Хәзер ул Иртәк буе авылларының үз үткәне кебек онытылып бара икән. 13) Аны вак сары алабута, әрсез бәбкә үләннәре басып киткән.

14) – И-и, энем, кем йөрсен моннан хәзер. 15) Күзен тал-туйра дип, язын печән дип, без карт-коры гына искә алсак инде. 16) Әнә бит басу ярып яңа юл суздылар...

17) Дөрес шул, Шаһиәхмәт абзый ымлаган якта аксыл тузан болыты бер дә таралып тормый икән. 18) Замана башка, юл башка инде. 19) Тыз-быз чапкан ул җитез тимер “ат”ларга бу иске юл, билгеле, тардыр да, сикелтәледер дә шул. 20) Тик карт кына бу эшне һаман да өнәп бетерми шикелле.

21) – Җир кадерен белмибез! 22) Ишелеп иген үскән басу уртасыннан юл сал, шунда чыгарып каралты-кура төзеп куй, имеш. 23) Әнә тагын, ниндидер комплекс төзибез, дип, күпер артындагы кырны бөтенләй чуттан чыгардылар. 24) Юк, әүвәл безнең бабайлар бөртек төртердәй төшкә абзар да салмаган...

25) Шаһиәхмәт абзый артык ашыкмый. 26) Чалгы очын төртеп алырлык кына печәнлек күрсә дә, ул һич иренеп, икеләнеп тормый.

27) – Тпру, малкай! 28) Ничек ташлап китмәк кирәк шушы байлыкны! – дип шул бер селтәнерлек әйберне җәһәт кенә чабып, күтәреп тә ала, арбага җәеп тә сала.

29) – Әһ, печәне печән генәме соң! – дип мактанып та куя карт. 30) – Без, картлар, шулай юктан бар итәргә яратабыз инде. 31) Кыш уртасында бер бөртеген дә таба алмыйсың аның. (Л. Хәмидуллиннан *)

**Лирон Хәмидуллин* (1932) – танылган язучы-прозаик, тәрҗемәче, публицист.

**6** **Текстның эчтәлегенә туры** килгән җөмләне күрсәтегез. Җавап номерын языгыз.

1) Җәйге авыл иртәсе матур.
2) Шаһиәхмәт абзый авылны ярата.
3) Иртәк елгасында балыклар күп.
4) Авылга зур комплекс кирәк.
5) Без печәнгә килдек.

Җавап: ________________ .

**7** **Фразеологик әйтелмә** кулланылган җөмләне күрсәтегез. Җавап номерын языгыз.

1) Әлегә ул һәркемгә дә тансык – назлап кына иркәли.
2) Күк бияне атлатып кына без Иртәк үзәне буйлап кайтып киләбез.

3) Юлдашым Шаһиәхмәт абзыйның никтер авылга ашыгыр исәбе юк әле бүген.

4) И-и, энем, кем йөрсен моннан хәзер.

5) Без, картлар, шулай юктан бар итәргә яратабыз инде.

Җавап: ________________ .

**8** 21-24 нче җөмләләрдән ***элек*** сүзенең синонимын табып, күчереп языгыз.

Җавап: _________ .

***2-8 нче биремнәрнең җавапларын, тестны үтәү өчен күрсәтмәдә әйтелгән тәртиптә, 1 нче номерлы бланкка күчереп язарга һәм җавапның бирем номеры күрсәтелгән юлга язылуын тикшерергә онытмагыз.***

## III бүлек

***2 нче бүлектә укылган текстны файдаланып, 9.1 яки 9.2 нче биремнәрнең бары тик берсен генә сайлап алып, 2 нче номерлы бланкта биремне үтәгез. Яза башлар алдыннан сайланган биремнең номерын күрсәтегез.***

**9.1** **"Җир кадерен белмибез!"** җөмләсендә әйтелгән фикерне ничек аңлыйсыз? Шулар турында языгыз. Фикерегезне раслау өчен, укылган тексттан **2 мисал** китерегез.

Файдаланган җөмләләрнең номерларын языгыз яки тексттан цитата китерегез.

Сочинениенең күләме **70 сүздән** дә ким булмаска тиеш.

Укылган текстка таянып язылмаган эшкә билге куелмый.

Бирелгән текстны күчереп яисә аның эчтәлеген аңлатмаларсыз язган өчен ноль балл куела.

Сочинениене чиста һәм таныrлык итеп языгыз.

**9.2** **Юктан бар итү** әйтеменең мәгънәсен ничек аңлыйсыз? "**Әйбер кадерен белгән кеше бәхетле булыр**" темасына сочинение языгыз. Фикерегезне языгыз. Раслау өчен, укылган тексттан **1 мисал**, үзегезнең тормыш тәҗрибәсеннән **1 мисал** китерегез.

Сочинениенең күләме **70 сүздән** дә ким булмаска тиеш.

Укылган текстка таянып язылмаган эшкә билге куелмый.

Бирелгән текстны күчереп яисә аның эчтәлеген аңлатмаларсыз язган өчен ноль балл куела.

Сочинениене чиста һәм таныrлык итеп языгыз.

## I бүлек

| *Тыңлау өчен текст* |
|---|

### Миләш

Кечкенә Миләш үзен ялгыз тойды. «Минем яныма беркем дә килми», – дип елады ул.

Сары Күбәләк аның елавын ишетте дә:

– Ник елыйсың, Миләш? – дип сорады.

– Мин ялгыз, минем яныма беркем дә килми, – диде Миләш, үкси-үкси.

– И елак, син бит әле кечкенә, синең чәчәгең дә юк, – диде гамьсез Күбәләк һәм очып та китте.

Күбәләкнең сүзенә Миләшнең хәтере калды. Ул тагын да ныграк елый башлады.

Шул чакны кайдандыр Сыерчык килеп чыкты.

– Ник елыйсың, Миләш? – дип сорады ул да ягымлы тавыш белән.

– Мин ялгыз, минем яныма беркем дә килми, – диде Миләш.

– Син кечкенә бит әле, сине борчырга ярамый, – диде Сыерчык, аны юатып.– Синең әле ботакларың да аз, кошлар кунар урының юк. Зур үскәч, сиңа күбәләкләр дә, кошлар да килер. Син безне кызыл җимешләрең белән сыйларсың. Елама, озакламый син дә үсәрсең!

Миләшнең күңеле күтәрелде. Елаудан туктап, ул елмаеп җибәрде.

*((Гыйльмия Таһировадан)* ***(134 сүз)***

### 5 вариант җаваплары

| Кыска изложение өчен текст турында белешмә | |
|---|---|
| **Абзац номеры** | **Микротемалар (мәгънәви кисәкләр)** |
| 1 | Миләш үзен ялгыз тойды. |
| 2 | Миләшнең Күбәләк сүзләренә хәтере калды. |
| 3 | Миләш янына Сыерчык килде һәм аны юатты. |

## II бүлек
### 2 – 8 нче биремнәр

| Биремнәр | Җаваплар |
|---|---|
| 2 | 1 |
| 3 | 4 |

| | |
|---|---|
| 4 | 1, 2 |
| 5 | саубуллашып |
| 6 | 2 |
| 7 | 5 |
| 8 | әүвәл |

## 6 нчы вариант
## I бүлек

***Текстны тыңлагыз һәм 1 нче биремне 2 нче номерлы җаваплар бланкында эшләгез. Башта биремнең номерын, аннары изложение текстын языгыз.***

**1** Текстны тыңлагыз һәм кыска изложение языгыз.

Текстны тыңлагач, микротемаларны билгеләгез.

Тулы текстның һәм андагы микротемаларның төп эчтәлеген бирергә кирәклеген истә тотып эшләгез.

Изложениенең күләме 70 сүздән ким булмаска тиеш.

Изложениене чиста һәм танырлык итеп языгыз.

## II бүлек

***2 – 8 нче биремнәрнең җавабы сүз яки цифрлар булырга мөмкин. Башта җавапны текстта күрсәтегез, соңыннан 1 нче номерлы бланкка буш ара калдырмыйча, тыныш билгеләрсез, башка өстәмә символларсыз күчереп алыгыз. Һәр хәрефне һәм санны, бланктагы үрнәктә күрсәтелгәнчә, аерым шакмакка языгыз.***

**2** Текстны укыгыз.

1) Кечкенә чакта Гадилә белән Шөһрәт бергәләп су коенырга бик яраталар иде. 2) Камышлар арасыннан кыр үрдәкләрен табып булмаган шикелле, аларны да эзләп таба алмыйсың. 3) Күлдән төнбоек чәчәкләре җыялар. 4) Гадилә ак төнбоекларны бик ярата. 5) Ул яр башына менеп, бер ноктага карап утыра-утыра да, еракта матур чәчәк күреп, кинәт күлгә сикерә.

Җөмләләрдә **вакыт хәле** дөрес күрсәтелгән очракны билгеләгез. Җавап номерын языгыз.

26) кечкенә чакта яраталар иде (1 нче җөмлә)
27) камышлар арасыннан таба алмыйсың (2 нче җөмлә)
28) төнбоек чәчәкләре җыялар (3 нче җөмлә)
29) Гадилә ярата (4 нче җөмлә)
30) матур чәчәк (5 нче җөмлә)

Җавап: ________________ .

**3** Текстны укыгыз.

**Рәт гармониясе сакланмаган** сүз кулланылган җөмләне табыгыз. Җавап номерын языгыз.

1) Мәнә берзаман таулар да бетеп киткән кебек тоелды, каршыда киң үзәнлекләр ачылып китте. 2) Сарбай, тәгәрәп диярлек, тигез җирдән чаба башлады. 3) Карт үзе дә тау-таштан бик арыган иде, йомшак җир буйлап рәхәтләнеп атлады. (*Фәүзия Бәйрәмова)*

Җавап: _______________ .

**4** Текстны укыгыз.

**Өтерләр** куелырга тиешле җөмләләрне табыгыз. Җавап номерларын языгыз.

1) Инде сугыш башлангач өч улы шул кечкенә станциядән кызыл вагоннарга утырып кояш батышына таба фронтка киттеләр. 2) Мәрьям абыстайның исәбенчә алар кайчан да булса шул ук станциягә кире кайтып төшәргә тиешләр иде. 3) Мәнә ул күңеле моңсу сагыш белән тулган яки бер дә сәбәпсез эче пошкан минутларда тәрәзәдән тимер юл буена карап торырга гадәтләнде. (*Әмирхан Еники*)

Җавап: ________________ .

**5** Текстны укыгыз.

**Исем фигыльне** табып языгыз.

Кешеләр җирдә яңа матурлык тудыру өчен эзләнәләр, максатларына ирешергә күпме көч куялар. Ә аяк астында ярдәм сорап яткан чиксез бай хәзинәнең йөзенә басып йөриләр. Мәнә сине дә бик күп кешеләр көтә бит, чишмә! Син булмагач, бу дөньяда нинди зур сихри гүзәллек җитми.

Җавап: _______ _______ .

***Текстны укыгыз һәм 6-9 нчы биремнәрне үтәгез.***

1) Татарча көрәш буенча республика чемпионы Рөстәм шәһәрдән кайтып килә иде. 2) Станциядә таныш шоферы, кабина ишеген ачып, аңа кул изәде. 3) Тик Рөстәм машинага утырамы соң? 4) Егерме чакрымдагы авылга рәхәтләнеп җәяү генә кайта ул.

5) Кояшлы җәйге иртә. 6) Төнлә мул һәм җылы яңгыр явып үткән. 7) Шоссе өстендәге вак иңкүлекләрдә, кырыйдагы чокырларда эреле-ваклы күзгеләр ялтырый. 8) Яшь батыр, киң күкрәген тутырып, әле серкәләнә генә башлаган арыш исен сулый. 9) Арыш басуы өстеннән килгән салмак җил аның кара

бөдрәләре белән уйный. 10) Нинди рәхәт дөньяда яшәве! 11) Үзеңнең ярышларда җиңүче икәнеңне, беләкләрдә көч ташып торганын хис итүе нинди рәхәт!

12) Ә менә, олылар сөйләвенчә, безнең борынгы бабаларыбыз тагын да көчле, таза булганнар әле. 13) Чатнама суыкларда бер кат киндер ыштаннан йөри алганнар. 14) Рөстәмнәр авылыннан бер агай бер йөк утынны чанасы-ние белән аркасына салган да базардан бер чакрымдагы үз өенә күтәреп кайткан. 15) Яхшы ат тарта торган йөкне күтәреп кенә барган ул агай. 16) Баһадир булган ул!

17) Рөстәм уйга калды. 18) Ә менә хәзер ул, тирә-як авыллардагы егетләрнең иң көчлесе, теге агай белән тиңләшә алыр иде микән? 19) Ай-һай, ат кадәр ат йөге бит ул... 20) Шулай итеп, техника үсә барган саен, тормыш җиңеләйгән саен кешеләр үзләре вагая, көчсезләнә бара дигән сүзләр дөрес микәнни? 21) Ул тәкъдирдә безнең киләчәктәге оныкларга әллә ни кызыгасы юк. 22) Әнә бит ничек үсә техника дигәнең. 23) Инде бүген үк тирләп-пешеп чалгы селтәүләрне, хәтта утын яруларны да оныта барабыз. 24) Ә йөз елдан, мең елдан бу җир йөзендәниләр булмас дисең. 25) Мөгаен, хәтта стенага кнопканы да роботлар чәнчеп куяр. 26) Шулай итеп безнең оныкларыбыз сыек бәдәнле, карсак буйлы, җеп тартып өзәргә дә көче җитмәгән мәхлукларга әйләнеп калыр микәнни?

27) Рөстәм елмаеп куйды. 28) Дөньяда могҗиза булып әнә шул оныкларны бер күрәсе иде. 29) Икешәр потлы герләрне капка түбәсе аша чөеп күрсәтәсе иде үзләренә. 30) Дистәләбен иңбашына күтәреп йөрисе иде... 31) Тик бу тыйнак, оялчан егет үзалдына гына булса да мактанырга яратмый иде. 32) Һәм ул, күңеленә килгән мондый уйлардан арынырга теләп, як-ягына каранып атлады.

*(Р. Фәизовтан *)*

**Радик Фәизов* (1931-2011) – танылган язучы, хикәяче.

**6** **Текстның эчтәлегенә туры** килгән җөмләне күрсәтегез. Җавап номерын языгыз.

1) Рөстәм шәһәрдә яши.
2) Рөстәм киләчәк буын турында уйлана.
3) Рөстәм борынгылар турында китаплар укый.
4) Рөстәм  - мактанчык егет.
5) Рөстәм йокыга талып, төш күргән.

Җавап: ________________ .

**7** **Фразелогик әйтелмә** кулланылган җөмләне күрсәтегез. Җавап номерын языгыз.

1) Станциядә таныш шоферы, кабина ишеген ачып, аңа кул изәде.

2) Үзеңнең ярышларда җиңүче икәнеңне, беләкләрдә көч ташып торганын хис итүе нинди рәхәт!

3) Инде бүген үк тирләп-пешеп чалгы селтәүләрне, хәтта утын яруларны

да оныта барабыз.

4) Мөгаен, хәтта стенага кнопканы да роботлар чәнчеп куяр.

5) Дистәләбен иңбашына күтәреп йөрисе иде...

Җавап: ________________ .

**8** 12-16 нчы җөмләләрдән ***зәмһәрир*** сүзенең синонимын табып, күчереп языгыз.

Җавап: ___________ .

***2-8 нче биремнәрнең җавапларын, тестны үтәү өчен күрсәтмәдә әйтелгән тәртиптә, 1 нче номерлы бланкка күчереп язарга һәм җавапның бирем номеры күрсәтелгән юлга язылуын тикшерергә онытмагыз.***

## III бүлек

***2 нче бүлектә укылган текстны файдаланып, 9.1 яки 9.2 нче биремнәрнең <u>бары тик берсен генә сайлап алып</u>, 2 нче номерлы бланкта биремне үтәгез. Яза башлар алдыннан сайланган биремнең номерын күрсәтегез.***

**9.1** **Тик бу тыйнак, оялчан егет үзалдына гына булса да мактанырга яратмый иде. Һәм ул, күңеленә килгән мондый уйлардан арынырга теләп, як-ягына каранып атлады.** - җөмләләрендә әйтелгән фикерне ничек аңлыйсыз? Шулар турында языгыз. Фикерегезне раслау өчен, укылган тексттан **2 мисал** китерегез.

Файдаланган җөмләләрнең номерларын языгыз яки тексттан цитата китерегез.

Сочинениенең күләме **70 сүздән** дә ким булмаска тиеш.

Укылган текстка таянып язылмаган эшкә билге куелмый.

Бирелгән текстны күчереп яисә аның эчтәлеген аңлатмаларсыз язган өчен ноль балл куела.

Сочинениене чиста һәм танырлык итеп языгыз.

**9.2** **Көчле булу** төшенчәсен ничек аңлыйсыз? “**Көч беләктә түгел, йөрәктә**” темасына сочинение языгыз. Фикерегезне языгыз. Раслау өчен, укылган тексттан **1 мисал**, үзегезнең тормыш тәҗрибәсеннән **1 мисал** китерегез.

Сочинениенең күләме **70 сүздән** дә ким булмаска тиеш.

Укылган текстка таянып язылмаган эшкә билге куелмый.

Бирелгән текстны күчереп яисә аның эчтәлеген аңлатмаларсыз язган өчен ноль балл куела.

Сочинениене чиста һәм танырлык итеп языгыз.

## I бүлек

| Тыңлау өчен текст |
| --- |

### Канатлы дусларыбызны онытмыйк

Менә ак тунлы кыш та килеп җитте. Бер-ике көн эчендә әллә никадәр кар яуды. Бөтен тирә-як ап-ак юрган астында калган кебек иде.

Укытучыбыз Сания апа кошларга җимлекләр ясап бирергә һәм анда нинди кошлар очып килүен күзәтергә кушты. Без моңа шатланып риза булдык. Мәктәптән кайткач, һәрберебез җимлек ясарга керештек.

Мин дә тактадан кечкенә генә өстәл һәм җимлек ясадым. Аны урман янындагы карт чыршы төбенә куйдым. Чыршының куе ботаклары җимлектәге азыкны кар басудан сакларлык иде. Җимлек әйбәт булып чыкты. Ул тәрәзәбездән дә күренеп тора әле. Дөресе шулай. Минем әтием урманчы булып эшли. Шуңа күрә урман янындагы өйдә яшибез.

Якшәмбе көн иде. Җимлегемә ипи, ярма, кипкән миләшләр салдым. Бер читтән күзәтә башладым. Менә ике песнәк килеп кунды. Ярма белән икмәкне ашадылар да агач ботагына кундылар. Шул арада кызылтүшләр очып килеп җитте. Алар миләш яраталар икән. Рәхәтләнделәр миләш ашап. Миләш чыпчыгы да авыз итте минем җимлектәге азыктан. Ә чыпчыклар? Алар җимлектән китергә ашыкмыйлар әле. Кинәт җимлек өстендәге ботакка тиен сикереп менде. Ул да миләштән авыз итте.

Хәзер мин көн саен канатлы дусларыма җим бирәм. Тиеннәр дә рәхим итсеннәр.

*(Ш.Бикколдан)* ***(174 сүз)***

### 6 вариант җаваплары

| Кыска изложение өчен текст турында белешмә | |
| --- | --- |
| **Абзац номеры** | **Микротемалар (мәгънәви кисәкләр)** |
| 1 | Менә кыш килеп җитте. |
| 2 | Укытучыбыз Сания апа җимлекләр ясарга кушты. |
| 3 | Мин җимлегемне урман янындагы агачка куйдым. |
| 4 | Минем җимлегемә кошлар килде. |
| 5 | Хәзер мин көн саен дусларыма җми бирәм. |

## II бүлек
## 2 – 8 нче биремнәр

| **Биремнәр** | **Җаваплар** |
| --- | --- |
| 2 | 1 |
| 3 | 1 |
| 4 | 1, 2 |
| 5 | тудыру |
| 6 | 2 |
| 7 | 2 |
| 8 | чатнама |

## 7 нче вариант
## I бүлек

***Текстны тыңлагыз һәм 1 нче биремне 2 нче номерлы җаваплар бланкында эшләгез. Башта биремнең номерын, аннары изложение текстын языгыз.***

**1** Текстны тыңлагыз һәм кыска изложение языгыз.

Текстны тыңлагач, микротемаларны билгеләгез.

Тулы текстның һәм андагы микротемаларның төп эчтәлеген бирергә кирәклеген истә тотып эшләгез.

Изложениенең күләме 70 сүздән ким булмаска тиеш.

Изложениене чиста һәм танырлык итеп языгыз.

## II бүлек

***2 – 8 нче биремнәрнең җавабы сүз яки цифрлар булырга мөмкин. Башта җавапны текстта күрсәтегез, соңыннан 1 нче номерлы бланкка буш ара калдырмыйча, тыныш билгеләрсез, башка өстәмә символларсыз күчереп алыгыз. Һәр хәрефне һәм санны, бланктагы үрнәктә күрсәтелгәнчә, аерым шакмакка языгыз.***

**2** Текстны укыгыз.

1) Әле уңга сугылган ул, әле сулга, әле алга йөгергән ул, әле артка. 2) Атлый-йөгерә торгач, эзли торгач, ярты кәрзин җиләк җыйган Таңсылу, тик җиләккә мавыгып, караңгы төшкәнен сизми калган. 3) Исенә килеп кайтырга чыкканда, төн үзенең кара җәймәсен күктән җиргә кадәр җәеп куйган булган. 4) Кыз, ятьмәгә эләккән балыктай бәргәләнгән, тәмам адашкан. 5) Тегендә чабып, монда чабып хәле беткән. *(Фәнис Яруллиннан)*

Җөмләләрнең **тәмамлыгы** дөрес күрсәтелгән очракны билгеләгез. Җавап номерын языгыз.

31) уңга сугылган (1 нче җөмлә)
32) ярты кәрзин җиләк (2 нче җөмлә)
33) җәймәсен җәеп куйган булган (3 нче җөмлә)
34) кыз адашкан (4 нче җөмлә)
35) тегендә чабып (5 нче җөмлә)

Җавап: ________________ .

**3** Текстны укыгыз.

**Тел арты ассимиляциясе күзәтелгән сүз булган** җөмләне табыгыз. Җавап номерын языгыз.

| |
|---|
| 1) Кәрим истәлекле урыннарның тарихы белән кызыксына. 2) Мәктәптә тарих укытучысы аны бик мактый. 3) Кәрим күп укый, күп белә. 4) Күптән түгел укытучысы аңа истәлекле вакыйгаларга багышланган бәйгедә катнашырга тәкъдим иткән. |

Җавап: _______________ .

**4** Текстны укыгыз.

**Ике нокта** куелырга тиешле җөмләләрне табыгыз. Җавап номерларын языгыз.

| |
|---|
| 1) Күземне ачтым өскә бактым нигәдер кояшның күзе кызарган зәңгәр күкне кара-кучкыл болытлар каплап алган. 2) Сикереп тордым. 3) Тирә-ягыма күз салдым табигатьтәге аклык башка чуар төсләр белән бергә укмашкан. 4) Ерактан мыштым гына якынлашкан тыгыз җил көчәеп мине тузанга коендырып китте. (*Рөстәм Галиуллиннан*) |

Җавап: _______________ .

**5** Текстны укыгыз.

**Саф кушма исемне** табып языгыз.

| |
|---|
| Туган төбәгемдә табигатьнең үзе шикелле гадел карашлы кешеләр белән аралашып үсүемне олы бәхет дип саныйм. Бәләкәйдән ук Парижларны күрмәдем, дөньялар гизмәдем, әмма язмышыма үпкәләмим. Ярлы балачагым күңелле узды. (*Марсель Галиевтән*) |

Җавап: ________________ .

***Текстны укыгыз һәм 6-9 нчы биремнәрне үтәгез.***

1) Ильяс мәктәпкә килеп кергәндә, әле кыңгырау чылтырамаган иде. 2) Ашыга-кабалана чишенү бүлмәсенә узды да, эскәмиягә утырып, чәчәкләрне янәшәсенә куйды һәм аяк киемен салырга дип иелгән халәтендә катып калды: нәкъ шул минутта ишек төбендә Ландыш белән Алисәнең чырык-чырык сөйләшкәне ишетелде.

3) — Алисә, беләсеңме, бүген туган көнемә әти нәрсә бүләк итте? 4) Кара! 5) Айпад! 6)Утыз меңлек! 7) Ә бу алтын алкаларны әни алды.

8) — Матур! 9) Үзең матур булгач, сиңа бар нәрсә дә килешә инде!

10) Чыннан да, сыйныфларындагы иң матур кыз шул ул Ландыш. 11) Төс-кыяфәте дә, кигән киемнәре дә бүтәннәрдән күпкә аерылып, үзенә җәлеп итеп тора.

12) — Әти белән әни минем өчен беркайчан да акча җәлләми, очсыз әйберне үземнең дә җенем сөйми. 13) Ә син помнишь, былтыр минем туган көнемә безнең сыйныфтагы Ильяс йомшак уенчык күтәреп килгән иде? 14) Ужас, әйеме? 15) Менә күрерсең, быел да шундый өч тиенлек берәр нәрсә алып киләчәк әле. 16) Ул миңа гашыйк булган, ахрысы, мескен! – диде Ландыш.

17) — Ильяс турында ямьсез сүз әйтмә, Ландыш!

18) Алисәне дә шушы минутта алмаштырып куйдылар диярсең, тавышы тимер чыңыдай чатнап чыкты. 19) — Сыйныфыбыздагы иң акыллы, чиста күңелле малай ул!.. 20) Бүтәннәргә аның кебек эшчән, ярдәмчел булырга ай-яй әле!

21) Шул вакытта кыңгырау чылтырады. 22) Кызлар үзара сөйләшә-сөйләшә чыгып киттеләр. 23) Ильяс исә үзалдына аптырап калды. 24) Очын очка ялгарга тырышып, әллә ничә эштә эшләп йөрүче әнисе, аз булса да файда китерим дип, дәресләрдән соң газета таратып, үзенең дә акча эшләргә тырышуы, бүгенге чәчәкләрне дә сөенә-сөенә үз акчасына алуы яшен утыдай күз алдыннан сызылып үтте.

25) Ильяс кызларны куып җитте:

— Алисә! — дип эндәште һәм кызга чәчәк бәйләмен сузды. 26) — Иртәгә җәйге каникуллар башлана бит, шуның белән бүген үк котлыйм әле сине, партадаш! — дип, көтелмәгән кыюлык белән өстәп тә куйды.

27) Әллә Алисәнең дөньяны балкытып эчкерсез елмаюыннан, әллә чәчәкләрдән сирпелгән аклыктан бөтен тирә-як шул мизгелдә нурга күмелде...

*(Айгөл Әхмәтгалиевадан*)*

**Айгөл Әхмәтгалиева* (1973) – язучы.

**6** **Текстның эчтәлегенә туры** килгән җөмләне күрсәтегез. Җавап номерын языгыз.

1) Бүген Ильясның туган көне.
2) Уку тәмамланырга да күп калмады.
3) Ильяс Ландышны туган көне белән котларга җыена.
4) Алисә Ильясны ошатып йөри.
5) Ландышка туган көненә бүләк бирмәгәннәр.

Җавап: ________________ .

**7** **Татар теле нормаларына туры килмәгән сүзләр** кулланылган җөмләне күрсәтегез. Җавап номерын языгыз.

1) Ильяс мәктәпкә килеп кергәндә, әле кыңгырау чылтырамаган иде.
2) — Алисә, беләсеңме, бүген туган көнемә әти нәрсә бүләк итте?

3) Ә син помнишь, былтыр минем туган көнемә безнең сыйныфтагы Ильяс йомшак уенчык күтәреп килгән иде?

4) — Ильяс турында ямьсез сүз әйтмә, Ландыш!

5) Кызлар үзара сөйләшә-сөйләшә чыгып киттеләр.

Җавап: ________________ .

**8** 21-24 нче җөмләләрдән ***рус теле аша кергән Европа алынмасын*** табып, күчереп языгыз.

Җавап: ________ .

***2-8 нче биремнәрнең җавапларын, тестны үтәү өчен күрсәтмәдә әйтелгән тәртиптә, 1 нче номерлы бланкка күчереп язарга һәм җавапның бирем номеры күрсәтелгән юлга язылуын тикшерергә онытмагыз.***

## III бүлек

***2 нче бүлектә укылган текстны файдаланып, 9.1 яки 9.2 нче биремнәрнең <u>бары тик берсен генә сайлап алып</u>, 2 нче номерлы бланкта биремне үтәгез. Яза башлар алдыннан сайланган биремнең номерын күрсәтегез.***

**9.1** **Алисәне дә шушы минутта алмаштырып куйдылар диярсең, тавышы тимер чыңыдай чатнап чыкты.— Сыйныфыбыздагы иң акыллы, чиста күңелле малай ул!.. Бүтәннәргә аның кебек эшчән, ярдәмчел булырга ай-яй әле! -** җөмләләрендә әйтелгән фикерне ничек аңлыйсыз? Шулар турында языгыз. Фикерегезне раслау өчен, укылган тексттан **2 мисал** китерегез.

Файдаланган җөмләләрнең номерларын языгыз яки тексттан цитата китерегез.

Сочинениенең күләме **70 сүздән** дә ким булмаска тиеш.

Укылган текстка таянып язылмаган эшкә билге куелмый.

Бирелгән текстны күчереп яисә аның эчтәлеген аңлатмаларсыз язган өчен ноль балл куела.

Сочинениене чиста һәм танырлык итеп языгыз.

**9.2** **Матурлык** төшенчәсен ничек аңлыйсыз? **“Матурлык нәрсәдән тора?”** темасына сочинение языгыз. Фикерегезне языгыз. Раслау өчен, укылган тексттан **1 мисал**, үзегезнең тормыш тәҗрибәсеннән **1 мисал** китерегез.

Сочинениенең күләме **70 сүздән** дә ким булмаска тиеш.

Укылган текстка таянып язылмаган эшкә билге куелмый.

Бирелгән текстны күчереп яисә аның эчтәлеген аңлатмаларсыз язган өчен ноль балл куела.

Сочинениене чиста һәм танырлык итеп языгыз.

## I бүлек

| Тыңлау өчен текст |
|---|

### Яхшылык кире кайта

Малайны әнисе кибеткә җибәрде. Ул ипи, казылык, сөт, катык алды да шуларны сумкасына тутырган хәлдә урам буйлап атлады. Биш-алты адым ара уздымы, каршында – маэмай! Койрыгын селкеп, борынын суза-суза шатлана. Яхшылыкка җавап бирми калу – начарлык. Шуңа күрә ул этне яратмыйча уза алмады. Тик эт нәрсәдер көтә иде.

Малай аңа ипи сындырып бирде. Эт ипине ашагач, казылык белән сыйлады. Ул кунагын тагын бер кат сыйпады да юлын дәвам итте.

Өйгә кайткач, бик үк каты булмаса да әнисеннән шелтә эләкте эләгүен. Ләкин малай андый гына ачулануга түгел, катырагына да түзәргә әзер иде.

Ул мәктәптән кайтып килгәндә, бер дә юктан эт көтүе аның өстенә һау-һаулап ташланды. Шул вакыт араларынннан берсе алгарак чыкты да, шулай ук ыржаеп, эт өеренә каршы ташланды. Шулай өрешә һәм шаулаша торгач, эт көтүе чигенергә мәҗбүр булды.

Күп тә үтмичә, алар үз юллары белән атлады. Малайны яклашкан маэмай гына калды. Койрык селки-селки, якты күзен елтыратып карап тора иде.

Малай аның теге вакытта үзе сыйлаган эт икәнен шунда гына таныды. (159 сүз)

*(Әхсан Баяновтан)*

### 7 вариант җаваплары

| Кыска изложение өчен текст турында белешмә | |
|---|---|
| **Абзац номеры** | **Микротемалар (мәгънәви кисәкләр)** |
| 1 | Малайны әнисе кибеткә җибәрде. |
| 2 | Малай, кибеттән кайтканда, маэмайны сыйлады. |
| 3 | Өйгә кайткач, әнисеннән эләгә. |
| 4 | Маэмай малайны эт көтүеннән яклады. |

## II бүлек
## 2 – 8 нче биремнәр

| Биремнәр | Җаваплар |
|---|---|

| | |
|---|---|
| 2 | 3 |
| 3 | 4 |
| 4 | 1, 3 |
| 5 | балачак |
| 6 | 3 |
| 7 | 3 |
| 8 | газета |

## 8 нче вариант
## I бүлек

***Текстны тыңлагыз һәм 1 нче биремне 2 нче номерлы җаваплар бланкында эшләгез. Башта биремнең номерын, аннары изложение текстын языгыз.***

**1** Текстны тыңлагыз һәм кыска изложение языгыз.
Текстны тыңлагач, микротемаларны билгеләгез.

Тулы текстның һәм андагы микротемаларның төп эчтәлеген бирергә кирәклеген истә тотып эшләгез.

Изложениенең күләме 70 сүздән ким булмаска тиеш.

Изложениене чиста һәм танырлык итеп языгыз.

## II бүлек

***2 – 8 нче биремнәрнең җавабы сүз яки цифрлар булырга мөмкин. Башта җавапны текстта күрсәтегез, соңыннан 1 нче номерлы бланкка бүш ара калдырмыйча, тыныш билгеләрсез, башка өстәмә символларсыз күчереп алыгыз. Һәр хәрефне һәм санны, бланктагы үрнәктә күрсәтелгәнчә, аерым шакмакка языгыз.***

**2** Текстны укыгыз.

1) Минем әбием барлык күршеләр белән дә дус, тату яшәде. 2) Беркайчан да юкка-барга күрше белән телгә килмәс, әйтәсе сүзен уйлап әйтер, күршеләр арасында кайчакта була торган кычкырышуларга, телләшүләргә катнашмый иде. 3) Шулай да ул, нишләптер, бездән биш йорт аша яшәгән Тәзкирә әби белән уртак тел таба алмады. 4) Дөресрәге, ул аның белән бөтенләй аралашмый иде. 5) Бер урамда яшиләр бит, очрашмый тора алмыйлар, әлбәттә, тик, очрашканда, чит кешеләре кебек, “исәнме-саумы”дан ары китә алмадылар. *(Х. Ширмәннән)*

Җөмләләрдә **вакыт хәле** дөрес күрсәтелгән очракны билгеләгез. Җавап номерын языгыз.

36) әбием яшәде (1 нче җөмлә)
37) беркайчан да телгә килмәс (2 нче җөмлә)
38) биш йорт аша яшәгән (3 нче җөмлә)
39) ул араалашмый иде (4 нче җөмлә)
40) бер урамда яшиләр (5 нче җөмлә)

Җавап: ________________ .

**3** Текстны укыгыз.

**Ирен ассимиляциясе күзәтелгән** сүз кулланылган җөмләне табыгыз. Җавап номерын языгыз.

| |
|---|
| 1) Бердәнбер көнне, Илдарның башына шундый уй килде: әгәр дә ул, кардан әнисенең сынын ясап, 8 Март көнне шуны алып кереп бүләк итсә? 2) Ну шаккатыр, ну сөенер иде әнисе!. 3) Шул ук кичтә Илдар үзенең бүләген, качырып кына алып кереп, иң түр бүлмәнең бер почмагына бастырып та куйды. *(Г. Гыйльмановтан)* |

Җавап:_________________ .

**4** Текстны укыгыз.
**Өтер** куелырга тиешле җөмләләрне табыгыз. Җавап номерларын языгыз.

| |
|---|
| 1) Март ахыры якынлашкач беренче зур яңалык шул булды кычыткан күбәләге оча башлады. 2) Кирпеч төсле кызыл күбәләк. 3) Шул кызыл өстендә вак кара таплар күренә. 4) Юка канатлары читеннән кара кайма киткән ә каймага зәңгәр таплар тезелгән. 5) Күбәләк суыкны агач ярыгында уздырган һәм яз җиткәч уянган. (*Г. Хәсәновтан*) |

Җавап: ______________ .

**5** Текстны укыгыз.
**Саф кушма исемне** табып языгыз.

| |
|---|
| Тау иңенә чалкан төшкән, туарылып аккан болытларга карыйм. Мин йөзәмме, болытлармы… Сирпелеп киткән тымызык әрем исендә – яшәү дәрте, исерткеч тәм, йомшак җил пышылдавы… Ваемсыз балачактагы кебек, күңелгә тыелгысыз хис тула. (*М. Галиевтән*) |

Җавап: ___________ .

| |
|---|
| ***Текстны укыгыз һәм 6-9 нчы биремнәрне үтәгез.*** |

1) Маратның вәгъдәләр таратырга оста икәнен мәктәптә күпләр белмиләр әле. 2) Бары дусты Илдар гына аның ничек итеп ялган вәгъдәләр бирергә оста икәнен чамалый. 3) Компьютердан дискка уеннар яздырып бирәм, тегене алып киләм, моны эшлим... 4) Бик күп алар!.. 5) Илдар үзе дә шакката дустының шундый ялганчы булуына.

6) - Болай кеше алдалап йөрмә, барыбер бер килеп кабарсың, - дип һәрчак кисәтә ул аны. 7) Тик Маратның исе дә китми.

8) Ә беркөнне Илдар бөтенләй телсез калды.

9) Сыйныфташлары Алиягә җырлардан торган диск яздырам дип вәгъдә биргән Марат. 10) “Иртәгә алып киләм, берсекөнгә әзер була”, - дип, бер ай буе алдап йөргән кызны.

11) Дәресләр тәмамлануга, өенә ашыккан Илдарны ишек төбендә Марат белән Алия тотып алды.

12) - Нәрсә булды? 13) Ашыгам! – диде Илдар.

14) Марат:

15) - Менә Алиягә диск алып килгән идем. 16) Соңгы дәрестә югалттым. 17) Сыйныфта калган булырга тиеш. 18) Әйдә, бергә эзлик әле, - диде.

19) Таба алмагач, Марат яңа хәйлә уйлап чыгарды. 20) “Ул Ринатның сумкасында киткән булырга тиеш, шалтыратып сорыйм әле”, - диде. 21) Ул читкәрәк китте дә, кәрәзле телефонының “шалтыратырга” дигән яшел төймәсенә басмый гына сөйләшкән булды. 22) Аннан, кызга борылып: “Синең диск Ринатта икән. 23) Иртәгә алып киләм, диде. 24) Мин сиңа берсекөнгә яздырып килермен”, - диде.

25) Алар өчәүләшеп баскычтан төшеп килгәндә, беренче каттагы ишек янында Ринат басып тора иде.

26) - Кайчаннан бирле шалтыратам, ник телефоныңны алмыйсың? – диде Ринат, Маратны күргәч. 27) – Инде бер ай буе вәгъдә биреп йөрисең, бүген алып килдеңме китапны?!

28) Илдар көлеп җибәрде, Алия, аптырап, бер Ринатка, бер Маратка карады. 29) Марат үзе дә югалып калды. (Р.Галиуллиннан*)

**Рөстәм Галиуллин** (1987) – татар язучысы.

**6** **Текстның эчтәлегенә туры** килгән җөмләне күрсәтегез. Җавап номерын языгыз.

1) Сыйныфта компьютер түгәрәгенә йөрүче дуслар бар.
2) Илдар – ялганчы.
3) Марат Алиянең китабын алган булган.
4) Марат ялган вәгъдәләр бирергә бик ярата.
5) Ринатның дискы югалган.

Җавап: ________________ .

**7** **Фразеологик әйтелмә** кулланылган җөмләне күрсәтегез. Җавап номерын языгыз.

1) Бик күп алар!..

2) Тик Маратның исе дә китми.

3) “Иртәгә алып киләм, берсекөнгә әзер була”, - дип, бер ай буе алдап йөргән кызны.

4) Менә Алиягә диск алып килгән идем.

5) Кайчаннан бирле шалтыратам, ник телефоныңны алмыйсың? – диде Ринат, Маратны күрүгә.

Җавап: ________________ .

**8** 6-10 нчы җөмләләрдән ***рус теле аша кергән Европа алынмасын*** табып, күчереп языгыз.

Җавап: ____ ______ .

***2-8 нче биремнәрнең җавапларын, тестны үтәү өчен күрсәтмәдә әйтелгән тәртиптә, 1 нче номерлы бланкка күчереп язарга һәм җавапның бирем номеры күрсәтелгән юлга язылуын тикшерергә онытмагыз.***

## III бүлек

***2 нче бүлектә укылган текстны файдаланып, 9.1 яки 9.2 нче биремнәрнең бары тик берсен генә сайлап алып, 2 нче номерлы бланкта биремне үтәгез. Яза башлар алдыннан сайланган биремнең номерын күрсәтегез.***

**9.1** **“Илдар үзе дә шакката дустының шундый ялганчы булуына.**
**- Болай кеше алдалап йөрмә, барыбер бер килеп кабарсың, - дип һәрчак кисәтә ул аны. Тик Маратның исе дә китми.”** җөмләләрендә әйтелгән фикерне ничек аңлыйсыз? Шулар турында языгыз. Фикерегезне раслау өчен, укылган тексттан **2 мисал** китерегез.

Файдаланган җөмләләрнең номерларын языгыз яки тексттан цитата китерегез.

Сочинениенең күләме **70 сүздән** дә ким булмаска тиеш.

Укылган текстка таянып язылмаган эшкә билге куелмый.

Бирелгән текстны күчереп яисә аның эчтәлеген аңлатмаларсыз язган өчен ноль балл куела.

Сочинениене чиста һәм танырлык итеп языгыз.

**9.2** **Ялганчының теле үзенә үзе аяк чала** мәкален ничек аңлыйсыз? **“Ялганлау яхшылыкки илтми”** темасына сочинение языгыз. Фикерегезне языгыз. Раслау өчен, укылган тексттан **1 мисал**, үзегезнең тормыш тәҗрибәсеннән **1 мисал** китерегез.

Сочинениенең күләме **70 сүздән** дә ким булмаска тиеш.

Укылган текстка таянып язылмаган эшкә билге куелмый.

Бирелгән текстны күчереп яисә аның эчтәлеген аңлатмаларсыз язган өчен ноль балл куела.

Сочинениене чиста һәм танырлык итеп языгыз.

## I бүлек

| Тыңлау өчен текст |
|---|

### Беренче укытучым

Минем беренче укытучым – Гадилә апа – ул чакта да өлкән яшьтә иде инде. Безне кайтарып җибәргәч тә утырып кала, дәфтәр тикшереп, киләсе дәресләренә әзерләнеп кайта торган булгандыр, класс тәрәзәсендә соңга кадәр ут сүнми иде.

Ялгыз яшәде Гадилә апа. “Сезнең барлыкка куанып яшим”, – дигән сүзләрен кайсыбыз аңлап җиткерсен соң? Хәер, бүген дә белеп бетермим бугай әле андый мәгънәне. Юкса, иң яраткан укучыларының берсе булып исәпләнә идем, өлкән классларда да укуым белән кызыксынып торды. Институтка укырга кергәч тә, миннән бигрәк ул куанды.

Аннан соң күп еллар узды инде. Гадилә апа белән үткән көннәр дә күңелдә җуела барды. Һәркемнең үз тормышы, үз мәшәкатьләре...

Янына килеп басуыма, Гадилә апа мине шунда ук таныды, кочаклап алды.

“Бәйрәм көнне берәрсе кереп чыгар дигән идем, рас килде бит! – диде, балаларча куанып. Мин синең шушы тирәдә генә яшәвеңне ишетеп белә идем, җае чыкмыйдыр, бер күрешеп чыгар әле дип көтә идем! – дип, сөйләнә-сөйләнә, капкага таба атлады. Йөземне чәчәкләр артына яшердем, юкса күзләремнең алдашканын, йөземнең куанычтан түгел, уңайсызланудан кызаруын сизми калмас иде укытучы апа.

*(Ләлә Гыймадиевадан)* ***(163 сүз)***

### 8 вариант җаваплары

| Кыска изложение өчен текст турында белешмә | |
|---|---|
| **Абзац номеры** | **Микротемалар (мәгънәви кисәкләр)** |
| 1 | Минем беренче укытучым гел мәктәптә булды. |
| 2 | Гадилә апа минем укуым белән кызыксынып торды. |
| 3 | Укытучымның хәлеен белергә вакыт таба алмадым. |
| 4 | Гадилә апа миңа бик сөенде. |

**II бүлек**
**2 – 8 нче бирем**

| Биремнәр | Җаваплар |
|---|---|
| 2 | 2 |
| 3 | 1 |
| 4 | 1, 4 |
| 5 | балачактагы |
| 6 | 4 |
| 7 | 2 |
| 8 | диск |

## 9 нчы вариант
## I бүлек

***Текстны тыңлагыз һәм 1 нче биремне 2 нче номерлы җаваплар бланкында эшләгез. Башта биремнең номерын, аннары изложение текстын языгыз.***

**1** Текстны тыңлагыз һәм кыска изложение языгыз.

Текстны тыңлагач, микротемаларны билгеләгез.

Тулы текстның һәм андагы микротемаларның төп эчтәлеген бирергә кирәклеген истә тотып эшләгез.

Изложениенең күләме 70 сүздән ким булмаска тиеш.

Изложениене чиста һәм танырлык итеп языгыз.

## II бүлек

***2 – 8 нче биремнәрнең җавабы сүз яки цифрлар булырга мөмкин. Башта җавапны текстта күрсәтегез, соңыннан 1 нче номерлы бланкка бүш ара калдырмыйча, тыныш билгеләрсез, башка өстәмә символларсыз күчереп алыгыз. Һәр хәрефне һәм санны, бланктагы үрнәктә күрсәтелгәнчә, аерым шакмакка языгыз.***

**2** Текстны укыгыз.

1) Яз башы, авыл тирәсендәге үзән-тауларда ашыкмыйча күченә-күченә көтү йөргәнен күзәтеп тору миңа бик кызык тоела иде. 2) Кыш буе ябулы ятып үшәнгән, ябага йоннарын коя-коя яшел ут-үлән артыннан йөгерешкән малларга карау аерата бер рәхәт. 3) Бу мескеннәр дә кысан, пычрак абзар, кысан кура-киртәләрдән ireккә чыкты дип, күңелең сөенеп туймый.. 4) Ә алар, бәхетлеләр, буын-сыннарын яза-яза бәэлдәшеп, бер яшеллектән икенчесенә чабышалар. 5) Җиләннәре ап-ак сөт белән тула. *(С. Моратбәков)*

Җөмләләрнең **оештыручы үзәкләре (грамматик нигезләре, баш кисәкләре)** дөрес күрсәтелгән очракны билгеләгез. Җавап номерын языгыз.

41) көтү йөргәнен күзәтеп тору (1 нче җөмлә)
42) яшел ут-үлән артыннан йөгерешкән (2 нче җөмлә)
43) ireккә чыкты дип (3 нче җөмлә)
44) бер яшеллектән икенчесенә чабышалар (4 нче җөмлә)
45) җиләннәре тула (5 нче җөмлә)

Җавап: ________________ .

**3** Текстны укыгыз.

**Рәт гармониясе сакланмаган** сүзләр кулланылган җөмләне табыгыз. Җавап номерын языгыз.

| |
|---|
| 1) Ошбу җиһанда яшәгәч, тереклек иткәч, һәркемнең тормышында үзенә бер куанычы, сөенече, мактанычы һәм дә горурлыгы була инде ул. 2) Ә минем мактанычым, куанычым, горурлыгым әтием булды. 3) Мин аны бүген дә, үз оныкларымның дәү әтие булгач та, өзелеп сагынам. |

Җавап:_____ .

**4** Текстны укыгыз.

**Сызык** куелырга тиешле җөмләләрне табыгыз. Җавап номерларын языгыз.

| |
|---|
| 3) Менә ул минем туган ягым! 2) Аны күрү колачлау өчен чама белгән биеклек кирәк. 3) Арырак бу манзараның икенче каты. 4) Боларны инде тагын да биегрәк киртләч сукмаклы итәгендәге кучкар-кучкар таш арасыннан җидешәр унар толымлы чишмәләр бәреп чыкканы куеннарыннан шәрә тезле кызчыклар кебек җитәкләшеп каеннар менеп барганы Язулы тау, Дегет тавы, Ял таулары! (*Г. Хәсәнов*) |

Җавап: _____.

**5** Текстны укыгыз.

**Артыклык дәрәҗәсендәге сыйфатны** табып языгыз.

| |
|---|
| Күтәрелгән саен тау сырты куе томаннан арына бара иде. Ниһаять, алар аның түбәсенә менеп җиттеләр. Шунда зәп-зәңгәр булып күк йөзе ачылып китте, әйтерсең, яңгыр аны юа-юа шулай саф үз төсенә кайтарган иде. |

Җавап: ________________ .

| |
|---|
| ***Текстны укыгыз һәм 6-9 нчы биремнәрне үтәгез.*** |

1) Кыш буе әбисе тәрәзә кырыннан китмәде. 2) Озаграк авырган чакта Ләйлә дә шулай тәрәзә тупсасына утырып, урамны күзәтергә ярата. 3) Әмма әбисенең шәһәр тормышында исе юк бугай, аның карашы еракка, бик еракка – офыкка төбәлгән, ә йөзе – шундый да моңсу.

4) – Нәрсә бар соң анда, әбием? – дип сорады беркөн Ләйлә бик тә зур сер ачасы килеп.

5) – Авылым! – диде әбисе авыр сулап.

6) Кызчык аяк очларына басып карача да, әбисенең авылын тапмады.

7) – Кая, кая соң ул, нигә мин күрмим?–дип көйсезләнә үк башлады.

8) – Аны күрер өчен күңел күзе кирәк шул, бәбкәм! – дип оныгының башыннан сыйпады әбисе.

9) Кызык, анысы тагын нинди күз була икән, дип гаҗәпләнде кызчык.

10) Түбәләрдән тып-тып тамчылар тама башлагач, әбисенә җан керде. 11) Ләйлә еш салкын тидереп чирләп интектергәч, кышкылыкка оныгын карашырга авылдан алып килгәннәр иде аны. 12) Шәһәргә һич кенә дә күңеле ятмады әбисенең.

13) – Алла боерса, сукмак төшү белән кайтып китәм, Ләйләне дә алырмын, шәһәр һавасы ярамый аңа. 14) Авыл каймагы белән сөтен эчсә, шалкан кебек таза булыр, – дип канатланып йөрде, хәтта төенчеген дә төйнәп куйды.

15) Әтисенең исә моңа хәтере калды.

16) – Әллә бер-бер авыр сүз әйтеп рәнҗеттекме, нигә шулай ашкынасың? - дип төпченде.

17) – Күрмисеңмени, әбием авылын сагынган, – дип Ләйлә әбисен якламакчы булып сүзгә кушылды.

18) – Нәрсәсен сагынасың инде аның! – дип элеп алды әтисе бераз ачуланган сыман. 19)– Балаларың янында, урының җылыда, түрдә, көрт көрәп, су ташып, пычрак ерып йөрисе юк. 20) Оҗмах рәхәте бит!

21) – И, улым, – дип сыкранды әбисе, – гомер иткән оям бит ул, кәкре казыгына кадәр йөрәккә якын. 22) Ничек шуны аңламыйсың! 23) Күрмисеңмени, җаным коштай талпына!

24) – Күрмим, күрәсем дә килми,–дип сүзне кырт кисмәкче булды әтисе.

25) – Күрергә күңел күзе кирәк бит аны!–дип әйтеп салды шулчак Ләйлә.

(Резедә Шәриповадан*)

* ***Резедә Шәрипова*** (1962) – язучы.

**6** **Текстның эчтәлегенә туры** килгән җөмләне күрсәтегез. Җавап номерын языгыз.

1) Әби кышын авылда үткәрә.
2) Әби авылын сагына.
3) Ләйлә авылга кайтты.
4) Ләйләнең әтисе шатлана.
5) Ләйләнең авылга кайтасы килми.

Җавап: ________________ .

**7** **Фразеологик әйтелмә** кулланылган җөмләне күрсәтегез. Җавап номерын языгыз.

1) Кыш буе әбисе тәрәзә кырыннан китмәде.

2) – Нәрсә бар соң анда, әбием? – дип сорады беркөн Ләйлә бик тә зур сер ачасы килеп.

3) – Аны күрер өчен күңел күзе кирәк шул, бәбкәм! – дип оныгының башыннан сыйпады әбисе.

4) Ләйлә еш салкын тидереп чирләп интектергәч, кышкылыкка оныгын карашырга авылдан алып килгәннәр иде аны.

5) Ничек шуны аңламыйсың!

Җавап: ________________ .

**8** 9-12 нче җөмләләрдән ***авырып*** сүзенең синонимын табып, күчереп языгыз.

Җавап: ____________ .

***2-8 нче биремнәрнең җавапларын, тестны үтәү өчен күрсәтмәдә әйтелгән тәртиптә, 1 нче номерлы бланкка күчереп язарга һәм җавапның бирем номеры күрсәтелгән юлга язылуын тикшерергә онытмагыз.***

## III бүлек

***2 нче бүлектә укылган текстны файдаланып, 9.1 яки 9.2 нче биремнәрнең <u>бары тик берсен генә сайлап алып</u>, 2 нче номерлы бланкта биремне үтәгез. Яза башлар алдыннан сайланган биремнең номерын күрсәтегез.***

**9.1** **“ – И, улым, – дип сыкранды әбисе, – гомер иткән оям бит ул, кәкре казыгына кадәр йөрәккә якын. Ничек шуны аңламыйсың! Күрмисеңмени, җаным коштай талпына!”** җөмләләрендә әйтелгән фикерне ничек аңлыйсыз? Шулар турында языгыз. Фикерегезне раслау өчен, укылган тексттан **2 мисал** китерегез.

Файдаланган җөмләләрнең номерларын языгыз яки тексттан цитата китерегез.

Сочинениенең күләме **70 сүздән** дә ким булмаска тиеш.

Укылган текстка таянып язылмаган эшкә билге куелмый.

Бирелгән текстны күчереп яисә аның эчтәлеген аңлатмаларсыз язган өчен ноль балл куела.

Сочинениене чиста һәм танырлык итеп языгыз.

**9.2**

**Күңел күзе** төшенчәсен ничек аңлыйсыз? “**Күңелең ак булса, йөзең шат булыр**” темасына сочинение языгыз. Фикерегезне языгыз. Раслау өчен, укылган тексттан **1 мисал**, үзегезнең тормыш тәҗрибәсеннән **1 мисал** китерегез.

Сочинениенең күләме **70 сүздән** дә ким булмаска тиеш.

Укылган текстка таянып язылмаган эшкә билге куелмый.

Бирелгән текстны күчереп яисә аның эчтәлеген аңлатмаларсыз язган өчен ноль балл куела.

Сочинениене чиста һәм танырлык итеп языгыз.

## I бүлек

***Тыңлау өчен текст***

### Балыкларны коткаручылар

Көннәрдән бер көнне балыкчылар каргаларны каравылга – балыкларны сакларга куярга булдылар. Кәҗәне кәбестәгә, песине каймакка якын китермәскә икәнлеген һәммәбез дә биш бармагы кебек беләә. Ә менә балыкчылар нигәдер каргаларга балыкларны ышанып тапшырдылар. Каян башларына килгән диген?!

Кыш көне су асты дөньясында караңгылык хакимлек итә. Кыш ахырларына таба балыклар, авызларын ачып, көчкә-көчкә кыймылдыйлар. Һава җитми, суларга кыен аларга. Боз астында кислород бетеп килә, ә боз өстендә һава керердәй бер ярык-тишек тә юк. Күр дә тор, тиздән балыклар көтүләре белән кырыла башлаячак. Кул кушырып карап торсаң, балыксыз калуың бар.

Менә каргаларның файдасы кайчан тиде.

Су астында һава бетә башлагач, балыклар бәке авызына җыелалар да авызларын судан чыгаралар. Моны күреп, төрле яклардан бәке яннарына каргалар җыела башлый. Балыкчылар балыкларның эшләре хөрти икәнне шуннан беләләр дә инде. Әмма авыз ачып тормыйлар, ломнар, балталар эләктерәләр дә тизрәк балыкларны коткарырга ашыгалар. Су астына саф һава керсен өчен, боз өстендә күп итеп бәкеләр тишәләр. Шулай итеп, каргалар сигналы балыкчыларны дәррәү аякка бастыра. Каргалар да сынатмыйлар, алар да үткен күзле, ышанычлы каравылчылардан бер дә ким түгелләр. Күргәнегезчә, балыклар язмышын ышанып тапшырырга була икән үзләренә.

*(Николай Сладковтан)* ***(175 сүз)***

## 9 вариант җаваплары

| Кыска изложение өчен текст турында белешмә | |
|---|---|
| **Абзац номеры** | **Микротемалар (мәгънәви кисәкләр)** |
| 1 | Балыкчылар каргаларны каравылга куярга булдылар. |
| 2 | Кыш көне балыкларга һава җитми. |
| 3 | Балыкларның хәле начар икәнен күреп, балыкчылар бәке тишәләр. |

**II бүлек**
**2 – 8 нче биремнәр**

| Биремнәр | Җаваплар |
|---|---|
| 2 | 5 |
| 3 | 1 |
| 4 | 3, 4 |
| 5 | зәп-зәңгәр |
| 6 | 2 |
| 7 | 3 |
| 8 | чирләп |

## 10 нчы вариант
## I бүлек

***Текстны тыңлагыз һәм 1 нче биремне 2 нче номерлы җаваплар бланкында эшләгез. Башта биремнең номерын, аннары изложение текстын языгыз.***

**1** Текстны тыңлагыз һәм кыска изложение языгыз.
Текстны тыңлагач, микротемаларны билгеләгез.

Тулы текстның һәм андагы микротемаларның төп эчтәлеген бирергә кирәклеген истә тотып эшләгез.

Изложениенең күләме 70 сүздән ким булмаска тиеш.

Изложениене чиста һәм танырлык итеп языгыз.

## II бүлек

***2 – 8 нче биремнәрнең җавабы сүз яки цифрлар булырга мөмкин. Башта җавапны текстта күрсәтегез, соңыннан 1 нче номерлы бланкка бүш ара калдырмыйча, тыныш билгеләрсез, башка өстәмә символларсыз күчереп алыгыз. Һәр хәрефне һәм санны, бланктагы үрнәктә күрсәтелгәнчә, аерым шакмакка языгыз.***

**2** Текстны укыгыз.

1) Их, гармун, гармун! 2) Сине яшьлегендә кулына алып, уйнап карамаган, яисә сыздырып-сыздырып уйнаучыга карап моңланмаган кеше бар микән? 3) Уйната да, җырлата да, юата да ул гармун! 4) Безнең татар авыллары гомер-гомергә үзенең оста гармунчылары белән дан тоткан. 5) Бер генә мәҗлес тә, бер генә тантана да гармуннан башка узмый иде. 6) Хәер, бүген дә бәйрәмнәрдә, сабантуйларда, авыл эшчәннәре очрашканда, туйларда гармун тавышлары еш яңгырый. *(М. Абдуллиннан)*

Җөмләләрнең **оештыручы үзәкләре (грамматик нигезләре, баш кисәкләре)** дөрес күрсәтелгән очракны билгеләгез. Җавап номерын языгыз.

46) яшьлегендә кулына алып карамаган (2 нче җөмлә)
47) ул гармун (3 нче җөмлә)
48) гармунчылары белән дан тоткан (4 нче җөмлә)
49) мәҗлес тә, тантана да узмый иде (5 нче җөмлә)
50) бүген дә бәйрәмнәрдә (6 нчы җөмлә)

Җавап: ________________ .

**3** Текстны укыгыз.

**Рәт гармониясе сакланмаган** сүзләр кулланылган җөмләне табыгыз. Җавап номерын языгыз.

| |
|---|
| 1) Гомеремдә беренче тапкыр авылымны ташлап чыгуымны сөйлим әле. 2) Җәйнең бик матур бер көнендә Хәлимә апа мине үзләренең авылына кунакка алып китте. 3) Минем улым синең белән яшьтәш, аның гармуны да, велосипеды да бар, икәүләп уйнарсыз, дип кызыктыргач, мин дә, әнкәй дә ризалаштык. |

Җавап:_____ _ ___________ ________________ .

**4** Текстны укыгыз.

**Өтерләр** куелырга тиешле җөмләләрне табыгыз. Җавап номерларын языгыз.

| |
|---|
| 4) Самолет биеклек алды барысы да топография картасындагы шартлы билге сыман шакмакларга әйләнде. 2) Туган җир артта калды. 3) Шулай да рух җиңеләеп китте. 4) Алда билгесез мәшәкатьләр билгесез кешеләр билгесез очрашулар көтә иде. (*Г. Хәсәнов*) |

Җавап: _______________ .

**5** Текстны укыгыз.

**Ясалма сыйфатны** табып языгыз.

| |
|---|
| Мин Агыйделнең еракларга төбәлеп торган Төбә яры өстендә битләремне астан искән җылы, чәчәкле болын җиленә куеп басып торам. Күз күреме җирләрдә болын да әрәмә; ә шулар эченнән, ярдан ярга тибеп, колындай уйнаклап, Агыйделем ага. |

Җавап: ________________ .

| |
|---|
| ***Текстны укыгыз һәм 6-9 нчы биремнәрне үтәгез.*** |

1) Дөньяда иң тәмле ризык нәрсә?

2) Әгәр бу хакта Галәү бабайдан сорасагыз, ул ике дә уйламыйча:

– Көлгә күмеп пешергән бәрәңге, – дияр.

3) Тик бүген Инсафның тамагыннан аш үтми. 4) Башында һаман бер уй, бер кайгы: аның өч ел буе назлап-иркәләп үстергән тае, ак бәкәлле елгыр кара айгыры югалды. 5) Тартай болынында башка атлар белән утлап йөргән җиреннән, шүрәле урлагандай юкка чыкты. 6) Шул кыбырсыкны эзләп, атна-ун

көн эчендә айкамаган урман-кыры, әйләнмәгән болын-тугае калмады малайның. 7) Инде тәмам төшләренә керә башлады. 8) Имештер, аның айгыры канатлы акбүз атлар өеренә баш булып алган да, шулар белән бергәләп, өем-өем ак болытлар арасында зәп-зәңгәр печән утлап йөри. 9) Менә бер заман ул Инсафны күреп ала да көмеш кыңгырау чыңлагандай яңгыравык аваз белән кешнәп җибәрә. 10) Аннары, кара ефәктәй бөдрә ялларын җилдә тузгытып, озын-озын, салмак-салмак ыргылып, түбән төшә башлый. 11) Ләкин төшеп җитүгә, ап-ак ефәк оекбаш төсле ак бәкәлләрен, ялтыр кара тоякларын күз иярмәс тизлек белән уйнатып, өермәдәй чабып китә. 12) Бөдрә яллары Инсафның йөзенә сирпелеп кенә кала. 13) Артыннан куа-куа малай хәлдән тая, шабыр тиргә батып уяна…

14) Галәү бабай Инсафның хәлен яхшы аңлый.

15) – Кайгырма, улым, хафаланма ул тикле, – дип, үзенчә тынычландырырга тырыша ул аны. 16) – Кайта, беркая да китми синең таең. 17) Кадерле ул туган як. 18) Кешегә генә түгел, хайванга да изге ул туган җир туфрагы…

19) Бераздан Галәү бабай, малайлар белән бергәләп, Идел ярындагы карама төбенә йокларга ятты. 20) Болын җиле тәмле печән исе, җиләкле аланнар исе алып килде. 21) Караманың яфраклары, ашыга-ашыга, нәрсәдер пышылдашып алдылар. 22) Моңсу гына тулы ай күтәрелде. 23) Ул, ботакларны аралап, кешеләргә күз төшереп алды.

24) Әйе, барысы да йокыда. 25) Оеп, изрәп йоклыйлар. 26) Тик Инсаф кына йокы аралаш елмая, куанып көлә… 27) Җиләс җилләр канатында ерак-ераклардан аңа бик таныш, бик тансык авазлар агылып килә. 27) Көмеш кыңгыраулар авазы!

29) Һәм колак төбендә һаман бер үк сүзләр яңгырый:

— Кадерле ул туган як. 30) Кешегә генә түгел, хайванга да изге ул туган җир туфрагы.

(Габделхәй Сабитовтан*)

**Габделхәй Сабитов* (1931 - 1995) – татар драматургы, язучы.

**6** **Текстның эчтәлегенә туры** килгән җөмләне күрсәтегез. Җавап номерын языгыз.

1) Инсаф көлгә күмгән бәрәңге ярата.
2) Ак бәкәлле елгыр кара айгырны Инсаф болынга алып килде.
3) Инсафның тәрбияләп үстергән тае югалды.
4) Туган якны яратырга кирәк.
5) Инсаф йоклаганда, тай аның янына килде.

Җавап: ________________ .

**7** **Фразеологик әйтелмә** кулланылган җөмләне күрсәтегез. Җавап номерын языгыз.

1) Дөньяда иң тәмле ризык нәрсә?
2) Тик бүген Инсафның тамагыннан аш үтми.
3) Кайта, беркая да китми синең таең.
4) Моңсу гына тулы ай күтәрелде.
5) Тик Инсаф кына йокы аралаш елмая, куанып көлә…

Җавап: ________________ .

**8** 1-5 нче җөмләләрдән ***ашап*** сүзенең синонимын табып, күчереп языгыз.

Җавап: ____________ .

***2-8 нче биремнәрнең җавапларын, тестны үтәү өчен күрсәтмәдә әйтелгән тәртиптә, 1 нче номерлы бланкка күчереп язарга һәм җавапның бирем номеры күрсәтелгән юлга язылуын тикшерергә онытмагыз.***

## III бүлек

***2 нче бүлектә укылган текстны файдаланып, 9.1 яки 9.2 нче биремнәрнең <u>бары тик берсен генә сайлап алып</u>, 2 нче номерлы бланкта биремне үтәгез. Яза башлар алдыннан сайланган биремнең номерын күрсәтегез.***

**9.1** **“– Кайта, беркая да китми синең таең. Кадерле ул туган як. Кешегә генә түгел, хайванга да изге ул туган җир туфрагы.”**җөмләләрендә әйтелгән фикерне ничек аңлыйсыз? Шулар турында языгыз. Фикерегезне раслау өчен, укылган тексттан **2 мисал** китерегез.

Файдаланган җөмләләрнең номерларын языгыз яки тексттан цитата китерегез.

Сочинениенең күләме **70 сүздән** дә ким булмаска тиеш.

Укылган текстка таянып язылмаган эшкә билге куелмый.

Бирелгән текстны күчереп яисә аның эчтәлеген аңлатмаларсыз язган өчен ноль балл куела.

Сочинениене чиста һәм танырлык итеп языгыз.

**9.2** **Туган як кадере** әйтеменең мәгънәсен ничек аңлыйсыз? “**Туган җирем – изге җир**” темасына сочинение языгыз. Фикерегезне языгыз. Раслау өчен, укылган тексттан **1 мисал**, үзегезнең тормыш тәҗрибәсеннән **1 мисал** китерегез.

Сочинениенең күләме **70 сүздән** дә ким булмаска тиеш.

Укылган текстка таянып язылмаган эшкә билге куелмый.

Бирелгән текстны күчереп яисә аның эчтәлеген аңлатмаларсыз язган өчен ноль балл куела.

Сочинениене чиста һәм танырлык итеп языгыз.

## I бүлек

| *Тыңлау өчен текст* |
|---|

### Әтиемнең эш бүлмәсе

Әтиемнең үзенә генә бер бүлмәсе бар. Эш бүлмәсе ди аны әтием. Анда кәгазьләр бик күп. Китаплар... Әтием заводта инженер булып эшли. Эш бүлмәсенә кермәгез, ди ул безгә. Әтием кушмагач, без анда кермибез.

Беркөнне әтием эшкә чыгып китте. Әнием дә өйдә юк иде. Карасам, әтиемнең эш бүлмәсе ачык калган. Мин әкрен генә аның ишеген ачып карадым. Безнең Ләйсән исемле бик шаян бер песиебез бар. Менә шул песи әтиемнең эш өстәленнән кирәкле кәгазьләрен тартып төшергән дә, рәхәтләнеп кыштырдата-кыштырдата, идәндә уйнап ята.

Мин язуларны өстәлгә алып куйдым. Ә песине куалап чыгардым. Ишекне япкан идем, куркып киттем. Ә песи тагын керсә? Уенчыкларымны алып килдем дә әтиемнең эш бүлмәсе янында уйный башладым.

Уйный торгач, йоклап киткәнмен. Кухняда аш пешереп йөргән әбием дә мине күрмәгән. Әтием күтәреп алгач кына уянып киттем. Ул эштән кайткан икән.

– Нишләп син монда килеп йокладың, кызым? – ди.

– Әтием, мин бүген каравылда тордым. Синең бүлмәң ачык калган иде, мин шуны сакладым, – дидем.

*(Әминә Бикчәнтәевадан)* ***(150 сүз)***

### 10 вариант җаваплары

| Кыска изложение өчен текст турында белешмә | |
|---|---|
| **Абзац номеры** | **Микротемалар (мәгънәви кисәкләр)** |
| 1 | Әтиемнең үз эш бүлмәсе бар. |
| 2 | Эш бүлмәсенә песи кергән. |
| 3 | Мин әтиемнең эш бүлмәсен саклыйм. |

## II бүлек
## 2 – 8 нче биремнәр

| **Биремнәр** | **Җаваплар** |
|---|---|
| 2 | 4 |
| 3 | 3 |
| 4 | 1, 4 |
| 5 | чәчәкле |
| 6 | 3 |
| 7 | 2 |
| 8 | утлап |

# ИМТИХАННЫ БӘЯЛӘҮ КРИТЕРИЙЛАРЫ

## I бүлек

### Кыска изложениене бәяләү критерийлары

| № | Критерий | Балл |
|---|---|---|
| **ИК1** | **Изложениенең эчтәлеге** | |
| | Укучы тыңлаган текстның эчтәлеген тулы ачкан, анда яктыртылган **барлык** мәсьәләләр язмада урын алган. | 2 |
| | Текстның эчтәлеге ачылган,<br>**әмма** бер микротема төшеп калган (яки өстәлгән). | 1 |
| | Текстның эчтәлеге ачылган,<br>**әмма** бердән артык микротема төшеп калган (яки өстәлгән). | 0 |
| **ИК2** | **Башлангыч текстны җыйнакландыру** | |
| | Укучы текстның гомуми эчтәлеген бер яки берничә алым белән кыскарткан, җыйнакландырган | 3 |
| | Бер яки берничә алым белән текстның ике микротемасын җыйнакландырган | 2 |
| | Бер яки берничә алым белән текстның бер микротемасы җыйнакландырылган | 1 |
| | Текстны җыйнакландыру өчен бер алым да **кулланылмаган** | 0 |
| **ИК3** | **Изложениенең мәгънә бөтенлеге, бәйләнешле сөйләм һәм аның эзлеклелеге** | |
| | Укучының эшендә мәгънә бөтенлеге, сөйләмнең бәйләнешле һәм эзлекле булуы күзәтелә:<br>- логик хаталар юк, эзлеклелек бозылмаган;<br>- текст кызыл юлларга дөрес бүленгән | 2 |
| | Эштә мәгънә бөтенлеге, сөйләмнең бәйләнешле һәм эзлекле булуы күзәтелә,<br>**әмма** бер логик хата бар<br>**яки** кызыл юлны билгеләүдә бер хата бар | 1 |
| | Эштә коммуникатив (аралашуга караган) мәгънә сакланган,<br>**әмма** бердән артык логик хата<br>**яки** кызыл юлны билгеләүдә ике хата җибәрелгән | 0 |
| **ИК1-ИК3 күрсәткечләре буенча изложение өчен җыела торган иң югары балл** | | **7** |

## II бүлек
### 2 – 8 нче биремнәрне тикшерү критерийлары

Икенче бүлектәге һәр биремгә дөрес җавап биргән өчен укучыга **берәр балл** куела. Җавап инструкциядә күрсәтелгәнчә эшләнсә һәм тулысынча

тиешле җавап белән тәңгәл килгән очракта, дөрес үтәлгән дип исәпләнә. Җавап ялгыш булса яки бөтенләй булмаса, **0 балл** куела

## III бүлек
## 9 нчы биремне тикшерү критерийлары

### 9.1 нче биремне бәяләү критерийлары
### 9.1 биременә җавап түбәндәге критерийлар буенча бәяләнә.

| № | Текст эчтәлеген анализлауга бәйле темага язылган сочинениене (9.1) бәяләү критерийлары | Баллар |
|---|---|---|
| **$С_1К1$** | **Тексттан алынган кисәкнең мәгънәсен аңлау** | |
| | Имтихан бирүче тексттан алынган кисәкнең эчтәлеген дөрес аңлаткан. Аңлатмада хаталар юк. | 2 |
| | Имтихан бирүче тексттан алынган кисәкнең эчтәлеген гомумән дөрес аңлаткан,<br>**ләкин** аңлатмада 1 хатасы бар. | 1 |
| | Имтихан бирүче тексттан алынган кисәкнең эчтәлеген дөрес аңлатмаган,<br>**яки** имтихан бирүче, тексттан алынган кисәкнең эчтәлеген аңлатканда, 2 яки күбрәк хата ясаган,<br>**яки** тексттан алынган кисәк эчтәлегенең аңлатмасы язма эштә юк. | 0 |
| **$С_1К2$** | **Дәлил-мисалларның булуы** | |
| | Имтихан бирүче тексттан әлеге кисәкнең эчтәлегенә туры килә торган 2 дәлил-мисал китергән. | 3 |
| | Имтихан бирүче тексттан әлеге кисәкнең эчтәлегенә туры килә торган 1 дәлил-мисал китергән. | 2 |
| | Имтихан бирүче башка тексттан дәлил-мисаллар (-лар) китергән. | 1 |
| | Имтихан бирүче әлеге кисәкнең эчтәлеген аңлата торган дәлил-мисал китермәгән,<br>**яки** имтихан бирүче биремдәге цитатаны я аның бер өлешен дәлил-мисал итеп китергән. | 0 |
| **$С_1К3$** | **Язманың мәгънәви бөтенлеге, сөйләм бәйләнешлелеге, язу эзлеклелеге** | |
| | Имтихан бирүченең эше мәгънәви бөтенлеге, сөйләм бәйләнешлелеге һәм язу эзлеклелеге белән характерлана:<br>– логик хаталар юк, язуда эзлеклелек бозылмаган;<br>– абзацларга бүленештә хаталар юк. | 2 |

| | | |
|---|---|---|
| | Имтихан бирүченең эше мәгънәви бөтенлеге, сөйләм бәйләнешлелеге һәм эзлеклелек белән характерлана, **ләкин** 1 логик хатасы бар, **һәм/яки** абзацларга бүленештә **1** урында хата бар. | 1 |
| | Язмада сөйләм үстерүгә омтылыш бар, **ләкин** логик хаталарның саны 1 дән артык, **һәм/яки** абзацларга бүленештә **2** урында хата бар. | 0 |
| **$С_1$К4** | **Эшнең композицион бөтенлеге** | |
| | Эш композицион яктан бөтен һәм төгәлләнгән, текст төзүдә хаталар юк. | 2 |
| | Эш композицион яктан бөтен һәм төгәлләнгән, **ләкин** текст төзүдә 1 хатасы бар. | 1 |
| | Текст төзүдә 2 яки күбрәк хатасы бар. | 0 |
| **$С_1$К1-$С_1$К4 критерийлары буенча сочинение өчен иң югары балл** | | **9** |

**Игътибар!**

Әгәр сочинениедә текст күчереп кенә язылса яки анда текстның эчтәлеге генә чагылыш тапса, бәяләүнең барлык критерийлары буенча ($С_1$К2-$С_1$К4) **0 балл** белән бәяләнә.

Әгәр сочинениедәге текст фрагменты 9.1 дәге тексттан алынмыйча, башка текстган алынса, бәяләүнең барлык критерийлары буенча ($С_1$К2-$С_1$К4) **0 балл** белән бәяләнә

**Язма эшнең грамоталылыгы һәм аның фактик төгәллеге** аерым бәяләнә (6 нчы таблицаны кара).

**9.2 нче биремне бәяләү критерийлары**

**9.2 биременә җавап түбәндәге критерийлар буенча бәяләнә.**

| № | Текст эчтәлеген анализлауга бәйле темага язылган сочинениене (11.2) бәяләү критерийлары | Баллар |
|---|---|---|
| **$С_3$К1** | **Тексттан алынган кисәкнең мәгънәсен аңлау** | |
| | Имтихан бирүче (сочинениенең теләсә кайсы өлешендә теге яки бу формада) аңлатма биргән һәм киңәйтелгән формада тасвирлаган. | 2 |
| | Имтихан бирүче (сочинениенең теләсә кайсы өлешендә теге яки бу формада) аңлатма биргән, **ләкин** киңәйтелгән формада тасвирламаган. | 1 |
| | Имтихан бирүче ялгыш аңлатма биргән, **яки** төшенчәгә аңлатмасы язма эштә юк. | 0 |
| **$С_3$К2** | **Дәлил-мисалларның булуы** | |

| | | |
|---|---|---|
| | Имтихан бирүче 2 дәлил-мисал китергән, шуларның берсе укылган тексттан, икенчесе – тормыш тәҗрибәсеннән **яки** имтихан бирүче 2 дәлил-мисал китергән, шуларның икесе дә укылган тексттан. | 3 |
| | Имтихан бирүче укылган тексттан 1 дәлил-мисал китергән. | 2 |
| | Имтихан бирүче тормыш тәҗрибәсеннән дәлил-мисаллар (-лар) китергән. | 1 |
| | Имтихан бирүче бер генә дәлил-мисал да китермәгән. | 0 |
| $С_3К3$ | **Язманың мәгънәви бөтенлеге, сөйләм бәйләнешлелеге, язу эзлеклелеге** | |
| | Имтихан бирүченең эше мәгънәви бөтенлеге, сөйләм бәйләнешлелеге һәм язу эзлеклелеге белән характерлана:<br>– логик хаталар юк, язуда эзлеклелек бозылмаган;<br>– абзацларга бүленештә хаталар юк. | 2 |
| | Имтихан бирүченең эше мәгънәви бөтенлеге, сөйләм бәйләнешлелеге һәм эзлеклелек белән характерлана,<br>**ләкин** 1 логик хатасы бар,<br>**һәм/яки** абзацларга бүленештә **1** урында хата бар. | 1 |
| | Язмада сөйләм үстерүгә омтылыш бар,<br>**ләкин** логик хаталарның саны 1 дән артык,<br>**һәм/яки** абзацларга бүленештә **2** урында хата бар. | 0 |
| $С_3К4$ | **Эшнең композицион бөтенлеге** | |
| | Эш композицион яктан бөтен һәм төгәлләнгән, текст төзүдә хаталар юк. | 2 |
| | Эш композицион яктан бөтен һәм төгәлләнгән,<br>**ләкин** текст төзүдә 1 хатасы бар. | 1 |
| | Текст төзүдә 2 яки күбрәк хатасы бар. | 0 |
| **$С_3К1$-$С_3К4$ критерийлары буенча сочинение өчен иң югары балл** | | **9** |

**Игътибар!**

Әгәр сочинениедә текст күчереп кенә язылса яки анда текстның эчтәлеге генә чагылыш тапса, бәяләүнең барлык критерийлары буенча ($С_3К2$-$С_3К4$) **0 балл** белән бәяләнә.

Әгәр сочинение 9.2 дәге сүз яки гыйбарәгә туры килмәсә, бәяләүнең барлык критерийлары буенча ($С_1К2$-$С_1К4$) **0 балл** белән бәяләнә.

Язма эшнең грамоталылыгы һәм аның фактик төгәллеге аерым бәяләнә (6 нчы таблицаны кара).

| № | Укучы сөйләменең грамоталылыгын һәм фактик төгәллеген бәяләү критерийлары | Баллар |
|---|---|---|
| **ГК1** | **Орфографик нормаларның үтәлеше** | |
| | Орфографик хаталары юк **яки** хатасы 1 дән артык түгел | 2 |

| | | |
|---|---|---|
| | 2-3 хата җибәрелгән | 1 |
| | Хаталарының саны 4 тән артык | 0 |
| **ГК2** | **Пунктуацион нормаларның үтәлеше** | |
| | Пунктуацион хаталары юк **яки** хатасы 2 дән артык түгел | 2 |
| | 3-4 хатасы бар | 1 |
| | Хаталарының саны 5 тән артык | 0 |
| **ГК3** | **Грамматик нормаларның үтәлеше** | |
| | Грамматик хаталары юк **яки** 1 хатасы бар | 2 |
| | 2 хатасы бар | 1 |
| | Хаталарының саны 3 тән артык | 0 |
| **ГК4** | **Сөйләм нормаларының үтәлеше** | |
| | Сөйләм хаталары юк **яки** хатасы 2 дән артык түгел | 2 |
| | 3–4 хатасы бар | 1 |
| | Хаталарының саны 5 тән артык | 0 |
| **ФК1** | **Язма сөйләмнең фактик төгәллеге** | |
| | Материалны язмада бирүдә, шулай ук аңлауда һәм терминнар кулланылышында фактик хаталар юк | 2 |
| | Материалны язмада бирүдә яки терминнар кулланылышында 1 хата бар | 1 |
| | Материалны язмада бирүдә яки терминнар кулланылышында 2 хата бар | 0 |
| **ГК1-ГК4, ФК1 критерийлары буенча сочинение өчен иң югары балл** | | **10** |

Грамоталылыкны бәяләгәндә, **изложение һәм сочинениенең күләмен** исәпкә алырга кирәк.

6 нчы таблицада китерелгән нормативлар гомуми күләме 140 тан артык сүз булган изложение һәм сочинениеләрне тикшерү өчен кулланыла.

Әгәр **изложение һәм сочинениеләрнең** гомуми күләме 70-139 сүз булса, ГК1-ГК4, ФК1 критерийлары буенча 1 баллдан артык куелмый:

ГК – 1 буенча орфографик хаталар булмаса яки 1 тупас булмаган хата булганда 1 балл куела;

ГК – 2 буенча пунктуацион хаталар булмаса яки 1 тупас булмаган хата булганда 1 балл куела;

ГК – 3 буенча грамматик хаталар булмаганда 1 балл куела;

ГК – 4 буенча сөйләм хаталары булмаганда 1 балл куела.

ФК1 – буенча фактик хаталар һәм терминнар кулланылышында хаталар булмаганда 1 балл куела.

Әгәр **изложение һәм сочинениеләрнең** гомуми күләме 69 гына сүз булса, мондый эшләргә ГК1-ГК4, ФК1 критерийлары буенча 0 балл куела.

Әгәр укучы иҗади эшнең бары тик берсен генә (я изложение, я сочинение) үтәсә, ГК1-ГК4, ФК1 критерийлары буенча бәяләү шулай ук эшнең күләменнән чыгып башкарыла:

Әгәр эш 140 яки аннан артыграк сүздән торса, грамоталылык 6 нчы таблица нигезендә бәяләнә.

Эшнең күләме 70-139 сүздән торса, ГК1-ГК4, ФК1 критерийлары буенча 1 баллдан артык куелмый (югары күрсәтелгәнчә).

Әгәр эшнең күләме 69 сүздән артмаса, мондый эшләргә ГК1-ГК4, ФК1 критерийлары буенча 0 балл куела.

Дәүләт йомгаклау аттестациясен тулаем башкару барышында җыярга мөмкин булган максималь балл – **33.**

**Имтихан эше өчен түбәндәге билгеләр куела:**

0-14 балл – «2» ле билгесе;

15-22 балл – «3» ле билгесе;

23-28 балл – «4» ле билгесе. Искәрмә: бу очракта укучының ГК1-ГК4 критерийлары буенча баллары 4 тән кимрәк булмаска тиеш.

29-33 балл – «5» ле билгесе. Искәрмә: бу очракта укучының ГК1-ГК4 критерийлары буенча баллары 6 дан кимрәк булмаска тиеш.

## 82 НЧЕ КОД БУЕНЧА БИРЕМНӘР

### Рус телендә гомуми белем бирү оешмаларының татар төркемнәрендә укучылар өчен 2023 нче елда туган (татар) телдән дәүләт йомгаклау аттестациясен уздыру материаллары

### Эшне башкару өчен күрсәтмә

Рус телендә гомуми белем бирү оешмаларның татар төркемнәрендә белем алып, 9 нчы сыйныфны тәмамлаучы укучыларга туган (татар) телдән дәүләт йомгаклау аттестациясе өчен 3 сәгать 55 минут (235 минут) вакыт бирелә.

Имтихан эше үз эченә 8 биремне алган ике бүлектән гыйбарәт.

**Беренче бүлек** 7 биремнән (1-7) тора. Беренче бүлектәге биремнәр сүзләр, җөмләләр, текстны анализлауны таләп итә. Әлеге биремнәрнең җаваплары сүз (сүзтезмә) яки цифрлар белән җаваплар бланкына языла. Соңыннан 1 нче номерлы җавап бланкына күчерелә.

**Икенче бүлектәге** бирем 1 нче бүлек биремнәрен эшләгәндәге текст буенча башкарыла. Эшли башлаганчы, **тәкъдим ителгән биремнәрнең (8.1 һәм 8.2) БЕРСЕН ГЕНӘ сайларга** һәм үз фикереңне дәлилләп, эзлекле рәвештә киңәйтелгән җавап бирергә кирәк. Әлеге бирем 2 нче номерлы җавап бланкында эшләнә.

Бланкларны тутырганда, кара гель яки капилляр ручка кулланырга рөхсәт ителә.

Имтиханда орфографик сүзлекләрдән файдаланырга рөхсәт ителә.

Биремнәрне караламада эшләргә була, әмма андагы һәм тикшерү материалларындагы язулар билге куйганда исәпкә алынмый.

Үтәлгән биремнәр өчен куелган баллар бергә кушыла. Мөмкин кадәр күбрәк биремгә дөрес җавап биреп, югарырак балл җыярга тырышыгыз.

Эшләп бетергәч, 1 нче һәм 2 нче җавап бланкындагы һәр җавапның дөрес номер янында язылуын тагын бер тапкыр тикшерегез.

**Сезгә уңышлар телибез!**

## БЕРЕНЧЕ ВАРИАНТ

### I бүлек

***1-7 нче биремнәрнең җавапларын сүз (берничә сүз) яки цифрлар белән языгыз. Һәр хәреф яки цифр бланктагы үрнәктәгечә аерым шакмакка язылырга тиеш. Сүзләр яки цифрлар буш шакмак калдырмыйча, өтерсез һәм башка тамгаларсыз языла.***

**1** ***Синтаксик анализ.***

Текстны укыгыз.

(1) Нәниләр зур дулкынлану белән мәктәпкә килеп җиттеләр. (2) Менә олысы-кечесе өчен тантаналы минут җитте. (3) Йөзләрчә балалар сыйныфларга кереп киттеләр. (4) Мәктәп коридорлары бушап калды. (5) Һәр җирдә зур эшләр башлаганда була торган тынлык урнашты.

**Баш кисәкләр** дөрес билгеләнгән җавап вариантларының номерларын языгыз.

1) нәниләр килеп җиттеләр (1 нче җөмлә)
2) олысы-кечесе җитте (2 нче җөмлә)
3) балалар кереп киттеләр (3 нче җөмлә)
4) мәктәп бушап калды (4 җөмлә)
5) тынлык урнашты (5 нче җөмлә)

Җавап: ______________________________.

**2** ***Пунктуацион анализ.***

**Тыныш билгеләрен куегыз.** Өтер куелырга тиеш урыннарның цифрларын языгыз.

*Кадерлеләрем (1) барыгыз (2) бәхетле юл (3) сезгә!*

Җавап: ______________________________.

**3** ***Синтаксик анализ.***

**Чыгыш килеше** кушымчасы ярдәмендә бәйләнгән сүзтезмәне табып языгыз.

*Күк йөзе болытлардан бөтенләй арынган иде.*

Җавап: ______________________________.

**4** ***Орфографик анализ.***

Язылышы дөрес аңлатылмаган сүзләрнең номерларын языгыз.

1) **БОЛГАНЧЫК** – о хәрефе сүзнең беренче иҗегендә генә языла.

2) **МАЭМАЙ** – [э] авазы, беренче иҗек азагында килгәндә, э хәрефе белән языла.

3) **ӘҢГӘМӘ** – ң хәрефе сүз башында язылмый.

4) **МӘГЪНӘ** – иҗек ахырында килгән г хәрефен калын уку өчен, ъ хәрефе языла.

5) **СӘГАТЬ** – иҗек башында килгән г хәрефен нечкә уку өчен, ь хәрефе языла.

Җавап: ___________________________.

***Текстны укыгыз һәм 5-7 нче биремнәрне үтәгез.***

(1) Шундый да күрекле. (2) Борынгы римлеләр «Кверкус» дип белми әйтмәгәннәр. (3) Бу исә – матур дигән сүз. (4) Матур да, нык та агач ул. (5) Имәнгә охшаталар ирнең асылын. (6) Ул имән кебек нык, диләр.

(7) Аның берсен үземне белә башлаганнан бирле күрә киләм. (8) Үзе аръякта, тугай уртасында ук, ә үзе әллә кайдан күренә. (9) Бер Алып батыр диярсең! (10) Үзен ник бер агач ышыкласын, үзе җил-давылларга бирешми. (11) Җәй коры килсә дә, аңа да исе китми. (12) Тамырлары тирәндә булгач, нәрсә ул аңа корылык!

(13) Минем өч улым буйга житеп килә. (14) Алар да бу имәнгә минем күк сокланып карарлар. (15) Аннары – оныкларым... (16) Имән ул чагында тәмам картаер, аннары... юк булыр. (17) Агач та мәңге яшәми. (18) Тик ул да үзенә яшь алмаш калдырыр.

(19) Имәннәр чикләвекләре белән генә түгел, сабаклар җибәреп тә үрчиләр. (20) Мин бу хәлне күптәннән күзәтә киләм. (21) Ничек күзәтәм дигәндә, кайчандыр әлеге имән белән янәшә икенче берсе шаулап утыра иде. (22) Ә быел аны яшен сукты. (23) Бөтен кәүсәсен көйдереп, яндырып төште. (24) Корыган имәнне кистеләр. (25) Ләкин күпмедер көннәрдән соң имән төбеннән ямь-яшел үрентеләр шытып чыкты. (26) Бу, әлбәттә, табигый хәл: кайчандыр зур печән кибәненә охшап утырган имәннең бөреләре күп санлы ботак-чатакларында гына түгел, төбендә дә булганнар. (27) Алар имән бик нәни вакытта ук яралганнар. (28) Имән ел саен юанайган, ел саен өскә үрләгән. (29) Ә астагы бөреләр изрәп йоклый биргәннәр.

(30) Имән үзе юк инде. (31) Ләкин «нинди биек булмасын, тамыры җирдә», –дип, агач турында дөрес әйтә халык. (32) Тамырлар буенча аккан тереклек суы әлеге бөреләрне уятты, аларга яшәү көче бирде. (33) Озакламый бөтен тирә-юньгә яшь яфраклар җыры таралды. (34) Әнә шулай итеп имән яңадан яши башлады.

(35) Яшь имәннәргә карыйм да мин, карт имәнне искә төшерәм. (36) Никадәр чикләвекләр өлгертте. (37) Ул чикләвекләрдән никадәр яшь агачлар үсеп шаулады. (38) Аз гына шул имәнгә охшаса икән дә, үзе турында шул имән кебек матур истәлекләр калдырса икән кеше!

*(Г. Хәсәновтан*)*

**Гарәфи Хәсәнов* *(1921-1990) – күренекле татар язучысы, тәрҗемәче.*

**5** ***Текстның эчтәлеген анализлау.***

Текстның эчтәлегенә туры килә торган җөмләләрнең номерларын языгыз.

1) Бер имән агачын бик күптәннән беләм.
2) Имән бик ерактан күренеп тора.
3) Минем өч оныгым бар.
4) Имән агачында яшел яфраклар үсеп чыкты.
5) Чикләвекләрдән бернинди имән үсмәде.

Җавап: ___________________________.

**6** ***Сәнгатьлелек чараларын анализлау.***

Фразеологик әйтелмә кулланылган җөмләләрнең номерларын языгыз.

1) Аның берсен үземне белә башлаганнан бирле күрә киләм.
2) Җәй коры килсә дә, аңа да исе китми.
3) Алар да бу имәнгә минем күк сокланып карарлар.
4) Минем өч улым буйга житеп килә.
5) Имән ел саен юанайган, ел саен өскә үрләгән.

Җавап: ___________________________.

**7** ***Лексик анализ.***

Тексттан «гомерлек» сүзенә синоним булган сүзне табып языгыз.

Җавап: ___________________________.

***Барлык җавапларны, эшне башкару буенча күрсәтмәдә әйтелгәнчә, 1 нче номерлы бланкка күчереп язарга онытмагыз. Һәр җавапның тиешле бирем номеры язылган юлда булуын тикшерегез.***

## II бүлек

**8.1** **«Аз гына шул имәнгә охшаса икән дә, үзе турында шул имән кебек матур истәлекләр калдырса икән кеше!»** Текст ахырында китерелгән бу сүзләрнең мәгънәсен аңлатып, сочинение языгыз.

Укылган тексттан фикерләрегезне раслый торган **ике** дәлил китерегез.

Мисаллар биргәндә, кирәкле җөмләләрне языгыз яисә аларның номерларын күрсәтегез.

Сочинениенең күләме 90 сүздән ким булмаска тиеш.

Әгәр сочинение сөйләп чыгу яки чыганак текстны аңлатуларсыз тулысынча күчереп язу формасында гына булса, мондый эш 0 балл белән бәяләнә.

Сочинениене пөхтә һәм аңлаешлы итеп языгыз.

**8.2** **ИМӘН КЕБЕК НЫК** гыйбарәсен ничек аңлыйсыз? Үзегез формалаштырган билгеләмәне дәлилләгез. Үзегез язган билгеләмәне тезис итеп алып, **«Нинди кешене имән кебек нык дип була?»** темасына сочинение языгыз. Тезисыгызны раслый торган **ике** дәлил китерегез: дәлилнең **берсен** укылган тексттан алыгыз, **икенчесен** тормыш тәҗрибәгездән чыгып формалаштырыгыз.

Әгәр сочинение сөйләп чыгу яки чыганак текстны аңлатуларсыз тулысынча күчереп язу формасында гына булса, мондый эш 0 балл белән бәяләнә.

Сочинениенең күләме 90 сүздән ким булмаска тиеш.

Сочинениене пөхтә һәм аңлаешлы итеп языгыз.

***Һәр җавапның тиешле бирем номеры язылган юлда булуын тикшерегез.***

**ҖАВАПЛАР**

| Биремнең номеры | Дөрес җавап |
|---|---|
| 1 | 135 |
| 2 | 12 |
| 3 | болытларданарынганиде |
| 4 | 25 |
| 5 | 124 |
| 6 | 24 |
| 7 | мәңге |

## ИКЕНЧЕ ВАРИАНТ

### I бүлек

***1-7 нче биремнәрнең җавапларын сүз (берничә сүз) яки цифрлар белән языгыз. Һәр хәреф яки цифр бланктагы үрнәктәгечә аерым шакмакка язылырга тиеш. Сүзләр яки цифрлар буш шакмак калдырмыйча, өтерсез һәм башка тамгаларсыз языла.***

**1** ***Синтаксик анализ.***
Текстны укыгыз.

(1) Табигатьтә көз билгеләре көннән-көн күзгә күбрәк чалыналар. (2) Карлыгачлар, шәүлегәннәр җылы якларга инде очып китте. (3) Җәнлекләр тормышында да зур үзгәрешләр бар. (4) Барысының да балалары үсеп җитте. (5) Хәзер алар үз белдекләре белән көн итәләр.

**Баш кисәкләр** дөрес билгеләнгән җавап вариантларының номерларын языгыз.

1) көз чалыналар (1 нче җөмлә)
2) карлыгачлар, шәүлегәннәр очып китте (2 нче җөмлә)
3) җәнлекләр бар (3 нче җөмлә)
4) балалары үсеп җитте (4 җөмлә)
5) алар көн итәләр (5 нче җөмлә)

Җавап: **_____________________________**.

**2** ***Пунктуацион анализ.***
**Тыныш билгеләрен куегыз.** Өтер куелырга тиеш урыннарның цифрларын языгыз.

*Болытлар безгә таба кузгалдылар да (1) эсседән көйгән киң болынны талгын күләгәләре белән рәхәтләндерделәр (2) бик аз гына сибәләп (3) кара урманга таба үттеләр.*

Җавап: **_____________________________**.

**3** ***Синтаксик анализ.***
**Төшем килеше** кушымчасы ярдәмендә бәйләнгән сүзтезмәне табып языгыз.

*Ул аларны, бик яратып, игътибар белән тыңлады.*

Җавап: **_____________________________**.

| 4 |
|---|

***Орфографик анализ.***

Язылышы дөрес аңлатылмаган сүзләрнең номерларын языгыз.

1) **БАВЫРСАК** – [у] авазы в хәрефе белән языла.
2) **ИГЪЛАН** – г хәрефен [ғ] авазы дип уку өчен ъ хәрефе языла.
3) **ҺАВА** – [w] авазы, ике сузык арасында килгәндә, в хәрефе белән языла.
4) **ТИЗ ГЕНӘ** – генә – кисәкчә, шуңа күрә ул аерым языла.
5) **ВӘГЪДӘСЕЗЛЕК** – кушма сүзләрдә ъ хәрефе языла.

Җавап: ____________________________.

| ***Текстны укыгыз һәм 5-7 нче биремнәрне үтәгез.*** |
|---|

(1) Иртәгә Яңа ел диясе көнне шугалакта дүрт-биш малайдан башка берәү дә юк иде. (2) Фәрит, рәшәткә янында туктап, аларны карап торды. (3) Малайлар җиңел шуалар, ак бүрекле, сигез-тугыз яшьләрендәге малай гына башкаларга караганда начаррак шуа.

(4) Берничә минуттан соң инде Фәрит боз өстендә, малайлар арасында иде. (5) Ул ак бүрекле малай белән бик тиз дуслашып китте. (6) Алар икәү бергә бик озак шудылар. (7) Аннары кар өемнәре өстенә кадап куелган аю, бүре, төлке сурәтләрен карап йөрделәр.

(8) Әллә инде җил чыкты, алар туңа башладылар. (9) Фәрит пальтосын төймәләде, ә ак бүрекле малай пальтосын да төймәләде, кесәсендәге бияләен дә алып киде.

(10) – Әйдә, киттек, кем узар? – диде ул.

(11) Ә үзе, Фәритне көтмичә, кулларын ашыгып бутый-бутый, шугалак эченә таба шуып та китте.

(12) Фәрит, ак бүрекле малайның бу кыланышын яратмыйча, яңадан рәсемнәр арасына борылды. (13) Ул рәсемнәр арасына барып җитәргә дә өлгермәде, аның күзенә җирдә аунап яткан бер кәгазь чалынды. (14) Фәрит, кызыксынып, кәгазьне кулына алды… һәм шатлыгыннан чак кына кычкырып җибәрмәде: елка билеты бу, елка билеты! (15) Фәрит билетны кулына тоткан килеш уйга калды. (16) Ак бүрекле малайныкы түгелме икән? (17) Билетны күрсәтергә дип, малай артыннан шуып китте. (18) Фәрит шугалак уртасына да барып җитмәде, күңеленең икенче почмагыннан ниндидер бер явыз уй калкып чыкты. (19) Башта ул, Фәритнең намуслылыгын капшап караган шикелле, кыюсыз гына кыймылдады, аннары, әкренләп, аның барлык яхшы ниятләрен җимерергә тотынды.(20) Ул, билетны күрсәтү фикереннән кайтып, рәшәткәнең җимерек урынына таба борылды. (21) Фәрит билетны кичкә кадәр берничә мәртәбә бик җентекләп карады. (22) Билетның эчке ягына «Мидхәт Шакиров» дип язылган.

(23) Фәрит Яңа ел көнне, бик яхшылап юынып, яңа киемнәрен киеп, клубка китте. (24) Ул кулындагы билетын ишек төбендәге абыйга сузды. (25) Абый аның билетын ачып карады һәм сорады:

– Исем-фамилияң ничек?

(26) Фәрит башта аптырап калды һәм яңгыравык тавыш белән әйтте:

– Мидхәт Шакиров.

(27) Фәрит шундый ышандырырлык итеп әйтте, ләкин абый ышанмады. (28) Ул кемгәдер ишарә ясады, Фәрит тә шул якка таба борылып карады. (29) Аннан Фәритләр классы укытучысы Сәлим абый Шакиров ишеккә таба туп-туры килә иде. (30) Фәрит шунда ук барысын да аңлады һәм кып-кызыл булды. (31) Ул шундый оялды, шундый оялды, җир тишегенә кереп китәрлек иде. (32) Укытучы абый аңа, һәрвакыттагыча, тыныч тавышы белән:

– Мине күргәч, исәнләшергә кирәк иде, нигә исәнләшмисең? – диде. (33) – Аннары беркайчан да ялганнарга ярамый. (34) Ялганлау – бик начар нәрсә ул…

(35) Фәрит укытучы абыйга күтәрелеп карый да, хәтта телен дә кузгата алмады.

*(А. Шамовтан*)*

**__Афзал Шамов__ (1901-1990) – күренекле татар язучысы, педагог, публицист һәм тәрҗемәче.*

**5** ***Текстның эчтәлеген анализлау.***

Текстның эчтәлегенә туры килә торган җөмләләрнең номерларын языгыз.

1) Шугалакта бер малай да юк иде.
2) Фәрит пальтосының төймәләрен ычкындырды.
3) Фәрит рәсемнәр арасында билет тапты.
4) Фәрит билетны үзенә алып калды.
5) Фәрит Яңа ел көнне бәйрәмгә барды.

Җавап: ____________________________.

**6** ***Сәнгатьлелек чараларын анализлау.***

Фразеологик әйтелмә кулланылган җөмләләрнең номерларын языгыз.

1) Фәрит, рәшәткә янында туктап, аларны карап торды.
2) Билетны күрсәтергә дип, малай артыннан шуып китте.
3) Фәрит билетны кичкә кадәр берничә мәртәбә бик җентекләп карады.
4) Ул шундый оялды, шундый оялды, җир тишегенә кереп китәрлек иде.
5) Фәрит укытучы абыйга күтәрелеп карый да, хәтта телен дә кузгата алмады.

Җавап: ____________________________.

**7** ***Лексик анализ.***

Тексттан «ансат» сүзенә синоним булган сүзне табып языгыз.

Җавап: ____________________________.

***Барлык җавапларны, эшне башкару буенча күрсәтмәдә әйтелгәнчә, 1 нче номерлы бланкка күчереп язарга онытмагыз. Һәр җавапның тиешле бирем номеры язылган юлда булуын тикшерегез.***

## II бүлек

**8.1** **«Ялганлау – бик начар нәрсә ул».** Текстта китерелгән бу сүзләрнең мәгънәсен аңлатып, сочинение языгыз.

Укылган тексттан фикерләрегезне раслый торган **ике** дәлил китерегез.

Мисаллар биргәндә, кирәкле җөмләләрне языгыз яисә аларның номерларын күрсәтегез.

Сочинениенең күләме 90 сүздән ким булмаска тиеш.

Әгәр сочинение сөйләп чыгу яки чыганак текстны аңлатуларсыз тулысынча күчереп язу формасында гына булса, мондый эш 0 балл белән бәяләнә.

Сочинениене пөхтә һәм аңлаешлы итеп языгыз.

**8.2** **ЯЛГАН** сүзен ничек аңлыйсыз? Үзегез формалаштырган билгеләмәне дәлилләгез. Үзегез язган билгеләмәне тезис итеп алып, **«Нинди кешене ялганчы дип була?»** темасына сочинение языгыз. Тезисыгызны раслый торган **ике** дәлил китерегез: дәлилнең **берсен** укылган тексттан алыгыз, **икенчесен** тормыш тәҗрибәгездән чыгып формалаштырыгыз.

Әгәр сочинение сөйләп чыгу яки чыганак текстны аңлатуларсыз тулысынча күчереп язу формасында гына булса, мондый эш 0 балл белән бәяләнә.

Сочинениенең күләме 90 сүздән ким булмаска тиеш.

Сочинениене пөхтә һәм аңлаешлы итеп языгыз.

***Һәр җавапның тиешле бирем номеры язылган юлда булуын тикшерегез.***

## Дөрес җаваплар

| Биремнең номеры | Дөрес җавап |
|---|---|
| 1 | 245 |
| 2 | 23 |
| 3 | аларнытыңлады |
| 4 | 15 |
| 5 | 345 |
| 6 | 45 |
| 7 | җиңел |

## ӨЧЕНЧЕ ВАРИАНТ

## I бүлек

***1-7 нче биремнәрнең җавапларын сүз (берничә сүз) яки цифрлар белән языгыз. Һәр хәреф яки цифр бланктагы үрнәктәгечә аерым шакмакка язылырга тиеш. Сүзләр яки цифрлар буш шакмак калдырмыйча, өтерсез һәм башка тамгаларсыз языла.***

**1** ***Синтаксик анализ.***
Текстны укыгыз.

(1) Җәйге аяз көннәрнең берсендә без әрәмәлеккә җиләккә киттек. (2) Менә кинәт көньяктан күксел болыт күтәрелде. (3) Бераздан кап-кара болыт бөтен күк йөзен каплап алды. (4) Көчле яңгыр ява башлады. (5) Без бер агачка ышыкландык, ләкин яңгырдан котыла алмадык.

**Баш кисәкләр** дөрес билгеләнгән җавап вариантларының номерларын языгыз.

1) без киттек (1 нче җөмлә)
2) болыт күтәрелде (2 нче җөмлә)
3) болыт алды (3 нче җөмлә)
4) яңгыр ява башлады (4 җөмлә)
5) без ышыкландык (5 нче җөмлә)

Җавап: ______________________________.

**2** ***Пунктуацион анализ.***
**Тыныш билгеләрен куегыз.** Өтер куелырга тиеш урыннарның цифрларын языгыз.
*Сорыкортлар (1) бал җыеймыйлар (2) бик юашлар (3) чага да белмиләр.*

Җавап: ______________________________.

**3** ***Синтаксик анализ.***
**Урын-вакыт килеше** кушымчасы ярдәмендә бәйләнгән сүзтезмәне табып языгыз.
*Урамнарда төрле төстәге электр лампалары яна.*

Җавап: ______________________________.

**4** ***Орфографик анализ.***
Язылышы дөрес аңлатылмаган сүзләрнең номерларын языгыз.

1) **ЙӨГЕРЕК** – [й] һәм [ө] авазлары рәттән килгәндә, һәрвакыт ике хәреф языла.

2) **АКСАКАЛ** – кушма сүз, шуңа күрә кушылып языла.
3) **МЕҢЬЯФРАК** – иҗекне нечкә уку өчен, ь хәрефе языла.
4) **БӘРЕЛӘ-СУГЫЛА** – парлы сүз, шуңа күрә ул сызыкча аша языла.
5) **СӘГАТЬНЕ** – г хәрефен [г] авазы дип уку өчен ь хәрефе языла.

Җавап: ____________________________.

***Текстны укыгыз һәм 5-7 нче биремнәрне үтәгез.***

(1) Болындагы чәчәкләр, уянып, таң нурында иркәләнеп күзләрен ачтылар.

(2) Чү, нинди тавыш бу? (3) Кем шулай чыңлап уятты аларны?!

(4) Үз тавышына игътибар итүләрен күреп, кыңгырау чәчәк тагын чыңлап куйды: «Тең-тең-тең!». (5) Шунда гына чәчәкләр үзләре янында үсеп утырган зәңгәр төстәге чәчәкне күреп алдылар. (6) «Күр әле, искитәрлек бер җире юк, ә үзе нинди яңгыравык, нинди моңлы тавыш чыгара!» – дип пышылдашты алар үзара.

(7) Ә кыңгырау чәчәк, туып килгән якты көнгә сокланып, иртәнге җыр сузды: «Теңә-теңә, тең-тең-тең, теңтеңгел-теңгелә!» (8) Тирә-юньдәге чәчәкләр, сокланып, аның җырын тыңладылар. (9) Җыр беткәч, шатланышып кул чаптылар.

(10) Алкышлардан кыңгырау чәчәкнең башы әйләнеп китте һәм бии-бии такмаклый башлады.

(11) Аның җырына башка чәчәкләр дә кушылды. (12) Болында җырлы бию, күңел ачу башланды. (13) Җыр, бию көне буе дәвам итәсе иде дә бит. (14) Әмма... (15) Шунда бер кечкенә чәчәк, көнләшеп, хәйлә белән кыңгырау чәчәккә сүз кушты:

– Кара әле, кыңгырау чәчәк! (16) Син нигә бирედә әрәм булып яшисең? (17) Бар, тизрәк авылга йөгер, үзеңне кешеләр күрсеннәр. (18) Монда сиңа чын бәя бирүче булмас!

(19) Кыңгырау чәчәк аның хәйләсен белми иде шул. (20) Шуңа да бу сүзләрдән масая башлады:

– Әйе, әйе, син дөрес әйтәсең. (21) Кем биредә минем белән ярыша ала. (22) Юк, миң кат юк!

(23) Кыңгырау чәчәк, алны-артны карамый, авылга җилдерде. (24) Җырлары белән кешеләрне сокландырасы килде аның. (25) Кыңгырау чәчәк юл уңаенда сыер, сарык һәм кәҗәләр алдында да мактанып алырга уйлады һәм җыр башлады. (26) Ләкин аны тыңлаучы булмады. (27) Алай гына да түгел, бер кәҗә аны кабып йотты һәм тәменнән канәгать калып, мәэлдәп куйды.

(28) Менә шулай, мактану, масаю яхшыга илтми. (29) Ә сез ничек, мактанмыйсызмы?!

*(Ф. Зарифтан*)*

*****Фирдәвес Зариф*** *(1961) – татар язучысы, журналист.*

| 5 | ***Текстның эчтәлеген анализлау.*** |
|---|---|

Текстның эчтәлегенә туры килә торган җөмләләрнең номерларын языгыз.

1) Үз тавышына игътибар итмәүләрен күреп, чәчәк чыңлап куйды.
2) Чәчәк, якты көнгә сокланып, иртәнге җыр сузды.
3) Аның җырына башкалар кушылды.
4) Кечкенә чәчәк, көнләшеп, кыңгырау чәчәккә эндәшмәде.
5) Кыңгырау чәчәкнең кешеләрне сокландырасы килде.

Җавап: ______________________________.

**6** ***Сәнгатьлелек чараларын анализлау.***
Фразеологик әйтелмә кулланылган җөмләләрнең номерларын языгыз.

1) Чәчәкләр үзләре янында үсеп утырган зәңгәр чәчәкне күреп алдылар.
2) Җыр беткәч, шатланышып кул чаптылар.
3) Алкышлардан кыңгырау чәчәкнең башы әйләнеп китте.
4) Аның җырына башка чәчәкләр дә кушылды.
5) Болында җырлы бию, күңел ачу башланды.

Җавап: ______________________________.

**7** ***Лексик анализ.***
Тексттан «назланып» сүзенә синоним булган сүзне табып языгыз.

Җавап: ______________________________.

***Барлык җавапларны, эшне башкару буенча күрсәтмәдә әйтелгәнчә, 1 нче номерлы бланкка күчереп язарга онытмагыз. Һәр җавапның тиешле бирем номеры язылган юлда булуын тикшерегез.***

## II бүлек

**8.1** **«Менә шулай, мактану, масаю яхшыга илтми».**Текстта китерелгән бу сүзләрнең мәгънәсен аңлатып, сочинение языгыз.

Укылган тексттан фикерләрегезне раслый торган **ике** дәлил китерегез.

Мисаллар биргәндә, кирәкле җөмләләрне языгыз яисә аларның номерларын күрсәтегез.

Сочинениенең күләме 90 сүздән ким булмаска тиеш.

Әгәр сочинение сөйләп чыгу яки чыганак текстны аңлатуларсыз тулысынча күчереп язу формасында гына булса, мондый эш 0 балл белән бәяләнә.

Сочинениене пөхтә һәм аңлаешлы итеп языгыз.

**8.2** **МАКТАНУ** сүзен ничек аңлыйсыз? Үзегез формалаштырган билгеләмәне дәлилләгез. Үзегез язган билгеләмәне тезис итеп алып, **«Нинди кешене мактанчык дип була?»** темасына сочинение языгыз. Тезисыгызны раслый торган **ике** дәлил китерегез: дәлилнең **берсен** укылган тексттан алыгыз, **икенчесен** тормыш тәҗрибәгездән чыгып формалаштырыгыз.

Әгәр сочинение сөйләп чыгу яки чыганак текстны аңлатуларсыз тулысынча күчереп язу формасында гына булса, мондый эш 0 балл белән бәяләнә.

Сочинениенең күләме 90 сүздән ким булмаска тиеш.

Сочинениене пөхтә һәм аңлаешлы итеп языгыз.

***Һәр җавапның тиешле бирем номеры язылган юлда булуын тикшерегез.***

**Дөрес җаваплар**

| **Биремнең номеры** | **Дөрес җавап** |
|---|---|
| 1 | 124 |
| 2 | 23 |
| 3 | урамнардауяна |
| 4 | 35 |
| 5 | 235 |
| 6 | 35 |
| 7 | иркәләнеп |

## ДҮРТЕНЧЕ ВАРИАНТ

### I бүлек

***1-7 нче биремнәрнең җавапларын сүз (берничә сүз) яки цифрлар белән языгыз. Һәр хәреф яки цифр бланктагы үрнәктәгечә аерым шакмакка языларга тиеш. Сүзләр яки цифрлар буш шакмак калдырмыйча, өтерсез һәм башка тамгаларсыз языла.***

**1** ***Синтаксик анализ.***
Текстны укыгыз.

(1) Карлы, буранлы суык кыш килде. (2) Кыр һәм болыннарны ак кар каплады. (3) Агачлар, куаклар һәм агач төпләре ап-ак кар бүрекләр киде. (4) Кар кояш яктысында җемелди, төрле төсләргә кереп ялтырый. (5) Еш кына көчле җил исә.

**Баш кисәкләр** дөрес билгеләнгән җавап вариантларының номерларын языгыз.

1) кыш килде (1 нче җөмлә)
2) кар каплады (2 нче җөмлә)
3) бүрекләр киде (3 нче җөмлә)
4) кояш җемелди, ялтырый (4 җөмлә)
5) җил исә (5 нче җөмлә)

Җавап: ______________________________.

**2** ***Пунктуацион анализ.***
**Тыныш билгеләрен куегыз.** Өтер куелырга тиеш урыннарның цифрларын языгыз.

*Ниһаять (1) бер фикергә килдек (2) бу эшне тикшерер өчен (3) өч кешедән комиссия төзергә булдык.*

Җавап: ______________________________.

**3** ***Синтаксик анализ.***
**Төшем килеше** кушымчасы ярдәмендә бәйләнгән сүзтезмәне табып языгыз.

*Көз килде дә каен яфракларын сап-сары буяуга манып китте.*

Җавап: ______________________________.

**4** ***Орфографик анализ.***
Язылышы дөрес аңлатылмаган сүзләрнең номерларын языгыз.

1) **III ГАСЫР** – рим цифрларыннан соң кушымчалар язылмый, сызыкча да куелмый.
2) **УНДҮРТ** – кушма саннар кушылып языла.

3) **КАЛӘМ** – [къ] авазын белдерү өчен, к хәрефеннән соң а языла.

4) **КАНӘГАТЬ** – иҗек башында килгән г хәрефен нечкә уку өчен, ь хәрефе языла.

5) **КОТОЧКЫЧ** – о хәрефе татар телендә сүзнең беренче һәм икенче иҗегендә языла.

Җавап: ____________________________.

***Текстны укыгыз һәм 5-7 нче биремнәрне үтәгез.***

(1) Биек тау сыртында, бик күренекле урында – ниндидер бер пыяла ватыгы, ә арырак, ком-балчык арасында затлы асылташ ята икән. (2) Шулай туры килгән ки, пыяла ватыгына көнозын кояш карый, кояш нуры төшә дә пыяла ватыгыбыз күзләрне камаштырып ялтырый. (3) Кешеләр аңа һәрвакыт сокланып карап үтәләр икән. (4) Ә асылташ ком-балчык арасында ята, аның затлы нурлары берәүнең дә күзенә чагылмый.

(5) Мактанмаган көне юк икән пыяла ватыгының:

– Бигрәк мескен син, асылташ. (6) Кеше күзенә күренердәй нурың да, бу дөньяда юньле генә урының да юк. (7) Ятасың шунда ком астында мүкләнеп. (8) Ә мине күр, ничек нур чәчәм! (9) Бу дөньядагы урыным да иң күренекле төштә минем!

(10) – Үз урыныңмы икән соң ул? – ди асылташ. (11) – Үзең түгел, шул урының гына балкый түгелме икән?

(12) – Чү-чү! (13) Син минем урынга өметеңне сузма! – ди пыяла ватыгы. (14) Мине бу урынымда берәү дә алыштыра алмый.

(15) – Мин дә хәзергә нәкъ үз урынымда, – ди асылташ. (16) – Биредә мин кояштан һәм олы тау күкрәгеннән үземә чын нурлар җыям. (17) Килер вакыты, мин дә балкырмын.

(18) Һәм ул вакыт җиткән.

(19) Көннәрдән бер көнне кеше бу биек тау сыртына да менеп җиткән. (20) Менеп җитүгә, әлбәттә, иң элек пыяла ватыгына үрелгән. (21) Аннары, чын-чынлап эзли торгач, асылташны да табып алган.

(22) Кеше асылташтан искиткеч гүзәл нурлар чәчүче йолдыз ясаган. (23) Бу йолдыз хәзер дә иң зур мәйданнарның берсендә, иң биек манарада кешеләрне сокландырып балкып тора. (24) Ә пыяла ватыгын кеше ваклап төйгән дә, тагын ниндидер ком-ташлар кушып, үзенең коралларын үткерли торган кайрак ясаган.

(25) Асылташ белән пыяла ватыгы, әнә шулай, үзләренең чын урыннарына утырганнар.

*(Р.Төхфәтуллиннан*)*

**Рафаил Төхфәтуллин* *(1924-1994) – татар язучысы.*

| 5 | ***Текстның эчтәлеген анализлау.*** |
|---|---|

Текстның эчтәлегенә туры килә торган җөмләләрнең номерларын языгыз.

1) Пыяла ватыгы һәм затлы асылташ тау сыртында яткан.
2) Кешеләр пыяла ватыгына сокланып караганнар.
3) Пыяла ватыгы бер дә мактанмаган.
4) Асылташ кояштан үзенә нурлар җыйган.
5) Кеше иң элек асылташны күреп алган.

Җавап: ____________________________.

**6** ***Сәнгатьлелек чараларын анализлау.***
Фразеологик әйтелмә кулланылган җөмләләрнең номерларын языгыз.

1) Пыяла ватыгы күзләрне камаштырып ялтырый.
2) Ә асылташ ком-балчык арасында ята.
3) Син минем урынга өметеңне сузма!
4) Кеше бу биек тау сыртына да менеп җиткән.
5) Аннары, чын-чынлап эзли торгач, асылташны да табып алган.

Җавап: ____________________________.

**7** ***Лексик анализ.***
Тексттан «шапырынмаган» сүзенә синоним булган сүзне табып языгыз.

Җавап: ____________________________.

***Барлык җавапларны, эшне башкару буенча күрсәтмәдә әйтелгәнчә, 1 нче номерлы бланкка күчереп язарга онытмагыз. Һәр җавапның тиешле бирем номеры язылган юлда булуын тикшерегез.***

## II бүлек

**8.1** **«Үзең түгел, шул урының гына балкый түгелме икән?»** Текстта китерелгән бу сүзләрнең мәгънәсен аңлатып, сочинение языгыз.

Укылган тексттан фикерләрегезне раслый торган **ике** дәлил китерегез.

Мисаллар биргәндә, кирәкле җөмләләрне языгыз яисә аларның номерларын күрсәтегез.

Сочинениенең күләме 90 сүздән ким булмаска тиеш.

Әгәр сочинение сөйләп чыгу яки чыганак текстны аңлатуларсыз тулысынча күчереп язу формасында гына булса, мондый эш 0 балл белән бәяләнә.

Сочинениене пөхтә һәм аңлаешлы итеп языгыз.

**8.2** **ҮЗ УРЫНЫҢ** гыйбарәсен ничек аңлыйсыз? Үзегез формалаштырган билгеләмәне дәлилләгез. Үзегез язган билгеләмәне тезис итеп алып, **«Нинди кешене үз урынын тапкан дип була?»** темасына сочинение языгыз. Тезисыгызны раслый торган **ике** дәлил китерегез: дәлилнең **берсен** укылган тексттан алыгыз, **икенчесен** тормыш тәҗрибәгездән чыгып формалаштырыгыз.

Әгәр сочинение сөйләп чыгу яки чыганак текстны аңлатуларсыз тулысынча күчереп язу формасында гына булса, мондый эш 0 балл белән бәяләнә.

Сочинениенең күләме 90 сүздән ким булмаска тиеш.

Сочинениене пөхтә һәм аңлаешлы итеп языгыз.

***Һәр җавапның тиешле бирем номеры язылган юлда булуын тикшерегез.***

**Дөрес җаваплар**

| Биремнең номеры | Дөрес җавап |
|---|---|
| 1 | 125 |
| 2 | 13 |
| 3 | яфракларынманыпкитте |
| 4 | 45 |
| 5 | 124 |
| 6 | 13 |
| 7 | мактанмаган |

## БИШЕНЧЕ ВАРИАНТ

### I бүлек

***1-7 нче биремнәрнең җавапларын сүз (берничә сүз) яки цифрлар белән языгыз. Һәр хәреф яки цифр бланктагы үрнәктәгечә аерым шакмакка язылырга тиеш. Сүзләр яки цифрлар буш шакмак калдырмыйча, өтерсез һәм башка тамгаларсыз языла.***

**1** ***Синтаксик анализ.***
Текстны укыгыз.

(1) Мин күл ярына килдем. (2) Ярдан эчкәрегә таба киң генә басма салынган. (3) Аны имән казыклар белән ныгытканнар. (4) Басма кырыенда судан яртылаш чыгарылган бәләкәй генә, җыйнак кына көймә ята. (5) Ә күл шактый киң.

**Баш кисәкләр** дөрес билгеләнгән җавап вариантларының номерларын языгыз.

1) мин килдем (1 нче җөмлә)
2) басма салынган (2 нче җөмлә)
3) аны ныгытканнар (3 нче җөмлә)
4) басма ята (4 җөмлә)
5) күл киң (5 нче җөмлә)

Җавап: ______________________________.

**2** ***Пунктуацион анализ.***
**Тыныш билгеләрен куегыз.** Өтер куелырга тиеш урыннарның цифрларын языгыз.

*Әлфия бөреләнеп килгән карлыган куакларына (1) алмагачларга күз йөртеп чыкты да (2) «Эх (3) нинди матур булыр безнең бакча (4) » – диде.*

Җавап: ______________________________.

**3** ***Синтаксик анализ.***
**Төшем килеше** кушымчасы ярдәмендә бәйләнгән сүзтезмәне табып языгыз.

*Кайсыларыбыз җимеш агачларының төпләрен йомшарта.*

Җавап: ______________________________.

**4** ***Орфографик анализ.***
Язылышы дөрес аңлатылмаган сүзләрнең номерларын языгыз.

1) **КӨЧЕК** – татар телендә ө хәрефе беренче иҗектә генә языла.
2) **ТЕГЕРМӘН** – [э] авазы иҗек уртасында е хәрефе белән языла.
3) **ТӘЭСИР** – [э] авазы, беренче иҗек азагында килгәндә, э хәрефе белән языла.

4) **ЧАҢГЫ** – ң хәрефе татар телендә сүз уртасында языла.
5) **ВӘГЪДӘ** – иҗек ахырындагы г хәрефеннән соң ъ хәрефе языла.

Җавап: ____________________________.

***Текстны укыгыз һәм 5-7 нче биремнәрне үтәгез.***

(1) Көннәрнең берендә ишегалдының усал малайлары, чәрелдек кызлары, уйный-уйный арып, өйләренә таралышкач, күктә йолдызлар кабынгач, болытларны аралап ай калыккач, бөркет җанлы юаш малай чыккан да җепшек кардан бик матур итеп Кар кызы ясап куйган. (2) «Без синең белән мәңге дуслар булырбыз», – дигән ул Кар кызына.

(3) – Мин риза, – дигән Кар кызы. (4) Һәм алар, җитәкләшеп, тауга менеп киткәннәр. (5) Егылсалар, берсен-берсе тартып торгызганнар, арысалар, иңгә-иң куеп ял иткәннәр, күктәге йолдызларга карап сокланганнар.

(6) – Их! – дигән юаш малай, хискә бирелеп, – дөньяда дустың булу нинди рәхәт икән.

(7) – Әйе, – дигән Кар кызы, – синең кебек батыр малай белән дус булуыма мин бик шат.

(8) – Юк шул, – дип кире каккан аны малай, – мин батыр түгел.

(9) – Син батыр! – дигән Кар кызы. (10) – Чөнки син кара төннән курыкмыйча берүзең урамга чыктың. (11) Аннары әле генә минем күзләремә карап: «Мин батыр түгел», – дип әйтә алдың. (12) Үзеңә карата мондый сүзне әйтер өчен дә батырлык кирәк.

(13) Моңа кадәр әле юаш малайга бер генә кешенең дә «син батыр» дип әйткәне булмаган. (14) Кеше йөрәгенә яшерелгән батырлыкны күрү өчен, күзең очлы, күңелең әйбәт булу кирәк шул. (15) Шушы минуттан башлап, юаш малай бернидән дә курыкмый башлаган.

(16) Төне буе шәһәр буйлап алар озак йөргәннәр. (17) Бер-берләренә иң яшерен серләрен чишкәннәр. (18) Йөреп туйгач, иңгә-иң куеп сүзсез генә утырганнар. (19) Берәм-берәм тәрәзәләр яктыра башлаган.

(20) – Бәхетле көн үтеп тә китте! – дигән малай, көрсенеп. (21) – Яңадан бервакытта да мин болай бәхетле булалмам инде.

(22) – Булырсың, – дигән Кар кызы, – чөнки синең күңелең бай. (23) Ә күңел байлыгы — зур бәхет ул.

(24) Кар кызы шулай дигән дә, шаянланып, малайның җилкәсенә суккан: «Син үзеңнең батыр икәнлегеңне онытма, батырлык иң беренче йөрәктә туа»

*(Ф.Яруллиннан*)*

****Фәнис Яруллин*** *(1938-2011) – шагыйрь, прозаик һәм драматург.*

**5** ***Текстның эчтәлеген анализлау.***

Текстның эчтәлегенә туры килә торган җөмләләрнең номерларын языгыз.

1) Малай кардан Кар кызы ясап куйган.
2) Кар кызы дус булырга риза булмаган.
3) Малайга бер кешенең дә «син батыр» дип әйткәне булмаган.
4) Малай һәм Кар кызы шәһәр буйлап озак йөргәннәр.
5) Берәм-берәм тәрәзәләрдә утлар сүнгән.

Җавап: ___________________________.

**6**

***Сәнгатьлелек чараларын анализлау.***
Фразеологик әйтелмә кулланылган җөмләләрнең номерларын языгыз.

1) Алар, җитәкләшеп, тауга менеп киткәннәр.
2) Дөньяда дустың булу нинди рәхәт икән.
3) Юаш малай бернидән дә курыкмый башлаган.
4) Бер-берләренә иң яшерен серләрен чишкәннәр.
5) Ә күңел байлыгы — зур бәхет ул.

Җавап: ___________________________.

**7**

***Лексик анализ.***
Тексттан «гомерлек» сүзенә синоним булган сүзне табып языгыз.

Җавап: ___________________________.

***Барлык җавапларны, эшне башкару буенча күрсәтмәдә әйтелгәнчә, 1 нче номерлы бланкка күчереп язарга онытмагыз. Һәр җавапның тиешле бирем номеры язылган юлда булуын тикшерегез.***

## II бүлек

**8.1**

**«Син үзеңнең батыр икәнлегеңне онытма, батырлык иң беренче йөрәктә туа».** Текстта китерелгән бу сүзләрнең мәгънәсен аңлатып, сочинение языгыз.

Укылган тексттан фикерләрегезне раслый торган **ике** дәлил китерегез.

Мисаллар биргәндә, кирәкле җөмләләрне языгыз яисә аларның номерларын күрсәтегез.

Сочинениенең күләме 90 сүздән ким булмаска тиеш.

Әгәр сочинение сөйләп чыгу яки чыганак текстны аңлатуларсыз тулысынча күчереп язу формасында гына булса, мондый эш 0 балл белән бәяләнә.

Сочинениене пөхтә һәм аңлаешлы итеп языгыз.

**8.2** **БАТЫРЛЫК** сүзен ничек аңлыйсыз? Үзегез формалаштырган билгеләмәне дәлилләгез. Үзегез язган билгеләмәне тезис итеп алып, **«Нинди кешене батыр дип була?»** темасына сочинение языгыз. Тезисыгызны раслый торган **ике** дәлил китерегез: дәлилнең **берсен** укылган тексттан алыгыз, **икенчесен** тормыш тәҗрибәгездән чыгып формалаштырыгыз.

Әгәр сочинение сөйләп чыгу яки чыганак текстны аңлатуларсыз тулысынча күчереп язу формасында гына булса, мондый эш 0 балл белән бәяләнә.

Сочиненениенең күләме 90 сүздән ким булмаска тиеш.

Сочинениене пөхтә һәм аңлаешлы итеп языгыз.

***Һәр җавапның тиешле бирем номеры язылган юлда булуын тикшерегез.***

**Дөрес җаваплар**

| **Биремнең номеры** | **Дөрес җавап** |
|---|---|
| 1 | 125 |
| 2 | 13 |
| 3 | төпләренйомшарта |
| 4 | 35 |
| 5 | 134 |
| 6 | 45 |
| 7 | мәңге |

## АЛТЫНЧЫ ВАРИАНТ

### I бүлек

***1-7 нче биремнәрнең җавапларын сүз (берничә сүз) яки цифрлар белән языгыз. Һәр хәреф яки цифр бланктагы үрнәктәгечә аерым шакмакка языларга тиеш. Сүзләр яки цифрлар буш шакмак калдырмыйча, өтерсез һәм башка тамгаларсыз языла.***

**1** ***Синтаксик анализ.***

Текстны укыгыз.

(1) Алалы-колалы яткан җир өсте тигез үлән белән капланды. (2) Иртәләрен куе таллыкта җырчы кошлар сайравы, сыгылмалы камышлар арасында бытбылдык кычкыруы ишетелеп тора. (3) Җылымса җир өстендә зәңгәр рәшә җемелди. (4) Текә таулар, яшел урманнар иртәдән кичкә чаклы аның дулкынында коена. (5) Зифа сынлы каеннар да купшы кунак кызы кебек көязләнделәр.

**Баш кисәкләр** дөрес билгеләнгән җавап вариантларының номерларын языгыз.

1) җир капланды (1 нче җөмлә)
2) сайравы, кычкыруы ишетелеп тора (2 нче җөмлә)
3) җир җемелди (3 нче җөмлә)
4) таулар, урманнар коена (4 җөмлә)
5) каеннар көязләнделәр (5 нче җөмлә)

Җавап: ______________________________.

**2** ***Пунктуацион анализ.***

**Тыныш билгеләрен куегыз.** Өтер куелырга тиеш урыннарның цифрларын языгыз.

*Әнисе Гөлнурга һәрвакыт әйтә торды (1) «Бик кайнар я бик салкын әйбер ашама (2) эчмә (3) каты әйберләр тешләмә» (4) – диде.*

Җавап: ______________________________.

**3** ***Синтаксик анализ.***

**Төшем килеше** кушымчасы ярдәмендә бәйләнгән сүзтезмәне табып языгыз.

*Эшчән бәхетне эшендә күрер, ялкау төшендә күрер.*

Җавап: ______________________________.

**4** ***Орфографик анализ.***

Язылышы дөрес аңлатылмаган сүзләрнең номерларын языгыз.

1) **МӘКАЛЬ** – ь хәрефе л хәрефен нечкәртү өчен языла.

2) **ДАВЫЛ** – [w] авазын белдерү өчен, в хәрефе белән языла.

3) **ЯРАН** – [а] авазы [й] авазы белән бергә килгәндә, я хәрефе языла.

4) **ТАБИГАТЬ** – иҗек башында килгән г хәрефеннән соң а хәрефе языла.

5) **КОТЫП** – кыска [о] авазы сүзнең беренче иҗегендә генә языла, икенче иҗектә ы хәрефе языла.

Җавап: ____________________________.

***Текстны укыгыз һәм 5-7 нче биремнәрне үтәгез.***

(1) Яшәгән, ди, бер Тузганак. (2) Аягы аның бик төз һәм бик озын булган, ди. (3) Башы хәйран да купшы, сырлы-сырлы ямь-яшел яфраклары, җилпәзәдәй булып, җиргә үк җәелгәннәр, ди.

(4) Тузганакның матурлыгына барысы да соклана икән.

(5) Бервакыт Каз үләне:

– Бигрәк күркәм инде сезнең бүрегегез! – дип куйган. (6) Тузганак үзенең матурлыгын үзе дә белә икән, бу сүзләргә исе дә китмәгән аның. (7) Берни дәшмәгән.

(8) Каз үләне исә аның купшы бүрегенә тагын бер генә мәртәбә күтәрелеп караган да җиргә иелгән. (9) Гарьлегеннән елыйсылары килгән аның. (10 Бигрәк инде, сөйләшмәгән дә була.

(11) Якында үсеп утырган Әрекмән дә, үзенең олы-олы салпы яфракларын рәтли-рәтли, Тузганакка сокланып карап торган.

(12) – Әйе, бүрегегез бик килешле, – дигән ул калын тавышы белән.

(13) Карт Әрекмәнне кем генә белми икән! (14) Аның турында бик зирәк дигән фикер таралган, һәм күпләр олылыйлар икән. (15) Шуңа күрә Тузганак та аның сүзләрен илтифатсыз калдырырга батырчылык итмәгән.

(16) – Әйе шул! (17) Бүрегем бик матур шул! – дигән. (18) – Ансыз яши дә алмас идем мин, – дип тә өстәгән.

(19) Бу сүзне ишеткәч, Әрекмән елмаеп әйткән:

– Юкка кайгырасыз. (20) Бүрексез яшәве читен түгел, менә башсыз яшәве кыенрак.

(21) Тузганакның моңа хәтере калган, тик озын-озак сүз көрәштереп тормаган. (22) «Әйдә, лыгырдасын шунда», – дип кенә куйган. (23) Әрекмәннең сүзен санга сукмаган.

(24) Нәкъ шул чакны җил күтәрелгән, һәммә үлән куркудан күзен йомган. (25) Бераздан керфекләрен ачып карасалар, ни күрсеннәр – һавада җиңел-җиңел парашютлар очып йөри, ә Тузганак яланбаш калган. (26) Аның шәрә башы майлы кабартма төсле ялтырап тора, баш тирәли ямь-яшел сакаллар салынган. (27) Тузганак үзенең матур бүрегеннән күтәрелгән парашютларга моңсуланып карап тора, ләкин бу хәлнең ничек булганын, ни рәвешле бүрексез калуын аңларга башы җитми аның. (28) Бик тә инде кызганыч булып калган Тузганак. (29) Каз үләне аңа берәр җылырак сүз әйтмәкче, күңелен күтәрмәкче булган.

(30) – Бер дә кайгырмагыз. (31) Без сезгә икенче бүрек табарбыз, – дигән ул.

(32) Карт Әрекмән генә дәшмәгән.

*(С.Гыйльметдиновадан*)*

**Светлана Гыйльметдинова* (1937) – язучы һәм тәрҗемәче.*

**5** ***Текстның эчтәлеген анализлау.***

Текстның эчтәлегенә туры килә торган җөмләләрнең номерларын языгыз.

1) Тузганакның аягы кыска һәм кәкре булган.
2) Тузганакның матурлыгына беркем дә сокланмаган.
3) Якында гына Әрекмән үсеп утырган.
4) Әрекмәнне барысы да белә икән.
5) Шул вакытта җил чыккан.

Җавап: ____________________________.

**6** ***Сәнгатьлелек чараларын анализлау.***

Фразеологик әйтелмә кулланылган җөмләләрнең номерларын языгыз.

1) Башы хәйран да купшы, сырлы-сырлы ямь-яшел яфраклары, җилпәзәдәй булып, җиргә үк җәелгәннәр, ди.

2) Тузганак үзенең матурлыгын үзе дә белә икән, бу сүзләргә исе дә китмәгән аның.

3) Якында үсеп утырган Әрекмән дә, үзенең олы-олы салпы яфракларын рәтли-рәтли, Тузганакка сокланып карап торган.

4) Әрекмәннең сүзен санга сукмаган.

5) Аның шәрә башы майлы кабартма төсле ялтырап тора, баш тирәли ямь-яшел сакаллар салынган.

Җавап: ____________________________.

**7** ***Лексик анализ.***

Тексттан «таралганнар» сүзенә синоним булган сүзне табып языгыз.

Җавап: ____________________________.

***Барлык җавапларны, эшне башкару буенча күрсәтмәдә әйтелгәнчә, 1 нче номерлы бланкка күчереп язарга онытмагыз. Һәр җавапның тиешле бирем номеры язылган юлда булуын тикшерегез.***

## II бүлек

**8.1** **«Бүрексез яшәве читен түгел, менә башсыз яшәве кыенрак».** Текстта китерелгән бу сүзләрнең мәгънәсен аңлатып, сочинение языгыз.

Укылган тексттан фикерләрегезне раслый торган **ике** дәлил китерегез.

Мисаллар биргәндә, кирәкле җөмләләрне языгыз яисә аларның номерларын күрсәтегез.

Сочинениенең күләме 90 сүздән ким булмаска тиеш.

Әгәр сочинение сөйләп чыгу яки чыганак текстны аңлатуларсыз тулысынча күчереп язу формасында гына булса, мондый эш 0 балл белән бәяләнә.

Сочинениене пөхтә һәм аңлаешлы итеп языгыз.

**8.2** **БАШСЫЗ ЯШӘҮ** гыйбарәсен ничек аңлыйсыз? Үзегез формалаштырган билгеләмәне дәлилләгез. Үзегез язган билгеләмәне тезис итеп алып, **«Нинди кешене башсыз дип була?»** темасына сочинение языгыз. Тезисыгызны раслый торган **ике** дәлил китерегез: дәлилнең **берсен** укылган тексттан алыгыз, **икенчесен** тормыш тәҗрибәгездән чыгып формалаштырыгыз.

Әгәр сочинение сөйләп чыгу яки чыганак текстны аңлатуларсыз тулысынча күчереп язу формасында гына булса, мондый эш 0 балл белән бәяләнә.

Сочинениенең күләме 90 сүздән ким булмаска тиеш.

Сочинениене пөхтә һәм аңлаешлы итеп языгыз.

***Һәр җавапның тиешле бирем номеры язылган юлда булуын тикшерегез.***

### Дөрес җаваплар

| **Биремнең номеры** | **Дөрес җавап** |
|---|---|
| 1 | 245 |
| 2 | 23 |
| 3 | бәхетнекүрер |
| 4 | 14 |
| 5 | 345 |
| 6 | 24 |
| 7 | җәелгәннәр |

## ҖИДЕНЧЕ ВАРИАНТ

## I бүлек

***1-7 нче биремнәрнең җавапларын сүз (берничә сүз) яки цифрлар белән языгыз. Һәр хәреф яки цифр бланктагы үрнәктәгечә аерым шакмакка язылырга тиеш. Сүзләр яки цифрлар буш шакмак калдырмыйча, өтерсез һәм башка тамгаларсыз языла.***

**1** ***Синтаксик анализ.***
Текстны укыгыз.

(1) Автобус безне Машук тавы итәгенә алып китте. (2) Менә бер аланга килеп туктадык. (3) Экскурсовод безне һәйкәл янына алып килде һәм 1841 елның 15 июлендә шушы урында бөек шагыйрь Лермонтовның дуэльдә һәлак булуы турында сөйли башлады. (4) Һәммәбез дә аны тып-тын калып тыңладык. (5) Минем күз алдымнан бик күптәнге вакыйгалар җанланып үтте.

**Баш кисәкләр** дөрес билгеләнгән җавап вариантларының номерларын языгыз.

1) автобус алып китте (1 нче җөмлә)
2) менә килеп туктадык (2 нче җөмлә)
3) экскурсовод алып килде, сөйли башлады (3 нче җөмлә)
4) һәммәбез дә тыңладык (4 җөмлә)
5) минем үтте (5 нче җөмлә)

Җавап: ______________________________.

**2** ***Пунктуацион анализ.***
**Тыныш билгеләрен куегыз.** Өтер куелырга тиеш урыннарның цифрларын языгыз.

*Кыска (1) ләкин хискә (2) фикергә искиткеч бай бу нәсер (3) шагыйрьнең соңгы әсәрләреннән берсе.*

Җавап: ______________________________.

**3** ***Синтаксик анализ.***
**Чыгыш килеше** кушымчасы ярдәмендә бәйләнгән сүзтезмәне табып языгыз.

*Яшең йөзгә җитмәсә дә, дустың йөздән артсын.*

Җавап: ______________________________.

**4** ***Орфографик анализ.***
Язылышы дөрес аңлатылмаган сүзләрнең номерларын языгыз.

1) **БӨТЕН** – [ө] авазы беренче иҗектә – ө хәрефе, икенче иҗектә е хәрефе белән языла.

2) **БАЛАЛАРЫБЫЗНЫҢ** – калын иҗектән соң калын кушымчалар языла.

3) **КАЛӘМ** – [л] авазын калын итеп уку өчен, а хәрефе языла.

4) **БМО** – кыскартылма сүз, шуңа күрә баш хәрефләр генә языла.

5) **СОРАВЫ** – у хәрефе иҗек башында килгәндә, в хәрефе белән языла.

Җавап: ____________________________.

***Текстны укыгыз һәм 5-7 нче биремнәрне үтәгез.***

(1) Бер әби урам буйлап килә. (2) Атлый да туктый, атлый да туктый. (3) Туктый да, ярдәм итәр кеше юкмы икән дигәндәй, як-ягына карана: кулындагы төенчеге бик авыр бугай. (4) Үч иткәндәй, урам буп-буш. (5) Бер малай гына туп куып йөри.

(6) Менә малай әбине күреп туктап калды. (7) Уенны ташлап, әби каршына йөгерде.

(8) – Булышыйммы, әби? – дип, рөхсәт иткәнче үк, төенчеккә ябышты. (9) Карчык бераз тын алыр өчен туктады, мөлаем елмайды.

(10) – Исемең ничек синең, бәбкәм?

(11) – Сөләйман.

(12) – Матур исем. Ә мин Галия әби булам.

(13) – Галия әби, әйдә, булышам, – дип кабатлады Сөләйман.

(14) – И, бигрәк итагатьле бала икәнсең. (15) Икебез күтәргәч, төенчек тә җиңел тоелыр, миңа да күңелле булыр.

(16) Менә алар икәүләп, төенчек күтәреп, урам буйлап киләләр, күптәнге танышлар кебек сөйләшәләр, көлешәләр.

(17) Сөйләшә-сөйләшә, тугыз катлы йорт каршына килеп җитүләрен сизми дә калдылар. (18) Әбисенең тавышын ишетеп, подъездан оныгы атылып чыкты һәм бар тавышка:

– Әбекәй, тәмле әйбер бир! – дип кычкырды.

(19) Үз яшендәге ят малайны күреп туктап калды. (20) Ник ярдәм итә ул әбигә?

(21) Мөгаен, тәмле әйбер алыр өчен күтәрешкән булгандыр. (22) Авызын чалшайтып, усал итеп, ят малайга эндәште:

— «Киндер сюрприз» кирәк булдымыни?

(23) Карчык белән Сөләйманның кәефе китте, көтелмәгән бу сүздән аптырап калдылар. (24) Сөләйман, ачуы чыгып, йодрыкларын каты итеп йомарлады, ләкин әбигә хөрмәт йөзеннән тавыш күтәрмәде, тыныч кына:

– Синнән сорамадылар... – дип әйтеп куйды.

(25) Оныгы өчен оят булып китте карчыкка, йөрәге сызлап куйды. (26) Ярдәмчесен иркәләп башыннан сыйпады:

– Яхшы малай ул – Сөләйман. (27) Зур рәхмәт сиңа.

(28) Аннары оныгына таба борылып, әйтеп куйды:

– Менә кем белән дуслашырга кирәк!

(29) Малай сандалие белән җирне чокый башлады, борынын мышкылдатты. (30) Кешеләргә рәхмәт өчен генә дә булышырга мөмкин икәнен аңладымы икән ул?

*(Н.Каштановтан*)*

* ***Нәкыйп Каштанов*** *(1942) – язучы, шагыйрь, журналист.*

**5** ***Текстның эчтәлеген анализлау.***

Текстның эчтәлегенә туры килә торган җөмләләрнең номерларын языгыз.

1) Урамда берничә малай туп куа.
2) Малай, уеныннан туктап, әби каршына йөгерде.
3) Сөләйман белән әби, төенчек күтәреп, урам буйлап баралар.
4) Үз яшендәге ят малайны күреп каршына йөгерде.
5) Әбигә оныгы өчен оят булды.

Җавап: ___________________________.

**6** ***Сәнгатьлелек чараларын анализлау.***

Фразеологик әйтелмә кулланылган җөмләләрнең номерларын языгыз.

1) Туктый да, ярдәм итәр кеше юкмы икән дигәндәй, як-ягына карана: кулындагы төенчеге бик авыр бугай.
2) Үч иткәндәй, урам буп-буш.
3) Икебез күтәргәч, төенчек тә җиңел тоелыр, миңа да күңелле булыр.
4) Карчык белән Сөләйманның кәефе китте, көтелмәгән бу сүздән аптырап калдылар.
5) Малай сандалие белән җирне чокый башлады.

Җавап: ___________________________.

**7** ***Лексик анализ.***

Тексттан «әдәпле» сүзенә синоним булган сүзне табып языгыз.

Җавап: ___________________________.

***Барлык җавапларны, эшне башкару буенча күрсәтмәдә әйтелгәнчә, 1 нче номерлы бланкка күчереп язарга онытмагыз. Һәр җавапның тиешле бирем номеры язылган юлда булуын тикшерегез.***

## II бүлек

**8.1** **«Кешеләргә рәхмәт өчен генә дә булышырга мөмкин икәнен аңладымы икән ул?»** Текстта китерелгән бу сүзләрнең мәгънәсен аңлатып, сочинение языгыз.

Укылган тексттан фикерләрегезне раслый торган **ике** дәлил китерегез.

Мисаллар биргәндә, кирәкле җөмләләрне языгыз яисә аларның номерларын күрсәтегез.

Сочинениенең күләме 90 сүздән ким булмаска тиеш.

Әгәр сочинение сөйләп чыгу яки чыганак текстны аңлатуларсыз тулысынча күчереп язу формасында гына булса, мондый эш 0 балл белән бәяләнә.

Сочинениене пөхтә һәм аңлаешлы итеп языгыз.

**8.2** **ИТАГАТЬЛЕ** сүзен ничек аңлыйсыз? Үзегез формалаштырган билгеләмәне дәлилләгез. Үзегез язган билгеләмәне тезис итеп алып, **«Нинди кешене итагатьле дип була?»** темасына сочинение языгыз. Тезисыгызны раслый торган **ике** дәлил китерегез: дәлилнең **берсен** укылган тексттан алыгыз, **икенчесен** тормыш тәҗрибәгездән чыгып формалаштырыгыз.

Әгәр сочинение сөйләп чыгу яки чыганак текстны аңлатуларсыз тулысынча күчереп язу формасында гына булса, мондый эш 0 балл белән бәяләнә.

Сочинениенең күләме 90 сүздән ким булмаска тиеш.

Сочинениене пөхтә һәм аңлаешлы итеп языгыз.

***Һәр җавапның тиешле бирем номеры язылган юлда булуын тикшерегез.***

### Дөрес җаваплар

| Биремнең номеры | Дөрес җавап |
|---|---|
| 1 | 134 |
| 2 | 12 |
| 3 | йөздәнартсын |
| 4 | 35 |
| 5 | 235 |
| 6 | 24 |
| 7 | итагатьле |

## СИГЕЗЕНЧЕ ВАРИАНТ

### I бүлек

***1-7 нче биремнәрнең җавапларын сүз (берничә сүз) яки цифрлар белән языгыз. Һәр хәреф яки цифр бланктагы үрнәктәгечә аерым шакмакка язылырга тиеш. Сүзләр яки цифрлар буш шакмак калдырмыйча, өтерсез һәм башка тамгаларсыз языла.***

**1** ***Синтаксик анализ.***
Текстны укыгыз.

(1) Аулак палубада, уйларымны юлдаш итеп, ялгыз мин йөрим. (2) Юл күрсәтеп чайкалган өч почмаклы бакеннар башындагы кызыл, яшел утлар, күз кыскандай сүнеп-кабынып, безне озатып калалар. (3) Пароходыбыз Идел яры буйлап, Красновидово, Шеланга авылларын, Ослан тауларын узып, Казанга якынлаша барды. (4) Иртәнге җиләс палубада ялгызым шул күренешне күзәтеп барам. (5) Тын гына, салмак кына тирбәлеп ага да ага Идел.

**Баш кисәкләр** дөрес билгеләнгән җавап вариантларының номерларын языгыз.

1) мин йөрим (1 нче җөмлә)
2) бакеннар озатып баралар (2 нче җөмлә)
3) пароходыбыз якынлаша барды (3 нче җөмлә)
4) күзәтеп барам (4 җөмлә)
5) Идел ага да ага (5 нче җөмлә)

Җавап: ______________________________.

**2** ***Пунктуацион анализ.***
**Тыныш билгеләрен куегыз.** Өтер куелырга тиеш урыннарның цифрларын языгыз.

*Урамда Әхмиров очрау белән (1) атын туктатып (2) аңа (3)*
*– Әмир култыгының печәне алгы тәгәрмәчләрне кумә. – диде.*

Җавап: ______________________________.

**3** ***Синтаксик анализ.***
**Төшем килеше** кушымчасы ярдәмендә бәйләнгән сүзтезмәне табып языгыз.

*Менә без тугайлыктагы тын, тирән җиргә килеп җитәбез, кармакларыбызны салабыз.*

Җавап: ______________________________.

**4** ***Орфографик анализ.***
Язылышы дөрес аңлатылмаган сүзләрнең номерларын языгыз.

1) **ТӘЭСИР** – [э] авазы, беренче иҗек азагында килгәндә, э хәрефе белән языла.

2) **БОРЫНГЫ** – о хәрефе сүзнең беренче иҗегендә генә языла.

3) **ТӘКЪДИМ** – иҗек ахырында килгән к хәрефен калын уку өчен, ъ хәрефе языла.

4) **СӘНГАТЬ** – иҗек башында килгән г хәрефен нечкә уку өчен, ь хәрефе языла.

5) **КҮҢЕЛЛЕ** – ң хәрефе сүз башында язылмый.

Җавап: ___________________________.

***Текстны укыгыз һәм 5-7 нче биремнәрне үтәгез.***

(1) Китап... (2) Ике катыргы арасына тыгызлап тутырылган чуар кәгазь. (3) Бары шул гына. (4) Яхшылабрак уйлап карасаң, китап ул – адәм балалары уйлап чыгара алган сирәк могҗизаларның могҗизасы.

(5) Могҗиза, чөнки Пушкин үлгән, Тукай үлгән, Гоголь, Толстой юк инде, ә без, бүгенге кешеләр, алар белән кара-каршы сөйләшкән кебек сөйләшәбез. (6) Алар нинди уйлар белән яшәгәннәр, нинди хис-тойгылар белән янганнар, язып калдырган китапларының битләрен ачып, без дә шул уйлар, шул хисләр белән янабыз. (7) Юнан, Мисыр, Рим, Һинд язучылары, галимнәре бүген безнең белән янәшә яшиләр, китаплары безнең алдыбызда. (8) Телевизор, радио, 21 нче гасыр могҗизалары чыбыксыз-нисез, вакыйгаларны ераклардан күрсәтә, сөйләп тора, ә китап тагын да могҗизалырак. (9) Ул моннан әллә ничә мең еллар элек яшәгән, хәзер инде туфраклары гына өелеп калган бөек дәүләтләрне, мәгърур халыкларны безнең күз алдыбызга бөтен законнары, гореф-гадәтләре, җырлары белән җанлы итеп китереп бастыра.

(10) Без китап битләрендә Мисыр кызының матур елмаюын күрәбез. (11) Борынгы Юнан шагыйрәсенең нәфис шигырьләрен укып рәхәтләнәбез. (12) Барысы да китап аркасында. (13) Китап миллионнарча акыл, күңел җимешләрен безгә түкми-чәчми китереп җиткергән.

(14) Дәүләтләр яшәгән – беткән. (15) Халыклар яшәгән – сөяге дә калмаган. (16) Ай калган, Кояш калган да китап калган. (17) Таш китап, тире китап, ефәк китап, кәгазь китап калган.

(18) Дөрестән дә, китап булмаса, без язучылар, шагыйрьләр нишләр идек? (19) Шигырьне күңелдән сөйләп була, ә хикәяне, романны? (20) Бөтен дөньяны онытып, китаптагы кызыклы, гыйбрәтле, фаҗигале вакыйгалар эченә чуму рәхәтен кем генә татымаган икән? (21) Кешеләр сугыш җирендә дә китаптан аерылмадылар. (22) Минем дә, сугышның буеннан-буена үзем белән йөреп, кире Казанга әйләнеп кайткан, яраткан китабым бар...

*(И.Газидан*)*

*****Ибраһим Гази*** *(1907-1971) – проза остасы, тәрҗемәче һәм җәмәгать эшлеклесе.*

**5** ***Текстның эчтәлеген анализлау.***

Текстның эчтәлегенә туры килә торган җөмләләрнең номерларын языгыз.

1) Китап ул – ике катыргы арасындагы кәгазь.
2) Без алар белән кара-каршы сөйләшкән кебек сөйләшәбез.
3) Мисыр, Рим, Һинд галимнәренең китаплары безнең алдыбызда.
4) Дәүләтләр беткән – китап калган.
5) Китаптагы кызыклы вакыйгалар эченә чуму рәхәт түгел.

Җавап: ____________________________.

**6** ***Сәнгатьлелек чараларын анализлау.***

Фразеологик әйтелмә кулланылган җөмләләрнең номерларын языгыз.

1) Ике катыргы арасына тыгызлап тутырылган чуар кәгазь.
2) Безнең күз алдыбызга җанлы итеп китереп бастыра.
3) Без китап битләрендә Мисыр кызының матур елмаюын күрәбез.
4) Таш китап, тире китап, ефәк китап, кәгазь китап калган.
5) Бөтен дөньяны онытып, китаптагы кызыклы вакыйгалар эченә чуму рәхәтен кем генә татымаган икән?

Җавап: ____________________________.

**7** ***Лексик анализ.***

Тексттан «ала-кола» сүзенә синоним булган сүзне табып языгыз.

Җавап: ____________________________.

***Барлык җавапларны, эшне башкару буенча күрсәтмәдә әйтелгәнчә, 1 нче номерлы бланкка күчереп язарга онытмагыз. Һәр җавапның тиешле бирем номеры язылган юлда булуын тикшерегез.***

## II бүлек

**8.1** **«Яхшылабрак уйлап карасаң, китап ул – адәм балалары уйлап чыгара алган сирәк могҗизаларның могҗизасы».** Текстта китерелгән бу сүзләрнең мәгънәсен аңлатып, сочинение языгыз.

Укылган тексттан фикерләрегезне раслый торган **ике** дәлил китерегез.

Мисаллар биргәндә, кирәкле җөмләләрне языгыз яисә аларның номерларын күрсәтегез.

Сочинениенең күләме 90 сүздән ким булмаска тиеш.

Әгәр сочинение сөйләп чыгу яки чыганак текстны аңлатуларсыз тулысынча күчереп язу формасында гына булса, мондый эш 0 балл белән бәяләнә.

Сочинениене пөхтә һәм аңлаешлы итеп языгыз.

**8.2** **ЯРАТКАН КИТАП** гыйбарәсен ничек аңлыйсыз? Үзегез формалаштырган билгеләмәне дәлилләгез. Үзегез язган билгеләмәне тезис итеп алып, **«Минем яраткан китабым»** темасына сочинение языгыз. Тезисыгызныраслый торган **ике** дәлил китерегез: дәлилнең **берсен** укылган тексттан алыгыз, **икенчесен** тормыш тәҗрибәгездән чыгып формалаштырыгыз.

Әгәр сочинение сөйләп чыгу яки чыганак текстны аңлатуларсыз тулысынча күчереп язу формасында гына булса, мондый эш 0 балл белән бәяләнә.

Сочинениенең күләме 90 сүздән ким булмаска тиеш.

Сочинениене пөхтә һәм аңлаешлы итеп языгыз.

***Һәр җавапның тиешле бирем номеры язылган юлда булуын тикшерегез.***

**Дөрес җаваплар**

| **Биремнең номеры** | **Дөрес җавап** |
|---|---|
| 1 | 135 |
| 2 | 12 |
| 3 | кармакларыбызнысалабыз |
| 4 | 14 |
| 5 | 134 |
| 6 | 25 |
| 7 | чуар |

## ТУГЫЗЫНЧЫ ВАРИАНТ

### I бүлек

***1-7 нче биремнәрнең җавапларын сүз (берничә сүз) яки цифрлар белән языгыз. Һәр хәреф яки цифр бланктагы үрнәктәгечә аерым шакмакка язылырга тиеш. Сүзләр яки цифрлар буш шакмак калдырмыйча, өтерсез һәм башка тамгаларсыз языла.***

**1** ***Синтаксик анализ.***
Текстны укыгыз.

(1) Фәрит Яруллин татар халык музыкасын гаҗәеп мул һәм оста куллана. (2) Бу байлыкны төрле планда файдаланып, аның дәрәҗәсен тагын бер баскычка күтәрә. (3) Авыл көйләре белән бергә ул шәһәр көйләрен дә бик иркен файдалана. (4) Икенче пәрдәдәге биюләрнең күпчелеге авыл җырларына корылган. (5) Шәһәрдә популярлык казанган «Тәфтиләү» кебек көйләрне дә ул, профессиональ югарылыкта эшкәртеп, биюләргә кертеп җибәрә, әмма һичбер вакытта да үзенең иҗат йөзен югалтмый.

**Баш кисәкләр** дөрес билгеләнгән җавап вариантларының номерларын языгыз.

1) Фәрит Яруллин куллана (1 нче җөмлә)
2) бу күтәрә (2 нче җөмлә)
3) көйләре файдалана (3 нче җөмлә)
4) күпчелеге корылган (4 җөмлә)
5) ул кертеп җибәрә, югалтмый (5 нче җөмлә)

Җавап: ___________________________.

**2** ***Пунктуацион анализ.***
**Тыныш билгеләрен куегыз.** Өтер куелырга тиеш урыннарның цифрларын языгыз.

*Болар (1) татар мәдәнияте күгендә балкыган (2) һәрчак якты янып торачак өч йолдыз (3) хәзерге рухи тормышыбызның рухи баганалары.*

Җавап: ___________________________.

**3** ***Синтаксик анализ.***
**Иялек килеше** кушымчасы ярдәмендә бәйләнгән сүзтезмәне табып языгыз.

*Чыршының кәүсәсендә дым күп булу сәбәпле, ул язын күркәләрне күп җибәрә.*

Җавап: ___________________________.

**4** ***Орфографик анализ.***
Язылышы дөрес аңлатылмаган сүзләрнең номерларын языгыз.

1) **ДӘВЕР** – [w] авазы, ике сузык арасында килгәндә, в хәрефе белән языла.
2) **ИГЪТИБАР** – г хәрефен [ғ] авазы дип уку өчен ъ хәрефе языла.
3) **ҖАНВАР** – [у] авазы в хәрефе белән языла.
4) **ХӘЗЕР ҮК** – үк – кисәкчә, шуңа күрә ул аерым языла.
5) **МӘСЬӘЛӘ** – кушма сүзләрдә ь хәрефе языла.

Җавап: ___________________________.

***Текстны укыгыз һәм 5-7 нче биремнәрне үтәгез.***

(1) Гомерем буе истә калырлык беренче әхлак дәресен мин әниемнән алдым. (2) Беренче сыйныфта укый башлаган чак. (3) Әни күпмедер акча сузды да: «Кибеттән бер ипи белән бер килограмм тоз алып кайт», – диде. (4) Йомышны үтәдем һәм акчаның калганын кайтарып бирдем. (5) Әнкәй кулымдагы сумкадан ипи белән тозны алды һәм:

– Мин сиңа артык акча бирмәгән идем ләбаса! – диде уфтанып. (6) – Сатучы апаң ялгыштымы икән?

(7) – Сатучылар ялгышамыни? – дидем мин, эчемнән сатучыларның беркайчан да хаталанмавына тирән ышанып.

(8) – Бик мөмкин, – диде әнкәй, һаман нәрсә турындадыр уйлана биреп, – дүрт аяклы ат та кайчак абына бит. (9) Шулай да бергәләп кибеткә барыйк әле, җаныма урын тапмыйм.

(10) – Бәлки иртәгә генә? – дидем мин. (11) Хәзер китапханәгә барырга җыенган идем.

(12) – Сатучы апаң, ялгышып, акчаның артыгын безгә биргән икән, без аны кире кайтарып бирмәсәк, мәңге гөнаһлы булып калабыз, – диде әнием.

(13) – Кем алдында?

(14) – Ходай алдында да, сатучы алдында да, барыннан да элек, үз намусыбыз алдында. (15) Бүген үк бармасак, минем төнем газапта үтәчәк, әйдә, улым, ашыгыйк.

(16) Чыннан да, сатучы апа хаталанган булып чыкты. (17) Ул безгә чиксез рәхмәтләрен әйтеп, өстәвенә, миңа бер конфет та бирде һәм елмаеп озатып калды.

(18) Кибеттән чыккач, әнием иркенләп тын алды да:

– Менә хәзер, улым, җаныбыз чистарынып калды инде, – диде, өстеннән тау төшкәндәй, чиксез бер канәгатьләнү белән.

(19) – Безнең ни гаебебез бар иде соң? (20) Без бит бер тиенне дә алдап алмадык, – дидем мин, һаман да булса әнкәйнең нәрсә әйтергә теләгәненә төшенеп бетә алмыйча.

(21) – Булсын. (22) Ә үз намусыңны кая куясың? (23) Иртәме-соңмы сатучы апаң акчасы җитмәгәнлеген сизәчәк һәм кемгә дә булса берәүгә артыгын алып

кире китермәгәннәре өчен рәнҗиячәк. (24) Кеше рәнҗешен алудан да зур гөнаһ бармы икән ул дөньяда?! (25) Хәтереңә салып куй: намусыңа тап төшерә күрмә!

*(В. Казыйхановтан*)*

**Вил Казыйханов (1939-2012) – укытучы һәм язучы.*

**5** ***Текстның эчтәлеген анализлау.***

Текстның эчтәлегенә туры килә торган җөмләләрнең номерларын языгыз.

1) Икенче сыйныфта укый башладым.
2) Әни сумкадан ипи белән тозны алды.
3) Хәзер мин китапханәгә барам.
4) Чыннан да, сатучы апа хаталанмаган икән.
5) Без бит сатучыны алдамадык.

Җавап: ____________________________.

**6** ***Сәнгатьлелек чараларын анализлау.***

Фразеологик әйтелмә кулланылган җөмләләрнең номерларын языгыз.

1) Йомышны үтәдем һәм акчаның калганын кайтарып бирдем.
2) Мин сиңа артык акча бирмәгән идем ләбаса!
3) Шулай да бергәләп кибеткә барыйк әле, җаныма урын тапмыйм.
4) Без аны кире кайтарып бирмәсәк, мәңге гөнаһлы булып калабыз.
5) Хәтереңә салып куй: намусыңа тап төшерә күрмә!

Җавап: ____________________________.

**7** ***Лексик анализ.***

Тексттан «вакыт» сүзенә синоним булган сүзне табып языгыз.

Җавап: ____________________________.

***Барлык җавапларны, эшне башкару буенча күрсәтмәдә әйтелгәнчә, 1 нче номерлы бланкка күчереп язарга онытмагыз. Һәр җавапның тиешле бирем номеры язылган юлда булуын тикшерегез.***

## II бүлек

**8.1** **«Хәтереңә салып куй: намусыңа тап төшерә күрмә!».** Текстта китерелгән бу сүзләрнең мәгънәсен аңлатып, сочинение языгыз.

Укылган тексттан фикерләрегезне раслый торган **ике** дәлил китерегез.

Мисаллар биргәндә, кирәкле җөмләләрне языгыз яисә аларның номерларын күрсәтегез.

Сочинениенең күләме 90 сүздән ким булмаска тиеш.

Әгәр сочинение сөйләп чыгу яки чыганак текстны аңлатуларсыз тулысынча күчереп язу формасында гына булса, мондый эш 0 балл белән бәяләнә.

Сочинениене пөхтә һәм аңлаешлы итеп языгыз.

**8.2** **НАМУСЛЫ КЕШЕ** гыйбарәсен ничек аңлыйсыз? Үзегез формалаштырган билгеләмәне дәлилләгез. Үзегез язган билгеләмәне тезис итеп алып, **«Нинди кешене намуслы дип була?»** темасына сочинение языгыз. Тезисыгызныраслый торган **ике** дәлил китерегез: дәлилнең **берсен** укылган текстtan алыгыз, **икенчесен** тормыш тәҗрибәгездән чыгып формалаштырыгыз.

Әгәр сочинение сөйләп чыгу яки чыганак текстны аңлатуларсыз тулысынча күчереп язу формасында гына булса, мондый эш 0 балл белән бәяләнә.

Сочинениенең күләме 90 сүздән ким булмаска тиеш.

Сочинениене пөхтә һәм аңлаешлы итеп языгыз.

***Һәр җавапның тиешле бирем номеры язылган юлда булуын тикшерегез.***

## Дөрес җаваплар

| Биремнең номеры | Дөрес җавап |
|---|---|
| 1 | 145 |
| 2 | 23 |
| 3 | чыршыныңкәүсәсендә |
| 4 | 35 |
| 5 | 125 |
| 6 | 35 |
| 7 | чак |

## УНЫНЧЫ ВАРИАНТ

### I бүлек

***1-7 нче биремнәрнең җавапларын сүз (берничә сүз) яки цифрлар белән языгыз. Һәр хәреф яки цифр бланктагы үрнәктәгечә аерым шакмакка язылырга тиеш. Сүзләр яки цифрлар буш шакмак калдырмыйча, өтерсез һәм башка тамгаларсыз языла.***

**1** ***Синтаксик анализ.***

Текстны укыгыз.

(1) Идел тамагы тирәләрендә әллә никадәр вак-вак утраулар бар. (2) Аларның һәрберсендә куе камыш үсә. (3) Камышның буе дүрт-биш метрга җитә. (4) Элек ул шунда череп әрәм булган. (5) Хәзер аны һәркайда диярлек төзү материалы һәм химик чимал итеп файдаланалар.

**Баш кисәкләр** дөрес билгеләнгән җавап вариантларының номерларын языгыз.

1) Идел тамагы бар (1 нче җөмлә)
2) камыш үсә (2 нче җөмлә)
3) буе җитә (3 нче җөмлә)
4) ул әрәм булган (4 җөмлә)
5) материалы файдаланалар (5 нче җөмлә)

Җавап: ______________________________.

**2** ***Пунктуацион анализ.***

**Тыныш билгеләрен куегыз.** Өтер куелырга тиеш урыннарның цифрларын языгыз.

*Эчкә керү белән (1) берсе шунда эшләүче хатынга мөрәҗәгать итте (2)*
*– Концерт башландымы әле (3) апа?*

Җавап: ______________________________.

**3** ***Синтаксик анализ.***

**Юнәлеш килеше** кушымчасы ярдәмендә бәйләнгән сүзтезмәне табып языгыз.

*Без юл өстендәге берничә авылга тукталдык.*

Җавап: ______________________________.

**4** ***Орфографик анализ.***

Язылышы дөрес аңлатылмаган сүзләрнең номерларын языгыз.

1) **ДӨНЬЯ** – иҗекне нечкә уку өчен, ь хәрефе языла.
2) **АККОШ** – кушма сүз, шуңа күрә кушылып языла.
3) **ЙОМЫШ**– [й] һәм [о] авазлары рәттән килгәндә, һәрвакыт ике хәреф языла.
4) **ӘЙЛӘНӘ-ТИРӘ** – парлы сүз, шуңа күрә ул сызыкча аша языла.
5) **СӘНГАТЬЛЕ** – г хәрефен [г] авазы дип уку өчен ь хәрефе языла.

Җавап: ____________________________.

***Текстны укыгыз һәм 5-7 нче биремнәрне үтәгез.***

(1) Галләметдин абыйлар белән күршеләр без. (2) Ишегалларын койма гына аерып тора.

(3) Беркөнне, мәктәптән кайтып керүемә, ишегалдыбызда кечкенә көчек күреп тукталып калдым. (4) Үзе чем-кара, күзләре ут булып яна. (5) Ничек безнең ишегалдына кергән диген?! (6) Койма буйлап йөгереп йөри. (7) Әледән-әле тукталып, койма арасыннан карый, теге якка чыгар иде дә, сыймый. (8) Тар шул. (9) Әнкәсе Актүш нишләргә дә белми. (10) Галләметдин абыйлар ягында әрле-бирле йөренә. (11) Көчегенә ярдәм итә алмавына көенә.

(12) Йөгереп барып, көчекне кулыма алдым. (13) Күтәреп, Галләметдин абыйларга кереп киттем. (14) Актүш һау-һаулап каршылады үземне. (15) Рәхмәт әйтүедер инде. (16) Көчек, җиргә куюга, әнисенә барып сыенды. (17) Башка көчекләр дә, туганнарының табылуына сөенгәндәй, аны урап алдылар.

(18) Актүшнең өрүен ишетепме, өйдән Галләметдин абый килеп чыкты. (19) Аңа хәлне сөйләп бирдем.

(20) Ул бер миңа, бер әниләре янында бөтерелеп йөрүче көчекләргә карап торды да:

– Рәхмәт, энем. (21) Кошларны, җәнлекләрне рәнҗетмәгән, кыен чакта аларга ярдәм кулы сузган кешеләрне яратам мин, – диде.

*(Р. Гыйззәтуллиннан*)*

** **Рафис Гыйззәтуллин** (1955) – язучы һәм журналист.*

**5** ***Текстның эчтәлеген анализлау.***
Текстның эчтәлегенә туры килә торган җөмләләрнең номерларын языгыз.

1) Без Галләметдин абыйларның күршесендә яшибез.
2) Аларның ишегалларында кечкенә көчек күрдем.
3) Көчекне кулыма алдым да Галләметдин абыйларга кереп киттем.
4) Галләметдин абыйга барысын да сөйләдем.
5) Галләметдин абый мине ачуланды.

Җавап: ___________________________.

**6** ***Сәнгатьлелек чараларын анализлау.***
Фразеологик әйтелмә кулланылган җөмләләрнең номерларын языгыз.

1) Ишегалларын койма гына аерып тора.
2) Үзе чем-кара, күзләре ут булып яна.
3) Галләметдин абыйлар ягында әрле-бирле йөренә.
4) Көчек, җиргә куюга, әнисенә барып сыенды.
5) Кошларны, җәнлекләрне рәнҗетмәгән, кыен чакта аларга ярдәм кулы сузган кешеләрне яратам мин.

Җавап: ___________________________.

**7** ***Лексик анализ.***
Тексттан «кысан» сүзенә синоним булган сүзне табып языгыз.

Җавап: ___________________________.

***Барлык җавапларны, эшне башкару буенча күрсәтмәдә әйтелгәнчә, 1 нче номерлы бланкка күчереп язарга онытмагыз. Һәр җавапның тиешле бирем номеры язылган юлда булуын тикшерегез.***

## II бүлек

**8.1** **«Кошларны, җәнлекләрне рәнҗетмәгән, кыен чакта аларга ярдәм кулы сузган кешеләрне яратам мин, – диде».** Текстта китерелгән бу сүзләрнең мәгънәсен аңлатып, сочинение языгыз.

Укылган тексттан фикерләрегезне раслый торган **ике** дәлил китерегез.

Мисаллар биргәндә, кирәкле җөмләләрне языгыз яисә аларның номерларын күрсәтегез.

Сочинениенең күләме 90 сүздән ким булмаска тиеш.

Әгәр сочинение сөйләп чыгу яки чыганак текстны аңлатуларсыз тулысынча күчереп язу формасында гына булса, мондый эш 0 балл белән бәяләнә.

Сочинениене пөхтә һәм аңлаешлы итеп языгыз.

**8.2** **КОШЛАРНЫ, ҖӘНЛЕКЛӘРНЕ РӘНҖЕТМӘҮ** гыйбарәсен ничек аңлыйсыз? Үзегез формалаштырган билгеләмәне дәлилләгез. Үзегез язган билгеләмәне тезис итеп алып, **«Нинди кеше кошларны, җәнлекләрне рәнҗетми?»** темасына сочинение языгыз. Тезисыгызны раслый торган **ике**

дәлил китерегез: дәлилнең **берсен** укылган тексттан алыгыз, **икенчесен** тормыш тәҗрибәгездән чыгып формалаштырыгыз.

Әгәр сочинение сөйләп чыгу яки чыганак текстны аңлатуларсыз тулысынча күчереп язу формасында гына булса, мондый эш 0 балл белән бәяләнә.

Сочинениенең күләме 90 сүздән ким булмаска тиеш.

Сочинениене пөхтә һәм аңлаешлы итеп языгыз.

***Һәр җавапның тиешле бирем номеры язылган юлда булуын тикшерегез.***

**Дөрес җаваплар**

| **Биремнең номеры** | **Дөрес җавап** |
|---|---|
| 1 | 234 |
| 2 | 13 |
| 3 | авылгатукталдык |
| 4 | 15 |
| 5 | 134 |
| 6 | 25 |
| 7 | тар |

## Татар теле буенча имтихан эшен бәяләү системасы

### I бүлек

1-7 нче биремнәрдә дөрес күрсәтелгән һәр җавап 1 балл белән бәяләнә. Җаваплар биремнәрне үтәү күрсәтмәсендәгечә язылган булса һәм дөрес җавап үрнәге белән тулысынча туры килсә, бирем дөрес үтәлгән дип санала. 1, 2, 3, 4, 5, 6, 7 нче биремнәрнең җавапларын язганда, символлар тәртибе әһәмиятле түгел.

*1 нче таблица*

### II бүлек

### 8 нче биремне бәяләү критерийлары

### 8.1 нче биремнең җавабы түбәндәге критерийлар буенча бәяләнә

*2 нче таблица*

| **№** | **Текст эчтәлеген анализлауга бәйле темага язылган сочинениене (8.1) бәяләү критерийлары** | **Баллар** |
|---|---|---|
| **С1К1** | **Тексттан алынган кисәкнең мәгънәсен аңлау** | |
| | Укучы тексттан алынган кисәкнең эчтәлеген дөрес аңлаткан. Аңлатмада хаталар юк. | 2 |

| | | |
|---|---|---|
| | Укучы тексттан алынган кисәкнең эчтәлеген гомумән дөрес аңлаткан,<br>**ләкин** аңлатмада 1 хата бар. | 1 |
| | Укучы тексттан алынган кисәкнең эчтәлеген дөрес аңлатмаган,<br>**яки** укучы, тексттан алынган кисәкнең эчтәлеген аңлатканда, 2 яки күбрәк хата ясаган,<br>**яки** тексттан алынган кисәк эчтәлегенең аңлатмасы язма эштә юк. | 0 |
| **С1К2** | **Дәлил-мисалларның булуы** | |
| | Укучы <u>тексттан</u> әлеге кисәкнең эчтәлегенә туры килә торган 2 дәлил-мисал китергән. | 3 |
| | Укучы <u>тексттан</u> әлеге кисәкнең эчтәлегенә туры килә торган 1 дәлил-мисал китергән. | 2 |
| | Укучы башка <u>тексттан</u> дәлил-мисал (-лар) китергән. | 1 |
| | Укучы әлеге кисәкнең эчтәлеген аңлата торган дәлил-мисал китермәгән,<br>**яки** укучы биремдәге цитатаны я аның бер өлешен дәлил-мисал итеп китергән. | 0 |
| **С1К3** | **Язманың мәгънәви бөтенлеге, сөйләмнең бәйләнешле булуы, язу эзлеклелеге** | |
| | Укучының эше мәгънәви бөтенлеге, сөйләмнең бәйләнешле булуы һәм язу эзлеклелеге белән характерлана:<br>– логик хаталар юк, язуда эзлеклелек бозылмаган;<br>– абзацларга бүленештә хаталар юк. | 2 |
| | Укучының эше мәгънәви бөтенлеге, сөйләмнең бәйләнешле булуы һәм эзлеклелек белән характерлана,<br>**ләкин** 1 логик хата бар,<br>**һәм/яки** абзацларга бүленештә 1 урында хата бар. | 1 |
| | Язмада сөйләм үстерүгә омтылыш бар,<br>**ләкин** логик хаталарның саны 1 дән артык,<br>**һәм/яки** абзацларга бүленештә 2 урында хата бар. | 0 |
| **С1К4** | **Эшнең композицион бөтенлеге** | |
| | Эш композицион яктан бөтен һәм төгәлләнгән, текст төзүдә хаталар юк. | 2 |
| | Эш композицион яктан бөтен һәм төгәлләнгән,<br>**ләкин** текст төзүдә 1 хата бар. | 1 |
| | Текст төзүдә 2 яки күбрәк хата бар. | 0 |
| **С1К1-С1К4 критерийлары буенча сочинение өчен иң югары балл** | | **9** |

**Игътибар!**

Чыганак текст күчереп кенә язылган яки текстның эчтәлеге генә чагылыш тапкан сочинение барлык критерийлар буенча (С1К1-С1К4) **0 балл** белән бәяләнә.

Башка текст нигезендә язылган сочинение С1К1-С1К4 критерийлары буенча **0 балл** белән бәяләнә.

Язма эшнең грамоталылыгы һәм аның фактик төгәллеге аерым бәяләнә (4 нче таблицаны кара).

### 8.2 нче биремнең җавабы түбәндәге критерийлар буенча бәяләнә

*3 нче таблица*

| № | Текст эчтәлеген анализлауга бәйле темага язылган сочинениене (8.2) бәяләү критерийлары | Баллар |
|---|---|---|
| **С2К1** | **Төшенчәнең мәгънәсен аңлату** | |
| | Укучы (сочинениенең теләсә кайсы өлешендә теге яки бу формада) төшенчәгә билгеләмә биргән һәм аңлаткан. | 2 |
| | Укучы (сочинениенең теләсә кайсы өлешендә теге яки бу формада) төшенчәгә билгеләмә биргән,<br>**ләкин** аңлатмаган. | 1 |
| | Укучы төшенчәгә дөрес билгеләмә бирмәгән<br>**яки** укучының эшендә төшенчә аңлатылмаган. | 0 |
| **С2К2** | **Дәлил-мисалларның булуы** | |
| | Укучы 2 дәлил-мисал китергән: берсе – тексттан, икенчесе тормыш тәҗрибәсеннән алынган<br>**яки** укучы укылган тексттан 2 дәлил-мисал китергән. | 3 |
| | Укучы укылган тексттан 1 дәлил-мисал китергән. | 2 |
| | Укучы тормыш тәҗрибәсеннән дәлил-мисал (-лар) китергән. | 1 |
| | Укучы дәлил-мисал китермәгән. | 0 |
| **С2К3** | **Язманың мәгънәви бөтенлеге, сөйләмнең бәйләнешле булуы, язу эзлеклелеге** | |
| | Укучының эше мәгънәви бөтенлеге, сөйләмнең бәйләнешле булуы һәм язу эзлеклелеге белән характерлана:<br>– логик хаталар юк, язуда эзлеклелек бозылмаган;<br>– абзацларга бүленештә хаталар юк. | 2 |
| | Укучының эше мәгънәви бөтенлеге, сөйләмнең бәйләнешле булуы һәм эзлеклелек белән характерлана,<br>**ләкин** 1 логик хата бар,<br>**һәм/яки** абзацларга бүленештә 1 урында хата бар. | 1 |

| | | |
|---|---|---|
| | Язмада сөйләм үстерүгә омтылыш бар,<br>**ләкин** логик хаталарның саны 1 дән артык,<br>**һәм/яки** абзацларга бүленештә 2 урында хата бар. | 0 |
| **С2К4** | **Эшнең композицион бөтенлеге** | |
| | Эш композицион яктан бөтен һәм төгәлләнгән, текст төзүдә хаталар юк. | 2 |
| | Эш композицион яктан бөтен һәм төгәлләнгән,<br>**ләкин** текст төзүдә 1 хата бар. | 1 |
| | Текст төзүдә 2 яки күбрәк хата бар. | 0 |
| **С2К1-С2К4 критерийлары буенча сочинение өчен иң югары балл** | | **9** |

**Игътибар!**

Чыганак текст күчереп кенә язылган яки текстның эчтәлеге генә чагылыш тапкан сочинение барлык критерийлар буенча (С2К1-С2К4) **0 балл** белән бәяләнә.

Башка сүз (гыйбарә) нигезендә язылган сочинение С2К1-С2К4 критерийлары буенча **0 балл** белән бәяләнә.

Язма эшнең грамоталылыгы һәм аның фактик төгәллеге аерым бәяләнә (4 нче таблицаны кара).

*4 нче таблица*

| № | Укучы сөйләменең грамоталылыгын һәм фактик төгәллеген бәяләү критерийлары | Баллар |
|---|---|---|
| **ГК1** | **Орфографик нормаларның үтәлеше** | |
| | Орфографик хаталары юк **яки** хатасы 1 дән артык түгел | 2 |
| | 2-3 хата җибәрелгән | 1 |
| | Хаталарының саны 4 тән артык | 0 |
| **ГК2** | **Пунктуацион нормаларның үтәлеше** | |
| | Пунктуацион хаталары юк **яки** хатасы 2 дән артык түгел | 2 |
| | 3-4 хатасы бар | 1 |
| | Хаталарының саны 5 тән артык | 0 |
| **ГК3** | **Грамматик нормаларның үтәлеше** | |
| | Грамматик хаталары юк **яки** 1 хатасы бар | 2 |
| | 2 хатасы бар | 1 |
| | Хаталарының саны 3 тән артык | 0 |
| **ГК4** | **Сөйләм нормаларының үтәлеше** | |
| | Сөйләм хаталары юк **яки** хатасы 2 дән артык түгел | 2 |
| | 3–4 хатасы бар | 1 |
| | Хаталарының саны 5 тән артык | 0 |
| **ФК1** | **Язма сөйләмнең фактик төгәллеге** | |
| | Материалны язмада бирүдә, шулай ук аңлауда һәм терминнар кулланылышында фактик хаталар юк | 2 |

| | | |
|---|---|---|
| | Материалны язмада бирүдә яки терминнар кулланылышында 1 хата бар | 1 |
| | Материалны язмада бирүдә яки терминнар кулланылышында 2 хата бар | 0 |
| **ГК1-ГК4, ФК1 критерийлары буенча сочинение өчен иң югары балл** | | **10** |

Грамоталылыкны бәяләгәндә (ГК1–ГК4), **сочинениенең күләмен** истә тотарга кирәк.

4 нче таблицада бирелгән нормативлар сочинениедә 90 һәм күбрәк сүз булган очракта тәкъдим ителә.

Әгәр сочинениедә 45-89 сүз булса, ГК1–ГК4 критерийлары буенча 1 дән артык балл куелмый:

ГК1 – орфографик хаталар булмаса, 1 балл куела.

ГК2 – пунктуацион хаталар булмаса, 1 балл куела.

ГК3 – грамматик хаталар булмаса, 1 балл куела.

ГК4 – сөйләм хаталары булмаса, 1 балл куела.

ФК1 – фактик хаталар булмаса, 1 балл куела.

Әгәр сочинениенең күләме 45 сүз һәм 45 сүздән дә кимрәк булса, ГК1–ГК4, ФК1 критерийлары буенча мондый эш 0 балл белән бәяләнә.

Имтиханны тулаем башкару барышында җыярга мөмкин булган максималь балл – **33.**

**Имтихан эше өчен түбәндәге билгеләр куела:**

0-14 балл – «2» ле билгесе;

15-22 балл – «3» ле билгесе;

23-28 балл – «4» ле билгесе. Искәрмә: бу очракта укучының ГК1-ГК4 критерийлары буенча баллары 4 тән кимрәк булмаска тиеш. Әгәр ГК1-ГК4 критерийлары буенча баллары 4 тән кимрәк булса, «3» ле билгесе куела.

29-33 балл – «5» ле билгесе. Искәрмә: бу очракта укучының ГК1-ГК4 критерийлары буенча баллары 6 дан кимрәк булмаска тиеш. Әгәр ГК1-ГК4 критерийлары буенча баллары 6 дан кимрәк булса, «4» ле билгесе куела.

## 83 НЧЕ КОД БУЕНЧА БИРЕМНӘР

**Рус телендә белем бирү мәктәпләренең**
**рус телле укучылары өчен**
**туган (татар) телдән дәүләт йомгаклау аттестациясен уздыру материаллары**

**Эшне башкару өчен күрсәтмә**

Татар теленнән төп дәүләт имтиханын тапшыру өчен, 3 сәгать 55 минут (235 минут) вакыт бирелә. Имтихан эше **33 биремне** үз эченә алган **4** бүлектән тора. **1 нче бүлектәге** 13 бирем (1 – 13 нче биремнәр) укучыларның тыңлап аңлау күнекмәләрен тикшерүгә юнәлтелгән. **2 нче бүлектәге** 7 бирем (14 – 20 нче биремнәр) укучыларның уку күнекмәләрен тикшерү максатыннан бирелә. **3 нче бүлектәге** 8 бирем (21 – 28 нче биремнәр) укучыларның лексик-грамматик күнекмәләрен тикшерүгә кайтып кала. **4 нче бүлектәге** 29 – 32 нче биремнәр сөйләм ситуациясенә караган татарча репликалар язуны күздә тота. Ачык типтагы **33 нче бирем** укучыларның язма сөйләмен тикшерүгә юнәлдерелгән.

**Уңышлар телибез!**

**Инструкция по выполнению работы**

Время, отведенное на выполнение заданий – 3 часа 55 минут (235 минут). Экзаменационная работа по татарскому языку состоит из четырех разделов, включающих 33 задания. **Раздел 1** (задания по аудированию) включает 13 заданий на понимание аутентичных текстов (задания 1 - 13). **Раздел 2** (задания по чтению) включает в себя 7 заданий (задания 14 - 20). **Раздел 3** (задания по лексике и грамматике) состоит из 8 заданий (задания 21 - 28). **Раздел 4** (задания по письменной речи) состоит из 4 заданий на написание реплик по предложенной коммуникативной ситуации (задания 29 – 32) и задания, в котором предлагается написать личное письмо (задание 33).

**Желаем успеха!**

## 1 нче вариант

## Раздел 1

***Прослушайте 7 коротких диалогов. В заданиях 1 - 7 укажите правильный вариант ответа. Вы услышите аудиозапись дважды.***

**1** **Киләсе атнада Айсылу кая барырга җыена?**
1) китап кибетенә
2) дусты белән кибеткә
3) дустының туган көненә

**2** **Дуслар кайда очрашырга сүз биргәннәр?**
1) урман янында
2) тау янында
3) шугалак янында

**3** **Рәшиткә кайсы һөнәр ошый?**
1) тәрҗемәче
2) тарихчы
3) укытучы

**4** **Айсылуга кайсы спорт төре ошый?**
1) фигуралы шуу
2) тимераякта шуу
3) йөзү

**5** **Айсылу кайсы фәннән олимпиадада катнашачак?**
1) татар теленнән
2) әдәбияттан
3) тарихтан

**6** **Айсылу кайда ял итәргә тели?**
1) тауларда
2) диңгездә
3) көньякта

**7** **Рәшитнең дуслары нинди?**
1) җаваплы
2) җитез
3) җитди

***Прослушайте разговор двух друзей. Определите, какие из приведенных утверждений 8 - 13 соответствуют содержанию текста (1), а какие – не соответствуют (2). Вы услышите аудиозапись дважды.***

**8** Дуслар яраткан дәресләре турында сөйләшәләр.

1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**9** Самат буш вакытында укырга ярата.

1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**10** Алсуны сәнгать кызыксындыра.

1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**11** Самат соңгы вакытта бер хикәя укыган.

1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**12** Самат дустын яңа белем бирү порталлары белән таныштыра.

1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**13** Алсу портретлар ясарга ярата.

1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

## Раздел 2

***Прочитайте тексты в заданиях 14 – 16. После каждого текста определите правильный вариант ответа.***

**14**

Этләр һәм песиләр күргәзмәсенә чакырабыз!

Шимбә – гаилә һәм дуслар белән бергә ял итә торган көн. Матур итеп күңел ачу өчен, Казанда төрле чаралар уздырыла. “Казан ярминкәсе” күргәзмә үзәге сезне этләр, песиләр һәм декоратив күселәр күргәзмәсенә чакыра. Анда сезне өйрәтелгән хайваннарның чыгышларыннан тыш, тропик күбәләкләр паркы һәм тотып карый торган зоопарк та көтә. Барлык павильоннар сәгать иртәнге уннан кичке җидегә кадәр эшли.
Ялларыгыз күңелле үтсен!

**Белдерүдә нәрсә турында әйтелә?**

1) Күргәзмә үзәгендә уздырылачак хайваннар ярышлары турында.

2) Күргәзмә үзәгендә үтәчәк чараларга чакыру турында.

3) Күргәзмә үзәгендә эшли торган күбәләкләр паркы турында.

**15**

Татарстанда узачак Әлфия Авзалова исемендәге халыкара фестиваль-конкурска рәхим итегез!
Халыкара татар җыры фестиваленең максаты – сәләтле яшьләргә ярдәм итү, аларның иҗади

**Бу хәбәр нәрсә турында?**

1) Яшь җырчыларны яңа бәйгегә чакыру турында.

| | | |
|---|---|---|
| | үсеше өчен шартлар тудыру һәм һөнәри осталыкларын камилләштерү. Анда катнашырга Россиянең төрле шәһәрләреннән яшьләр чакырыла. Катнашу өчен гаризалар 10 нчы декабрьгә кадәр кабул ителә. Фестивальнең гала-концерты 24 нче февральдә үткәреләчәк. Җиңүчеләр гала-концертта бүләкләнәчәк. Яшь җырчыларны яңа бәйгедә көтеп калабыз. Халыкара фестиваль-конкурс турында тулырак мәгълүматны сайтта табарга мөмкин.<br>Белешмәләр өчен: 231-18-28. | 2) Яшь җырчылар бәйгесенең максаты турында.<br>3) Яшь җырчылар фестивалендә җиңүчеләр турында. |
| **16** | Хәерле көн, Әнисә! Хәлләрең әйбәтме? Тормышыңда нинди яңалыклар бар?<br>Минем хәлләрем әйбәт, укулар да яхшы бара. Быел мин “Татар кызы” бәйгесендә катнаштым, призлы урын алдым. Җиңүчеләргә диплом һәм бүләк бирделәр. Бу бәйгедә шәһәрнең төрле мәктәпләреннән кызлар катнашты. Без татар биюе, татар җыры башкардык, шулай ук һәркем үзе яраткан шагыйрьнең бер шигырен яттан сөйләргә тиеш иде. Без матур милли киемнәрдән чыгыш ясадык. Бәйге бик күңелле узды, мин яңа дуслар таптым. Ә син нинди чараларда катнаштың? Вакытың булгач, миңа хат яз, көтәм.<br>Сәлам белән дустың Камилә. | **Электрон хатында Камилә дустына нәрсә турында язган?**<br>1) Шәһәрдә үткәрелгән яңа бәйгедә беренче урын алуы турында.<br>2) Шәһәр бәйгесендә катнашып, җиңүе турында.<br>3) Шәһәрдә үткәрелә торган төрле бәйгеләр турында. |

***Прочитайте текст. В заданиях 17 - 20 укажите правильный вариант ответа.***

Әтисе Гүзәлгә курчак алып кайтты. Исеме дә бар. Айсылу исемле.
— Иптәшләрең белән бергәләп уйнарсыз, — диде әтисе. Әй шатланды соң Гүзәл! Җитен чәчле, зәңгәр күзле курчагын кулыннан төшермәде. Җайсызрак тотканда, Айсылу:
— Ән-нә,ән-нәү-ү... — дип тавыш та бирә белә иде.
Бүген ял көне. Гүзәлне бакчага илтмәделәр. Ул, сөенеп, Айсылу белән уйный гына башлаган иде, күрше кызы Рәйханәнең тавышы ишетелде:
— Гүзәл, әйдә, уйнарга!
Кыз, тиз-тиз киенде дә урамга йөгерде. Айсылуның:
— Мине дә алып чык, бергә-бергә уйнарбыз, — дип, курчагының ялварып карап калуын да күрмәмешкә салышты.

— Әйем лә, синең белән үзем генә уйнармын, — дип, ашыгып, ишекне япты. Чөнки Рәйханәнең курчак белән уйнавын теләмәде ул. Урамда комнан әллә нәрсәләр ясап бетерделәр. Тора-бара Гүзәл курчагы турында тәмам онытты. Өйгә кергәч кенә, янә хәтеренә төшерде, йөгереп килеп, Айсылуны кулына алды.Чү! Ни булган аңа? Кулга алуга:
— Ән-нәү-ү, тимәү-ү! — дигән сыман ыңгырашты да күзләрен йомды.
— Әни, әнием, — дип, алгы бүлмәгә йөгереп керде Гүзәл. — Айсылу минем белән уйнарга теләми. Әнисе кызына карады.
— Әллә үпкәләттеңме үзен?
Гүзәл ни дияргә белмәде. Бары шунда гына әтисе әйткән сүзләрне исенә төшерде. «Иптәшләрең белән бергәләп уйнарсыз...» — дигән иде бит. Гүзәл курчагының чәченнән йомшак кына сыйпап алды:
— Син ачуланма инде, икенче тапкыр сине дә дусларым янына алып чыгармын... — диде.
Айсылу әйтерсең лә шуны гына көтеп торган, ул зәңгәр күк йөзе төсле күзләрен ачып җибәрде. (*Рафис Гыйззәтуллин*)

**17** Курчак алып кайткач, әтисе кызына нишләргә кушты?
1) Курчакны дусларына бирмәскә.
2) Курчакны урамга алып чыкмаска.
3) Дуслары белән бергә уйнарга.

**18** Гүзәл, ни өчен ашыгып, урамга чапты?
1) Аның курчагы белән уйныйсы килмәде.
2) Аны күрше кызы чакырды.
3) Аның комда уйныйсы килде.

**19** Гүзәлнең курчагы нәрсәгә үпкәләгән?
1) Гүзәл аны дуслары янына алып чыкты.
2) Кыз курчагын дустына бирде.
3) Гүзәл курчагын үзе белән алмады.

**20** Кыз курчактан ничек гафу үтенде?
1) Ул, курчагының чәченнән сыйпап, аны юатты.
2) Ул, курчакны кочагына алып, аны тынычландырды.
3) Ул, курчакның кулын тотып, аңа матур сүзләр әйтте.

## Раздел 3

***Прочитайте текст. В заданиях 21 – 28 определите правильный вариант ответа.***

Беркөн мин улым Рөстәм белән әбиләрдә (21) ... булдым. Самовар, җырлый-җырлый, (22) ... килеп басты. Самовар артыннан ит сумсалары, алма, карбызлар, конфетлар килеп тулдылар өстәлгә. Алмалары: «Мине ал, мине ал!»;

конфетлары: «Кулыңны (23) ... ! Ах, тәмле без, ах, тәмле!»; карбызлары: «Без ал, кызыл төстә. Ал,кызыл! Кап авызыңа, (24) ...», — диләр, безне кызыктыралар.

Рөстәм кулын сузарга ашыкмады. Башта ул (25) ... карады. Аннан әбисенә карады. Әбисе аның (26) ... өч сумса салды. Мин бер алма алып бирдем. Апасы аның алдына конфет, бер телем карбыз (27) ... . Улым үзен бик әдәпле тотты. Ашыкмый гына ашады, авызын чапылдатмады. Ашъяулыкка карбыз суын (28) .... . *(Дәрҗия Аппакова)*

**21** 1) ялга 2) кунакта 3) сәяхәттә

**22** 1) өстәлдә 2) өстәлне 3) өстәлгә

**23** 1) суз 2) бир 3) ал

**24** 1) эредек 2) эрербез 3) эриләр

**25** 1) мине 2) миннән 3) миңа

**26** 1) урынына 2) тәлинкәсенә 3) калагына

**27** 1) куйды 2) куяр 3) куячак

**28** 1) агызгач 2) агызды 3) агызмады

## Раздел 4

***В заданиях 29-32 необходимо написать репли ки в соответствии с заданной речевой ситуацией.***

**Сөйләм ситуациясенә туры килгән репликаларны языгыз.**

**29** Сообщите другу (подруге), что в экстрим-парке “Урам” состоится фестиваль уличной культуры.

**30** Спросите у друга (подруги), как он (она) провел(а) зимние каникулы.

**31** Предложите однокласснику посетить в летние каникулы Великий Булгар.

**32** Спросите у своих родителей, пойдут ли они в этом году на классический фестиваль балета имени Рудольфа Нуриева.

**33** **Вы получили письмо от друга (подруги). Напишите ему (ей) письмо объемом не менее 60 слов, ответив на его (её) вопросы.**
**Для ответа на это задание используйте специальный бланк ответов.**

| |
|---|
| *... Мин ял көннәрендә заманча бию түгәрәгенә йөрим. Без төрле концертларда катнашабыз, бәйрәмнәрдә чыгыш ясыйбыз. Безнең коллектив бик дус. Анда төрле мәктәпләрдән кызлар һәм егетләр йөри.* <br><br> *... Ә син нинди дә булса түгәрәккә яки секциягә йөрисеңме?...Анда нәрсәләр белән шөгыльләнәсез? ... Кайларда чыгыш ясыйсыз?* |

**Тыңлап аңлау биремнәре өчен текстлар**

**Прослушайте 7 коротких диалогов. В заданиях 1 - 7 укажите правильный вариант ответа. Вы услышите аудиозапись дважды.**

**Беренче сорау. Киләсе атнада Айсылу кая барырга җыена?**

Айсылу: Сәлам, Рәшит!

Рәшит: Сәлам, Айсылу! Дәресләрдән соң бию түгәрәгенә барасыңмы?

Айсылу: Бүген анда дәресләр юк. Бүген дәресләрдән соң китап кибетенә барырга җыенам, чөнки киләсе атнада дустымның туган көне, аңа бүләк алырга телим.

Рәшит: Камиләнең туган көнемени? Ничәсендә? Мин дә котлармын.

Айсылу: Унбишендә, җомга көнне.

Рәшит: Яхшы, рәхмәт. Ә син нинди бүләк алырга телисең?

Айсылу: Мин аңа "Татар милли ашлары" китабын бүләк итәргә телим, чөнки ул пешерергә ярата.

Рәшит: Кызык! Ә нәрсәләр пешерә?

Айсылу: Өчмочмак, кыстыбый.

Рәшит: Менә уңган кыз! Афәрин!

[2 секунд пауза]

Прослушайте диалог второй раз.

[язма икенче тапкыр яңгырый]

[2 секунд пауза]

**Икенче сорау. Дуслар кайда очрашырга сүз биргәннәр?**

Рәшит: Айсылу, ял көннәрендә нишләргә җыенасың?

Айсылу: Әле уйламадым, бу атнада контроль эшләр бик күп. Башым авырта, шуңа күрә саф һавада буласым килә.

Рәшит: Әйе, дәресләр күп, саф һавада аз булабыз. Сәламәтлек турында онытмаска кирәк.

Айсылу: Шулай шул, мин синең белән килешәм. Сәламәтлек – иң зур байлык, диләр. Һәр кеше сәламәтлеге турында кайгыртырга тиеш.

Рәшит: Шуңа күрә мин сиңа чаңгы шуарга барырга тәкъдим итәм. Безнең өйдән ерак түгел тау бар, анда ял көннәрендә кеше күп була. Бик күңелле. Синең чаңгың бармы соң? Булмаса, прокатка алырга мөмкин, анда чаңгы базасы эшли.

Айсылу: Чаңгым бар. Буш вакытым булганда, без дус кызым Камилә белән урманда чаңгы шуабыз. Кайбер көннәрне кичләрен шугалакта тимераякта шуабыз. Безнең өй каршында шугалак бар.

Рәшит: Бик яхшы. Алайса кайда очрашабыз?

Айсылу: Әйдә, тау янында очрашыйк. Мин шунда килермен. Син иртәрәк килсәң, шуа торырсың.

Рәшит: Сөйләштек. Рәхәтләнеп ял итәрбез саф һавада.

**[2 секунд пауза]**
**Прослушайте диалог второй раз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый] **[2 секунд пауза]**

**Өченче сорау. Рәшиткә кайсы һөнәр ошый?**
Рәшит: Айсылу, синдә һөнәрләр турында татарча китап юкмы?
Айсылу: Карарга кирәк. Ә нигә сорыйсың?
Рәшит: Миңа һөнәрләр турында татарча проект эше әзерләргә кирәк. Интернеттан кайбер мәгълүматны таптым, ләкин аз булды, шуңа күрә синнән ярдәм сорыйм.
Айсылу: Ә сиңа кайсы һөнәр ошый соң? Син тарих дәресләрен дә, рус әдәбияты дәресләрен дә бик яратасың бит. Укытучы буласың киләме?
Рәшит: Укытучы һөнәре – бик мактаулы һөнәр, ләкин миңа башка һөнәр күбрәк ошый. Мин телләр өйрәнергә яратам, инглизчә, испанча беләм.
Айсылу: Синең тәрҗемәче буласың киләме? Мин дөрес уйлыйммы?
Рәшит: Әйе, дөрес. Бу һөнәр миңа бик ошый. Әнием дә минем белән килешә. Ә син кем булырга телисең?
Айсылу: Мин белмим әле, сайларга кирәк.
Рәшит: Ярар, вакыт бар әле.
[2 секунд пауза]
**Диалогны икенче тапкыр тыңлагыз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**

**Дүртенче сорау. Айсылуга кайсы спорт төре ошый?**
Рәшит: Айсылу, сәлам, хәлләр ничек? Син спорт секциясенә киттеңме?
Айсылу: Сәлам, Рәшит! Әйе, бүген тренировка бар, сәгать дүрттә башлана. Соңга калырга ярамый, тренерыбыз бик таләпчән. Ә син кая киттең?

Рәшит: Мин рус теленнән өстәмә дәрескә барам. Имтиханга яхшырак әзерләнү өчен, әни өстәмә дәресләргә йөрергә кушты. Атнага ике тапкыр йөрим. Дәресем бишенче яртыда башлана. Син ничә ел инде йөзү белән шөгыльләнәсең?
Айсылу: 4 ел инде. Бу спорт төре миңа бик ошый. Уңышларым да аз түгел. Республика ярышларында катнашам, призлы урыннар да алганым бар. Спорт миңа укуымда да булыша. Мин авырлыкларны җиңәргә, үз вакытымны файдалы үткәрергә өйрәнәм.
Рәшит: Әйе, бик дөрес, спорт күп нәрсәгә ирешергә ярдәм итә. Мин дә берничә ел тимераякта шуу белән шөгыльләндем. Хәзер вакыт җитми, шуңа күрә быел тренировкаларга йөрмим. 10 нчы сыйныфта спорт белән шөгыльләнүне дәвам итәрмен дип уйлыйм.
Айсылу: Шулай, бу уку елында имтиханнар тапшырабыз шул. Барысына да вакыт җиткереп булмый. Сиңа да, миңа да тырышырга кирәк.
[2 секунд пауза]
**Прослушайте диалог второй раз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**

**Бишенче сорау. Айсылу кайсы фәннән олимпиадада катнашачак?**

Рәшит: Айсылу, син бу атнада ял көннәрендә кайда булырсың? Әти-әниең белән авылга кайтырсыңмы?

Айсылу: Юк, мин авылга кайтмыйм, өйдә калам, чөнки киләсе атнада район олимпиадасы була. Укытучыбыз миңа әзерләнергә кушты.

Рәшит: Шулаймы? Син кайсы фәннән катнашасың?

Айсылу: Мин ел саен төрле фәннәрдән катнаша идем, ә быел әдәбияттан гына әзерләнергә вакытым бар, чөнки инглиз теле курсларына да йөрим. Ә синең олимпиадаларда катнашканың бармы?

Рәшит: Былтыр мин, тарихтан район олимпиадасында катнашып, икенче урын алдым, аннары республика олимпиадасында да җиңү яуладым. Быел да катнашырга уйлыйм. Бу фәннән олимпиада соңрак була әле, әзерләнергә вакыт бар.

Айсылу: Ә миңа вакыт аз калды шул, шуңа күрә көн саен шөгыльләнергә кирәк. Алайса кабатлап чыгарга өлгермим.

Рәшит: Әйе, бәйгеләрдә җиңү өчен, күп укырга, күп белергә кирәк. Катнашучылар барысы да көчле була.

Айсылу: Тырышам инде, нишлисең бит, мәктәп данын якларга кирәк.

Рәшит: Уңышлар сиңа, дустым.

[2 секунд пауза]

**Диалогны икенче тапкыр тыңлагыз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**

**Алтынчы сорау. Айсылу ничек ял итәргә тели?**

Рәшит: Айсылу, җәйге ял башлангач, кайда буласың?

Айсылу: Имтиханнарны уңышлы тапшырсам, әллә кайларга барырмын кебек.

Рәшит: Мәсәлән, сиңа нинди ял күбрәк ошый? Бакчадамы, диңгездәме, әллә таулардамы? Имтиханнар бетүгә, син кая телисең, шунда китә аласың. Көньякка да барырга мөмкин, төньякка барырга теләүчеләр дә аз түгел. Җаның ни тели, шуны сайла.

Айсылу: Син әйткәнчә генә түгел шул. Башта әти-әнинең ялга чыгуын көтәргә кирәк. Аннары гына каядыр баруны хәл итеп була.

Рәшит: Гадәттә алар кайсы айда ял алалар?

Айсылу: Әти дә, әни дә июль аенда ял алырга тырышалар, чөнки бу вакытта һава торышы бик яхшы була.

Рәшит: Әйе шул, күпчелек кешеләр бу айда ял итәргә омтылалар.Ә сезнең планнарыгыз нинди? Кайсы якка юл тотарга җыенасыз?

Айсылу: Быел әти белән әниемнең Пятигорск шәһәренә барасы килә, чөнки анда табигать бик матур, тауларга менәргә мөмкин, тарихи урыннар да бар. Миңа аеруча таулар ошый, шуңа күрә мин дә алар белән килештем.

Рәшит: Яллар күңелле үтсен!

Айсылу: Рәхмәт!

**[2 секунд пауза]**
**Прослушайте диалог второй раз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**

**Җиденче сорау. Рәшитнең дуслары нинди?**

Рәшит: Айсылу, синең иң якын дусларың кемнәр?

Айсылу: Беләсең киләме, Рәшит? Иң якын дусларым – Алсу һәм Әминә.

Рәшит: Сез сыйныфташлармы?

Айсылу: Әйе, без беренче сыйныфтан бергә укыйбыз, бер йортта яшибез. Без – чын дуслар. Ярдәм кирәк булса, без һәрвакыт бер-беребезгә булышырга әзер. Бергә саф һавада йөрибез, кинога, театрга барабыз. Без гел бергә.

Рәшит: Шундый дусларың булу белән син бик бәхетледер. Яхшы дуслар булу – зур байлык ул. Дуслар шатлыкта да, кайгыда да кирәк, диләр. Минемчә, дусларсыз яшәү мөмкин түгел..

Айсылу: Әлбәттә, шулай. Ә синең дусларың кемнәр, Рәшит?

Рәшит: Минем дусларым күп, ләкин ике якын

дустым бар: Марат һәм Айрат. Без сыйныфташлар түгел, Марат сигезенче сыйныфта укый, Ә Айрат – унынчы сыйныф укучысы. Алар бик ярдәмчел, юмарт һәм җитди.

Айсылу: Сез күптән дусłармы?

Рәшит: Менә 5 ел була инде. Марат белән Айрат безнең мәктәпкә күчтеләр, һәм шул вакыттан алып, без – яхшы дуслар. Без күрше йортларда яшибез.

**[2 секунд пауза]**
**Прослушайте диалог второй раз.**

[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**

***Прослушайте разговор двух друзей. Определите, какие из приведенных утверждений 8 - 13 соответствуют содержанию текста, а какие – не соответствуют. Вы услышите аудиозапись дважды.***

**[пауза 20 секунд]**

Самат: Сәлам, Алсу!

Алсу: Сәлам, Самат! Әйт әле, син нәрсәләр белән кызыксынасың?

Самат: Минем яраткан шөгыльләрем – шахмат уйнау һәм кызыклы маҗаралар турында уку.

Алсу: Шулаймыни? Маҗаралар турында әсәрләр укыйсыңмы яки Интернеттан кызыклы мәгълүмат табасыңмы?

Самат: Танылган язучыларның фантастик әсәрләрен дә укыйм, Интернеттан да мавыктыргыч мәкаләләр, хикәяләр табам.

Алсу: Кызык! Соңгы вакытта нинди язмалар белән таныштың? Әйтә аласыңмы?

Самат: Әйе. Мин Рәис Мөхәммәдиевнең берничә хикәясен укыдым. Мәсәлән, “Билгесез планетада”, “Кактус”, “ Ирек маҗаралары” һәм башкалар.

Алсу: Син аларны китапханәдән алдыңмы?

Самат: Юк, Интернеттан таптым. Анда “Фантат” исемле сайт бар, шунда әлеге хикәяләр урнаштырылган. Һәркем укый ала. Синең дә укыйсың киләме, Алсу?

Алсу: Юк. Миңа андый әсәрләр кызык түгел. Мин сәнгать белән күбрәк кызыксынам, сәнгать мәктәбендә укыдым бит. Шуңа күрә мин танылган рәссамнарның тормышы һәм иҗаты турында язмалар укырга яратам.

Самат: Яраткан рәссамың бармы?

Алсу: Миңа берничә рус рәссамының иҗаты ошый, бигрәк тә Иван Айвазовскийның картиналарына гашыйкмын. Татар рәссамнарына килгәндә, Бакый Урманченың иҗаты белән безне татар теле дәресләрендә укытучыбыз таныштырды. Каникул вакытында без аның музеенда да булдык, атаклы картиналарын күрдек.

Самат: Бик яхшы булган. Син дә Айвазовский кебек диңгезне сурәтләргә яратасыңмы?

Алсу: Мин пейзажлар ясарга яратам. Үзебезнең туган як табигате миңа бик ошый. Рәсемнәремдә көзге урманны, кышкы көнне, язгы матурлыкны күрсәтергә тырышам.

Самат: Рәсемнәреңне миңа да күрсәтерсең әле.

Алсу: Әлбәттә. Безгә кунакка килгәч карарсың. Син миңа тагын нинди кызыклы порталлар белән танышырга киңәш итәсең?

Самат: Төрле фәннәрдән, бигрәк тә астрономия, физика фәннәре буенча язмалар укыйсың килсә, “Гыйлем” порталына мөрәҗәгать итә аласың. Ә менә

татар телен яхшырак беләсең килсә, “Ана теле” онлайн мәктәбенә теркәл һәм өйрән. Бик кызыклы ресурс.

Алсу: Син шундый күп беләсең, Самат! Болар белән танышырга каян вакыт табасың? Син минем өчен үрнәк! Минем дә синең кебек күп беләсем килә.

Самат: Яхшы, үзем танышкан сайтлар белән сине дә таныштырып барырмын. Кызыклы хикәяләрнең сылтамасын сиңа җибәрермен.

Алсу: Шәп! Мин риза! Зур рәхмәт сиңа, дустым.

**[2 секунд пауза]**

**Прослушайте диалог второй раз.**

[язма икенче тапкыр яңгырый]

**[2 секунд пауза]**

**Внесите ответы в бланк ответов.**

**ҖАВАПЛАР**

| **Биремнең номеры** | **Дөрес җавап** |
|---|---|
| 1 | 3 |
| 2 | 2 |
| 3 | 1 |
| 4 | 3 |
| 5 | 2 |
| 6 | 1 |
| 7 | 3 |
| 8 | 2 |
| 9 | 1 |
| 10 | 1 |
| 11 | 2 |
| 12 | 1 |
| 13 | 2 |
| 14 | 2 |
| 15 | 1 |
| 16 | 2 |
| 17 | 3 |
| 18 | 2 |
| 19 | 3 |
| 20 | 1 |
| 21 | 2 |
| 22 | 3 |
| 23 | 1 |
| 24 | 2 |
| 25 | 3 |
| 26 | 2 |
| 27 | 1 |
| 28 | 3 |

**2 нче вариант**

## Раздел 1

***Прослушайте 7 коротких диалогов. В заданиях 1 - 7 укажите правильный вариант ответа. Вы услышите аудиозапись дважды.***

**1** **Рәшит Айсылудан нәрсә ясарга сорый?**

1) әбисенең портретын
2) дустының портретын
3) үзенең портретын

**2** **Дуслар кайда булганнар?**

1) очрашуда
2) туган көн бәйрәмендә
3) күргәзмәдә

**3** **Рәшитнең иң зур хыялы нинди?**

1) тәрҗемәче булу
2) дөнья гизү
3) кешеләрне дәвалау

**4** **Айсылуга нинди кешеләр ошый?**

1) эшчән
2) максатчан
3) акыллы

**5** **Айсылу нәрсәләр укырга ярата?**

1) әдәби әсәрләр
2) хикәяләр
3) тарихи язмалар

**6** **Айсылу кая укырга керергә тели?**

1) техникумга
2) училищега
3) университетка

**7** **Рәшитнең әбисе кайда яши?**

1) Арча районында
2) Биектау районында
3) Мөслим районында

***Прослушайте разговор двух друзей. Определите, какие из приведенных утверждений 8 - 13 соответствуют содержанию текста (1), а какие – не соответствуют (2). Вы услышите аудиозапись дважды.***

**8** Дуслар яраткан шөгыльләре турында фикер алышалар.

1) текстка туры килә  2) текстка туры килми

**9** Самат күптән түгел театрда булган һәм яңа спектакль караган.

1) текстка туры килә  2) текстка туры килми

**10** Бу кызык спектакльнең исеме - “Дию пәрие”.

1) текстка туры килә  2) текстка туры килми

**11** Саматка барысы да ошаган: җырлар да, биюләр дә.

1) текстка туры килә  2) текстка туры килми

**12** Мәктәпне тәмамлагач, Алсу биюче булырга хыяллана.

1) текстка туры килә  2) текстка туры килми

**13** Алсуның дусты белән театрга барасы килә.

1) текстка туры килә  2) текстка туры килми

## Раздел 2

***Прочитайте тексты в заданиях 14 – 16. После каждого текста определите правильный вариант ответа.***

| | | |
|---|---|---|
| **14** | Картиналар галереясына күргәзмәгә чакырабыз!<br><br>Шәһәр үзәк китапханәсенең кече картиналар галереясында яшь рәссамнарның күргәзмәсе оештырыла. Күргәзмәдә төрле техникада башкарылган рәсемнәр, график һәм декоратив эшләр тәкъдим ителә. Шулай ук әкият геройлары сурәтләнгән картиналарны да күрә аласыз. Күргәзмә бик үзенчәлекле һәм кызык.<br>Теләге булган һәркем 1 нче июльгә кадәр яшьләрнең иҗаты белән таныша һәм аларга бәя бирә ала.<br>Галерея иртәнге уннан кичке җидегә кадәр эшли. Рәхим итегез!<br>Белешмәләр өчен телефон: 70-02-26 | **Белдерүдә нәрсә турында әйтелә?**<br>1) Шәһәр китапханәсендә үтәчәк яшь шагыйрьләр белән очрашу турында.<br>2) Яшь рәссамнарның иҗатына багышланган кичә турында.<br>3) Күргәзмәгә чакыру турында. |
| **15** | Балалар музыка мәктәбендә узачак яшь җырчылар бәйгесенә чакырабыз! | **Бу хәбәр нәрсә турында?** |

| | |
|---|---|
| Әлеге чараның төп максаты – сәләтле яшь башкаручыларны ачыклау, җыр сәнгатен үстерү һәм музыка укытучыларының иҗади эшчәнлеген камилләштерү. Яшь җырчылар үзләре сайлап алган ике әсәрне башкарырга тиеш. Бәйгегә гаризалар 1 нче декабрьгә кадәр кабул ителә. Җиңүчеләргә дипломнар тапшырылачак. Яшь җырчыларны әлеге чарада көтеп калабыз. Тулырак мәгълүматны музыка мәктәбенең сайтында таба аласыз.<br>Белешмәләр өчен телефон: 70-00-63. | 1) Музыка мәктәбенә укырга чакыру турында.<br>2) Яшь җырчылар өчен оештырыла торган бәйге турында.<br>3) Яшь җырчылар бәйгесендә җиңүчеләрне бүләкләү турында. |

**16**

| | |
|---|---|
| Хәерле көн, Әминә! Хәлләрең ничек? Укулар ничек бара?<br>Мин әйбәт кенә укып йөрим. Гаиләбездә барысы да әйбәт. Сиңа уңышларым турында язасым килә. Үткән атнада мин университетта үткәрелгән укучылар конференциясендә катнаштым. Анда мин инглиз телендә чыгыш ясадым. Бу чарада төрле мәктәплләрдән укучылар катнашты. Алар барысы да инглиз телендә сөйләде. Миңа берничә сорау да бирделәр, аларга җавап бирә алдым. Минем өчен бу – беренче тәҗрибә. Бик ошады. Ә синең фәнни конференцияләрдә катнашканың бармы? Кайсы фәннән? Вакытың булгач, миңа хат яз, көтәм.<br>Сәлам белән дустың Рамилә. | **Электрон хатында Рамилә дустына нәрсә турында язган?**<br>1) Укучылар конференциясендә чыгыш ясавы турында.<br>2) Университетта үткәрелгән чарада җиңүе турында.<br>3) Инглиз теле дәресендә сорауларга җавап бирүе турында. |

***Прочитайте текст. В заданиях 17 - 20 укажите правильный вариант ответа.***

Бүләк кемгә?

Бервакыт Кояш елның дүрт фасылын — Көзне, Кышны, Язны һәм Җәйне — үзенә чакырып алган.

— Сезнең кайсыгыз матуррак, кайсыгыз эштә батыррак? Шуңа бүләк бирәм, — дигән. Ә бүләк бик затлы икән. Уч тутырып, йолдыз бирергә уйлаган Кояш. Сүзне Көз башлый:

— Үзегез яхшы беләсез: мин бөтен басуларның уңышын җыйдым, бар дөньяны алтынга күмдем. Кошларны җылы якка озаттым, балаларны мәктәпкә җыйдым. Бүләк миңа тиеш!

— Әллә мин аз эшләдемме? — дип сикереп тора Яз.

— Мин барлык карларны эреттем, басуларга иген чәчтем, кошларны чакырып кайтардым, агачларны яфрак ярдырдым, болыннарны чәчәккә күмдем. Арада иң матуры да, иң булдыклысы да мин! — дигән ул.

— Ай-яй, — дигән Җәй, — мине тыңлагыз әле: мин дөньяны яшеллеккә күмәм, чәчәкләр үстерәм, игеннәрне өлгертәм, җимешләрне пешерәм. Әллә мин иң матурыгыз түгелме?
— Артык күп түгел минем эш, — ди тыйнак кына Кыш.
— Мин җирне ял иттерәм, киләсе уңыш өчен карлар ташыйм, дөньяны ап-акка буйыйм, балаларны чана, чаңгы шуарга чакырам. Мин дә ямьсез түгел. Минем чыршыларымны, кар бөртекләремне, бәсләремне яраталар.

Тыңлап-тыңлап торган да Кояш, бүләкне бу дүртәүнең берсенә дә бирә алмаган. Йолдызларны ул күккә сипкән. «Әнә барыгызга да!» — дигән. Йолдызларны елның бер фасылы да үзенә ала алмаган. Алар һәрвакыт — яз да, җәй дә, көз дә, кыш та балкып яналар. (*Татар халык әкияте*)

**17** Кояш ел фасылларына нәрсә бирергә уйлаган?
1) Йөз йолдыз.
2) Бер уч йолдыз.
3) Йолдызлы күк.

**18** Көз нишли?
1) Дөньяны яшелеккә күмә.
2) Кошларны чакырып кайтара.
3) Тирә-якны алтынга күмә.

**19** Язын табигать нишли?
1) Ул чәчәккә күмелә.
2) Ул ял итә.
3) Ул ап-ак була.

**20** Булачак уңыш өчен кайсы ел фасылы күбрәк тырыша?
1) Җәй
2) Көз
3) Кыш

## Раздел 3

***Прочитайте текст. В заданиях 21 – 28 определите правильный вариант ответа.***

Бер кыз (21) ... канатлы булуларына кызыгып яшәгән.
— Ник минем канатларым юк икән? — дигән бу кыз (22) ... .
— Кошларга кызыгасыңмы? — дигән әнисе. — Әйе, бик кызыгам, — дигән кыз. — Канатың (23) ... нишләр идең, балам? — дигән әнисе. — Әллә очып китәр идеңме? Мине калдырып? — Очып китәр идем дә... Очып кайтып җитәр идем, (24) ... сагынып, — дигән кызы. Әнисе кызын (25) ... алган. Кыз да әнисен кочаклаган. — Канатларың булса, кулларың булмас иде. Син мине (26) ... кочаклый алмас идең, кызым, — дигән әнисе. Кыз (27) ... әнисен тагын да кысыбрак кочаклаган. Моннан соң ул кошларга кызыкмаган. Аларга ул бик

яратып карый, кызганып та куя... Үзенең бердәнбер әнисе, әнисен кочакларга ике (28) ... булган өчен шатланып яши икән. (*Рөстәм Мингалим*)

**21** 1) кошларга 2) кошларның 3) кошлардан

**22** 1) әнигә 2) әнисен 3) әнисенә

**23** 1) булса 2) барса 3) алса

**24** 1) синнән 2) сине 3) сиңа

**25** 1) канатына 2) кулына 3) кочагына

**26** 1) андый 2) болай 3) шундый

**27** 1) шунда 2) анда 3) аннары

**28** 1) кул 2) куллары 3) кулы

## Раздел 4

***В заданиях 29-32 необходимо написать реплики в соответствии с заданной речевой ситуацией.***

**Сөйләм ситуациясенә туры килгән репликаларны языгыз.**

**29** Сообщите другу (подруге), что вы с классом посетили новый IT парк.

**30** Спросите у друга (подруги), как он (она) провел(а) выходные дни.

**31** Предложите друзьям покататься в воскресенье на велосипеде.

**32** Спросите у друзей, пойдут ли они на встречу с молодыми татарскими поэтами.

**33** **Вы получили письмо от друга (подруги). Напишите ему (ей) письмо объемом не менее 60 слов, ответив на его (её) вопросы.**

**Для ответа на это задание используйте специальный бланк ответов.**

*... Мин буш вакытымны файдалы үткәрергә тырышам. Мәктәптән кайткач, мин ял итәм, Интернеттан яңа мәгълүмат белән танышам, кичләрен дусларым белән аралашам, саф һавада йөрим, аннары дәресләремне әзерлим, әти-әнием белән сөйләшергә яратам.*
*... Ә син буш вакытыңны ничек үткәрәсең?... Нәрсәләр укырга яратасың? ... Кемнәр белән күбрәк аралашасың?*

## Тыңлап аңлау биремнәре өчен текстлар

**Прослушайте 7 коротких диалогов. В заданиях 1 - 7 укажите правильный вариант ответа. Вы услышите аудиозапись дважды.**
**Беренче сорау. Рәшит Айсылудан нәрсә ясарга сорый?**

Айсылу: Сәлам, Рәшит!

Рәшит: Сәлам, Айсылу! Дәресләрдән соң сәнгать мәктәбенә барасыңмы?

Айсылу: Әйе, бүген анда дәресем бар. Мәктәптән чыгуга, шунда китәм. Без күргәзмәгә әзерләнәбез, шуңа күрә эш күп.

Рәшит: Күргәзмәгә? Кайчан була ул? Минем дә барасым килә.

Айсылу: Безнең мәктәптә ел саен шундый күргәзмә оешырыла. Кызганыч, былтыр мин катнаша алмадым, авырдым. Көне билгеле булгач, мин сиңа әйтермен. Анда безнең эшләрне дә куячаклар.

Рәшит: Кызык. Ә синең рәсемнәрең анда булачакмы?

Айсылу: Әлбәттә. Мин портретлар ясарга яратам. Әбиемнең портретын тәкъдим итәргә уйлыйм.

Рәшит: Ә минем портретны ясый аласыңмы?

Айсылу: Теләсәң ясармын.

Рәшит: Менә уңган кыз! Афәрин!

[2 секунд пауза]

**Прослушайте диалог второй раз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**

**Икенче сорау. Дуслар кайда булганнар?**

Рәшит: Айсылу, мин сине туган көнемә чакырам.

Айсылу: Туган көнең кайчан? Ял көнендәме?

Рәшит: Әйе, якшәмбе көнне миңа 16 яшь тула, дусларымны җыям. Кафеда очрашырбыз дип уйлыйм. Килә аласыңмы?

Айсылу: Әлбәттә. Яхшы дустымны туган көне белән котламый булмый инде. Нәрсә бүләк итим, дустым?

Рәшит: Үзең ни телисең, шуны ал. Син минем яраткан шөгыльләремне беләсең.

Айсылу: Әйе шул. Үткән атнада син мине күргәзмәгә чакырдың бит, шунда мин синең рәсемнәреңне күрдем. Алар миңа бик ошады. Син бик оста рәсем ясыйсың, рәссам булырсың инде.

Рәшит: Юк, бу эш белән мин күңелем өчен шөгыльләнәм. Булачак һөнәргә килгәндә, минем очучы буласым килә.

Айсылу: Бик кирәкле һөнәр, ләкин моның өчен сәламәтлегең бик яхшы булырга тиеш.

Рәшит: Әйе, мин беләм, шуңа күрә спорт белән шөгыльләнергә дә вакыт табам. Эш күп булганда, моңсуланырга вакыт калмый, диләр.

Айсылу: Син хаклы, дустым. Якшәмбегә кадәр! Чакыруың өчен рәхмәт!

**[2 секунд пауза]**
**Прослушайте диалог второй раз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый] **[2 секунд пауза]**

**Өченче сорау. Рәшитнең иң зур хыялы нинди?**

Рәшит: Айсылу, синдә сәяхәтчеләр турында кызыклы китаплар юкмы?

Айсылу: Белмим шул. Карармын. Син сәяхәткә җыенасыңмы?

Рәшит: Юк әле, танылган сәяхәтчеләр турында укыйсым килә. Югары белем алгач, минем иң зур хыялым - төрле илләрдә сәяхәт итү. Көньякта да, төньякта да булу. Менә шуңа duслардан, танышлардан китаплар барлыгын белешергә булдым. Кемдәдер шундый китаплар бардыр. Табылса, бик шат булыр идем.

Айсылу: Ә кемнәр турында укыдың инде?

Рәшит: Безне укытучы татар әдәбияты дәресендә Миргазиян Юнысның иҗаты белән таныштырган иде. Аның тормыш юлы миндә зур кызыксыну уятты. Мин китапханәдән аның китапларын алып укыдым.

Айсылу: Алар сәяхәт итү турындамы?

Рәшит: Язучы аларда якын һәм ерак чит илләрдә яшәүче халыкларның тормышын тасвирлап язган. Ә синең кем буласың килә, Айсылу?

Айсылу: Минем шәфкать туташы буласым килә, кешеләргә ярдәм итәргә, аларны дәваларга телим. Бу һөнәр миңа бик ошый.

**[2 секунд пауза]**
**Диалогны икенче тапкыр тыңлагыз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**

**Дүртенче сорау. Айсылуга нинди кешеләр ошый?**

Рәшит: Айсылу, сәлам, хәлләр ничек?

Айсылу: Сәлам, бик яхшы, рәхмәт!

Рәшит: Синең иң якын дусларың кемнәр?

Айсылу: Минем дусларым күп, ә иң якыннары – Әминә белән Лилия. Алар – минем сыйныфташларым.

Рәшит: Ә минем бер якын дустым бар. Аның исеме – Айдар. Ул башка мәктәптә укый. Без аның белән дзюдо секциясендә дуслаштык. Менә инде биш ел без – чын дуслар. Бергә спорт белән шөгыльләнәбез, походларга йөрибез.

Айсылу: Ә ул кайсы мәктәптә укый?

Рәшит: Ул Мәрҗани исемендәге 2 нче татар гимназиясендә укый, татарча бик яхшы белә. Бу мәктәптә барлык фәннәрне татар телендә укыталар. Ул бик белемле, максатчан, тырыш. Ел саен ул төрле олимпиадаларда катнаша, призлы урыннар ала. Киләчәктә аның табиб буласы килә. Ә синең дусларың нинди?

Айсылу: Минем дус кызларым да бик акыллы. Алар барлык фәннәрдән яхшы укыйлар, җәмәгать эшләрендә дә, волонтерлар булып та төрле чараларда катнашалар. Мин шундый эшчән, күңелле, кызык кешеләр белән аралашырга яратам.

**[2 секунд пауза]**
**Прослушайте диалог второй раз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**

**Бишенче сорау. Айсылу нәрсәләр укырга ярата?**

Рәшит: Айсылу, буш вакытың булганда, син күбрәк нишләргә яратасың?

Айсылу: Буш вакытым булса, мин кибетләрдә йөрергә, яңа киемнәр алырга яратам.

Рәшит: Ә өйдә булганда, нәрсә белән шөгыльләнәсең?

Айсылу: Мин Интернеттан дөнья яңалыклары турында укырга яратам. Ә инде ял көннәрендә мин тарих турында язмалар укыйм. Мин бу фәнне бик яратам, чөнки минем бабам – тарихчы, ул миңа кечкенәдән үк кызыклы вакыйгалар турында сөйли иде. Минем һәрвакыт тагын да күбрәк беләсем килде.

Рәшит: Россия тарихы сине кызыксындырамы?

Айсылу: Әйе, мин төрле чорлар, төрле танылган дәүләт эшлеклеләре, патшалар турында кызыксынып укыйм. Мәсәлән, Бөек Петр Беренче турындагы язмалар миңа бик ошады. Ул Россиянең беренче императоры булган, үз заманында бик күп яңалыклар керткән.

Рәшит: Син шундый кызык сөйлисең, минем дә укыйсым килә башлады. Мин күбрәк фантастик хикәяләр укырга яратам, ә тарих белән моңа кадәр бик кызыксынмый идем. Синең сүзләреңнән соң фикерем үзгәрде.

Айсылу: Мин сиңа шундый шәхесләр турында сөйләрмен әле.

Рәшит: Рәхмәт сиңа, дустым.

**[2 секунд пауза]**
**Диалогны икенче тапкыр тыңлагыз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**

**Алтынчы сорау. Айсылу кая укырга керергә тели?**

Рәшит: Айсылу, мәктәпне тәмамлагач, кайда укыйсың килә?

Айсылу: Тугызынчы сыйныфны тәмамлагач, минем училищега укырга керәсем килә.

Рәшит: Ничек? Син унынчы сыйныфка бармыйсыңмы? Менә яңалык. Беренче тапкыр ишетәм. Ник шулай уйладың?

Айсылу: Сиңа чыннан да кызыктыр, Рәшит. Әйе, мин мәктәптән китәргә җыенам, чөнки минем шәфкать туташы буласым килә.

Рәшит: Казанда укырга җыенасыңмы?

Айсылу: Әйе, минем дустым Алия дә шул һөнәрне сайлады. Без бергә медицина училищесында укырга хыялланабыз. Ә син, Рәшит, унынчы сыйныфта укуыңны дәвам итәчәксеңме?

Рәшит: Әйе шул, мин китү турында уйламадым да. Киләчәктә минем төзүче буласым килә. 9 нчы сыйныфтан соң техникумда укырга мөмкин, ә аннары университетта югары белем алып була.

Айсылу: Шулай булгач, син дә техникумда үзеңә ошаган һөнәрне үзләштерә аласың.

Рәшит: Әти-әнием риза булмаслар дип уйлыйм.

Айсылу: Аңлашылды.

**[2 секунд пауза]**
**Прослушайте диалог второй раз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**

**Җиденче сорау. Рәшитнең әбисе кайда яши?**

Рәшит: Айсылу, сезнең туганнарыгыз күпме?

Айсылу: Күп түгел. Әниемнең бертуган сеңелесе бар. Ул Алабуга шәһәрендә яши. Ә әтинең абыйсы бар. Ул Мөслим районында яши.

Рәшит: Әбиең, бабаң да бардыр бит?

Айсылу: Әйе, алар Арча районында Казанбаш авылында яшиләр. Ә синең туганнарың кайсы шәһәрләрдә яки авылларда яшиләр, Рәшит?

Рәшит: Безнең туганнарыбыз күп, чөнки әниемнең ике бертуган апасы бар, алар Түбән Камада яшиләр. Әтиемнең дә ике апасы бар, алар Самарада яшиләр.

Айсылу: Әбиләрең бармы соң, Рәшит?

Рәшит: Бер әбием бар. Ул – әниемнең әнисе.

Айсылу: Ул сезнең белән яшиме?

Рәшит: Юк. Ул авылда яши.

Айсылу: Кайсы районда?

Рәшит: Биектау районында.

**[2 секунд пауза]**
**Прослушайте диалог второй раз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**

***Прослушайте разговор двух друзей. Определите, какие из приведенных утверждений 8 - 13 соответствуют содержанию текста, а какие – не соответствуют. Вы услышите аудиозапись дважды.***

**[пауза 20 секунд]**

Самат: Сәлам, Алсу!

Алсу: Сәлам, Самат! Әйт әле, син күптән театрда булдыңмы?

Самат: Күптән түгел без гаиләбез белән Камал театрында булдык.

Алсу: Шулаймыни? Анда нинди спектакль карадыгыз?

Самат: ”Бию пәрие” исемле пьеса карадык.

Алсу:  Кызык! Минем караганым юк әле. Сиңа бу спектакль ошадымы?

Самат: Әйе, бик ошады. Ул шундый заманча һәм юморга бай. Артистлар шундый матур бииләр. Бу спектакль күп артистларга иҗади сәләтләрен күрсәтергә мөмкинлек биргән.  Барлык тамашачылар сокланып утырды.

Алсу: Анда сиңа таныш булган артистлар уйнадымы? Кайсы артистның уены бигрәк тә ошады?

Самат: Анда күп яшь артистлар уйный. Алар арасында миңа иң ошаганы Эмиль Талипов булды. Аның уйнавы бик күп тамашачыларга ошады дип уйлыйм.

Алсу: Ә төп рольне кем башкарды?

Самат: Камал театрының танылган артисты Илдус Габдрахманов.

Алсу: Димәк, сез театрда рәхәтләнеп ял итеп утыргансыз.

Самат: Нәкъ шулай. Барысы да шәп булды: артистларның уены да, дәртле биюләре дә, моңлы җырлары да.

Алсу: Зал тулы идеме?

Самат: Тамашачылар зал тутырып килгән. Бер буш урын да юк иде.

Алсу: Минем дә бу спектакльне карыйсым килә. Кечкенә чакта минем биюче буласым килә иде, берничә ел бию түгәрәгенә дә йөрдем.

Самат: Алайса син бу спектакльдән бик канәгать калачаксың, чөнки аның нигезе биюгә корылган. Халык бу спектакльне бик җылы кабул итте. Минем хәтта икенче тапкыр бу спектакльне карыйсым килә.

Алсу: Менә ничек яхшы! Димәк, без синең белән бергә бара алабыз. Афишадан карыйк, бу айда аны тагын кайсы көнне күрсәтәләр икән. Булса, билетларны онлайн алып куярбыз. Алдан алмасак, аннары калмас. Минемчә, бу спектакльгә халык күп йөри.

Самат:  Мин риза. Комедияне карарга теләүчеләр күп булыр. Син хаклы, билетларны алдан алып куярбыз.

Алсу: Әйдә, бүген дәресләрдән соң билетларга заказ бирик.

Самат: Яхшы, сөйләштек.

Алсу: Зур рәхмәт сиңа, дустым.

**[2 секунд пауза]**

**Прослушайте диалог второй раз.**

[язма икенче тапкыр яңгырый]

**[2 секунд пауза]**

**Внесите ответы в бланк ответов.**

## ҖАВАПЛАР

| **Биремнең номеры** | **Дөрес җавап** |
|---|---|
| 1 | 3 |
| 2 | 3 |
| 3 | 2 |
| 4 | 1 |
| 5 | 3 |
| 6 | 2 |
| 7 | 2 |
| 8 | 2 |
| 9 | 1 |
| 10 | 2 |
| 11 | 1 |
| 12 | 2 |
| 13 | 1 |
| 14 | 3 |
| 15 | 2 |
| 16 | 1 |
| 17 | 2 |
| 18 | 3 |
| 19 | 1 |
| 20 | 3 |
| 21 | 2 |
| 22 | 3 |
| 23 | 1 |
| 24 | 2 |
| 25 | 3 |
| 26 | 2 |
| 27 | 1 |
| 28 | 3 |

## 3 нче вариант
## Раздел 1

***Прослушайте 7 коротких диалогов. В заданиях 1 - 7 укажите правильный вариант ответа. Вы услышите аудиозапись дважды.***

**1** **Рәшит Айсылуга нәрсә турында әйтә?**

1) көрәшче булуы
2) ярышта җиңүе
3) бәйгедә катнашуы

**2** **Кыз белән егет кайда очрашырга сөйләшкәннәр?**

1) табигатьтә
2) бакчада
3) тукталышта

**3** **Рәшит Айсылуны кая чакыра?**

1) өс киеме бүлегенә
2) аяк киеме кибетенә
3) сәүдә үзәгенә

**4** **Айсылуның дусты кем булырга тели?**

1) төзүче
2) очучы
3) тәрбияче

**5** **Айсылуның нишлисе бар?**

1) ризыклар илтәсе бар
2) сеңелесен карыйсы бар
3) дару кертәсе бар

**6** **Айсылу ял көнен кайда үткәргән?**

1) фестивальдә
2) очрашуда
3) өйдә

**7** **Рәшитнең абыйсы кем булып эшли?**

1) җырчы
2) биюче
3) җитәкче

***Прослушайте разговор двух друзей. Определите, какие из приведенных утверждений 8 - 13 соответствуют содержанию текста (1), а какие – не соответствуют (2). Вы услышите аудиозапись дважды.***

**8** Дуслар киләсе ял көннәрен үткәрү турында сөйләшәләр.

1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**9** Айсылу дустын яшь җырчылар концертына чакыра.

1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**10** Айсылу дустына танылган татар җырчысының тормышы турында сөйли.

1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**11** Бу җырчыны республиканың алтын тавышы дип атыйлар.

1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**12** Самат бу җырчының җырларын яхшы белә.

1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**13** Бу җырчының чыгышларын халык бик җылы кабул итә.

1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

## Раздел 2

***Прочитайте тексты в заданиях 14 – 16. После каждого текста определите правильный вариант ответа.***

| **14** | “Габдулла Тукай: яшьләр карашы” күргәзмәсенә рәхим итегез!<br>Ул 3 нче майга кадәр эшләячәк. Габдулла Тукай әдәби музеенда яшь рәссамнарның күргәзмәсе эшли башлады. “Яшьләр Тукай әсәрләре образларын ничек күзаллый – безгә шул кызык иде”, - дип ачып җибәрде күргәзмәне музей җитәкчесе Гүзәл Төхвәтова. Күргәзмәгә бик күп шәһәрләрдән төрле жанрларда башкарылган эшләр җибәрелгән. “Тукай модада! Бу безнең яшьләрнең эш юнәлеше”, - дип белдерде ТР Рәссамнар берлеге рәисе Альберт Шиһабиев.<br>Күргәзмә сәгать уннан кичке алтыга кадәр эшли. Рәхим итегез! | **Белдерүдә нәрсә турында әйтелә?**<br>1) Әдәби музейда ачылачак яшь рәссамнар күргәзмәсе турында.<br>2) Яңа күргәзмә эшли башлавы турында.<br>3) Күргәзмәгә куелган рәсемнәр турында. |
|---|---|---|

| | | |
|---|---|---|
| **15** | Үзәк китапханәдә җәй ахырында чәчәкләр күргәзмәсе уза!<br>Быел безнең күргәзмәбез “Чәчәкләр дөньясында“ дип атала. “Китапханә хезмәткәрләренә зур рәхмәтебезне җиткерәбез, чөнки күргәзмәне алар белән бергә оештырдык”, - дип әйтте оештыручыларның берсе - Нина Халикова. Күргәзмәгә килүче һәр кеше мондагы матурлыкка соклануын белдерә. Һәр чәчәк үзенә күрә нәфис!<br>Шәһәр халкын һәм кунакларны әлеге чарада көтеп калабыз. Күргәзмә 5 нче сентябрьгә кадәр дәвам итә. | **Бу хәбәр нәрсә турында?**<br>1) Чәчәкләр күргәзмәсенең җитәкчесе турында.<br>2) Чәчәкләр күргәзмәсендә катнашучылар турында.<br>3) Чәчәкләр күргәзмәсенә барлык теләүчеләрне чакыру турында. |
| **16** | Хәерле көн, Гөлназ! Хәлләрең яхшымы? Гаиләгездә барысы да исән-саулармы?<br>Минем хәлләрем шәп. Әти-әнием дә исән-саулар. Сине сагынып, хат язарга, яңалыклар турында сөйләргә булдым. Киләсе атнада мин фәнни конференциядә чыгыш ясарга әзерләнәм. Бу чараны университетның татар теле кафедрасы уздыра. Мин татар мәкальләре белән бәйле темага сөйләячәкмен. Күп китаплар укыдым, мисаллар җыйдым, фәнни эшемне шушы көннәрдә тәмамлармын. Мин беренче тапкыр шундый чарада катнашам, шуңа күрә дулкынланам. Ә синең тормышыңда нинди яңалыклар бар? Вакытың булу белән миңа хат яз, дустым.<br>Сәлам белән дустың Гүзәл. | **Электрон хатында Гүзәл дустына нәрсә турында язган?**<br>1) Татар теленнән үткәреләчәк фәнни конференция турында.<br>2) Университетта үткәрелгән фәнни чара турында.<br>3) Татар телендә чыгыш ясавы турында. |

***Прочитайте текст. В заданиях 17 - 20 укажите правильный вариант ответа.***

Яз җиткәч, аю баласы Әппәс йокысыннан уянган. Уянгач та, өненнән чыккан. Иртәрәк чыккан аю баласы өненнән. Шул чакта урман буйлап аучы узып бара икән. Аучы аю баласы Әппәсне күреп алган. Мылтыгын төзәп:

— Тукта, аю баласы, мин сине хәзер атам! — дип кычкырган аучы.

Аю баласы Әппәс куаклар арасына кереп качкан. Аучы аны куа башлаган. Әппәс качкан җиреннән чыккан да и йөгерә, и йөгерә икән. Аучы һаман куа икән аю баласын. Үзе йөгерә, үзе шатыр-шотыр мылтыктан ата, ди. Барыбер аучы Әппәскә тидерә алмаган. Аучы артта калган. Аю баласы, куркуыннан туктый алмыйча, әллә кая чаклы йөгергән. Шулай йөгерә торгач, сукмакка аркылы ауган агачка абынып егылган. Егылганда, аягын авыртырган.

Авырткан аягына өрә-өрә:
— У-у, аягым каерылды. Өемә кайта алмам инде! — дип кайгыра икән Әппәс.
Аю баласының аягы нык имгәнгән булган шул. Ул кишер дә, шалкан да утырта алмаган. Куян, керпе, тиен аю баласы Әппәсне бергәләп караганнар, ашатканнар. Гөмбә, чикләвек, шомырт, җиләк, карлыган, тагын әллә ниләр белән сыйлаганнар.
— Йокла, Әппәс, тиз терел! — дип, үзләренчә җырлар җырлаганнар җәнлекләр.
Аю баласы Әппәс терелгән. Ул терелгәнче, җәй дә үтеп киткән, кыш та килеп җиткән. Кыш җитүгә, аюлар йокларга тала. Аю баласы Әппәс тагын өненә кереп яткан. Җәнлекләр аңа тагын бишек җыры җырлаганнар. (*Батулла)*.

**17** Аю баласы, аучыдан куркып, кая качкан?
1) Ауган агач артына.
2) Өненә.
3) Куаклар арасына.

**18** Куркуыннан туктый алмыйча йөгереп, аю баласы нишләгән?
1) Егылган.
2) Чокырга төшкән.
3) Артта калган.

**19** Аю баласына дуслары ничек ярдәм иткәннәр?
1) Алар аңа бал ашатканнар.
2) Алар аны ашатканнар.
3) Алар аны кишер белән сыйлаганнар.

**20** Кыш җиткәч, аюлар нишли?
1) Җәй җиткәнне көтәләр.
2) Урманда азык эзлиләр.
3) Өннәрендә йоклыйлар.

## Раздел 3

***Прочитайте текст. В заданиях 21 – 28 определите правильный вариант ответа.***

Исмәгыйльнең тамагы (21) ... . Температурасы күтәрелде, хәтта колаклары да уттай яна. Исмәгыйльнең үзеннән бигрәк, әнисе борчылды. Чөнки алар атна башыннан Чаллыга кунакка (22) ... тиешләр. Инде билетларны да алып куйганнар иде. Ә хәзер менә Исмәгыйльне (23) ... үк салып куярга мөмкиннәр. Исмәгыйльнең анда ятып чыкканы бар. Укол (24) ..., тәмам җәфалап бетерделәр. Әнисе бу юлы да табибә (25) ... чакырды. Озаклап тыңлап карагач, табибә апа: «Бал белән (26) ..., ике көннән терелер», — диде.
Әнисе, җылы сөткә бал бутап, Исмәгыйльгә эчертә башлады. Гаҗәп! Малайның хәле кичкә үк (27) .... Әнә нинди тылсымлы көчкә ия икән ул бал! Хәзер

Исмәгыйль һәр чәчәк таҗына кунган (28) ... чын күңелдән сокланып, яратып карый. Аны кулына алып сөясе килә Исмәгыйльнең. (*Альберт Хәсәнов*).

**21** 1) шешкәч 2) шешә 3) шеште

**22** 1) бардылар 2) барырга 3) бару

**23** 1) кунакханәгә 2) хастаханәгә 3) даруханәгә

**24** 1) эчереп 2) биреп 3) кадап

**25** 1) апаны 2) ападан 3) апага

**26** 1) дәвалана 2) дәвалагыз 3) дәвалыйлар

**27** 1) начарланды 2) бетте 3) яхшырды

**28** 1) бал кортына 2) бал кортларын 3) бал кортының

## Раздел 4

***В заданиях 29-32 необходимо написать реплики в соответствии с заданной речевой ситуацией.***

**Сөйләм ситуациясенә туры килгән репликаларны языгыз.**

**29** Скажите друзьям, что вы любите читать рассказы об истории Россиии.

**30** Спросите у друга (подруги), какой спектакль он (она) посмотрел(а) в театре юного зрителя.

**31** Предложите друзьям посетить новую выставку в Национальном музее РТ.

**32** Спросите у брата, пойдет ли он на концерт популярного татарского певца Ришата Тухватуллина.

**33** **Вы получили письмо от друга (подруги). Напишите ему (ей) письмо объемом не менее 60 слов, ответив на его (её) вопросы.**
**Для ответа на это задание используйте специальный бланк ответов.**

*... Минем дусларым акыллы, максатчан, уңышлы. Мин алар белән аралашырга яратам. Алар белән без төрле яңалыклар, кызыклы китаплар, яраткан шөгыльләребез турында сөйләшәбез.*

*... Ә синең дусларың нинди?... Сез нәрсәләр турында сөйләшәбез? ... Алар белән кайларга барасыз?*

**Тыңлап аңлау биремнәре өчен текстлар**

**Прослушайте 7 коротких диалогов. В заданиях 1 - 7 укажите правильный вариант ответа. Вы услышите аудиозапись дважды.**

**Беренче сорау. Рәшит Айсылуга нәрсә турында әйтә?**

Айсылу: Сәлам, Рәшит!

Рәшит: Сәлам, Айсылу! Дәресләрең ничәдә бетә?

Айсылу: Бүген безнең биш дәрес була. Димәк, бер тулганда бетә. Ә син кайчан бушыйсың?

Рәшит: Безнең дә биш дәрес кенә, алтынчы дәрес булмый диделәр, чөнки химия укытучысы авырый. Әйдә, бүген өйгә җәяү кайтабыз. Мин сиңа барлык яңалыклар турында сөйләрмен.

Айсылу: Яхшы, мин риза. Дәресләр бетүгә, мин сине мәктәп ишегалдында көтәрмен. Яңалыкларың шундый күпмени? Юл буе алар турында сөйләрсеңме? Син шундый шат, ниндидер бәйгедә яки ярышта җиңдеңме?

Рәшит: Анысы да бар инде. Син бит беләсең, мин – көрәшче. Күптән түгел республика беренчелеге үтте, һәм мин анда беренче урынны алдым.

Айсылу: Күрәм инде, шатлыгың эченә сыймый. Шатлыгыңны уртаклашам, дустым. Башка яңалыклар турында өйгә кайтышлый сөйләрсең инде. Дәрес башланырга өч минут калды. Мин киттем. Очрашуга кадәр!

Рәшит: Яхшы, сөйләштек. Мин сине көтәрмен.

Айсылу: Барлык яңалыкларың турында беләсем килә.

Рәшит: Сөйләрмен!

**[2 секунд пауза]**

**Прослушайте диалог второй раз.**

[язма икенче тапкыр яңгырый]

**[2 секунд пауза]**

**Икенче сорау. Кыз белән егет кайда очрашырга сөйләшкәннәр?**

Рәшит: Айсылу, сәлам, әйдә, иртәгә безнең бакчага барабыз. Быел алма бик күп, әти-әнигә булышырга кирәк. Дәресләрдән соң вакытың булырмы?

Айсылу: Иртәгә түгәрәкләргә барасым юк. Димәк, синең белән бара алам. Алма ашарга бик яратам. Сезгә дә булышырмын.

Рәшит: Алайса шулай сөйләшәбез. Мәктәптән кайткач, син дәресләреңне әзерлә, чөнки бакчада озак булырбыз, аннары вакытың калмас.

Айсылу: Ярар, аңладым. Әзер булгач, син миңа шалтыратырсыңмы?

Рәшит: Әйе, әлбәтттә. Әти эштән кайтуга, без бергәләп машинада бакчага китәрбез.

Айсылу: Минем сезнең бакчада булганым юк бит әле. Бик күрәсем килә.

Рәшит: Әйе шул. Безнең бакчабыз Идел буенда урнашкан. Көзен табигать бигрәк тә матур. Рәхәтләнеп ял итеп кайтырсың. Озакламый яңгырлар башлана. Матурлыкка сокланып калырга кирәк.

Айсылу: Бик дөрес. Дәресләр күп, саф һавада булырга вакыт та калмый. Ә инде табигатькә чыгу турында хыялланасы гына кала.

Рәшит: Менә шуңа күрә безнең белән бакчага барырга тәкъдим иттем дә инде. Без синең белән тукталышта очрашырбыз. Шулай уңайлырак булыр.

Айсылу: Чакыруың өчен рәхмәт! Син – чын дус!

**[2 секунд пауза]**
**Прослушайте диалог второй раз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый] **[2 секунд пауза]**

**Өченче сорау. Рәшит Айсылуны кая чакыра?**

Рәшит: Айсылу, минем сиңа бер тәкъдимем бар.

Айсылу: Нинди тәкъдим? Мине кая чакырырга телисең? Концерткамы? Театргамы?

Рәшит: Юк, миңа синең ярдәмең кирәк. Дөресрәге, синең киңәшең кирәк булачак.

Айсылу: Нинди эштә?

Рәшит: Эштә түгел, ә әйбер сайлауда.

Айсылу: Нәрсә алырга җыенасың? Яңа өс киемеме, әллә аяк киемеме?

Рәшит: Миңа яңа кроссовка кирәк, шуңа бүген дәресләрдән соң кибеткә барырга җыенам. Айсылу, дәресләрдән соң синең вакытың булырмы?

Айсылу: Башта миңа инглиз теленнән өстәмә дәрескә барырга кирәк, аннары бушыйм. Ничәдә һәм кайда очрашабыз?

Рәшит: Сәгать биштә сезнең өегез янында очрашыйк. Шулай уңайлымы сиңа?

Айсылу: Бик уңайлы.

Рәшит: Рәхмәт сиңа, дустым.

**[2 секунд пауза]**
**Диалогны икенче тапкыр тыңлагыз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**

**Дүртенче сорау. Айсылуның дусты кем булырга тели?**

Рәшит: Айсылу, сәлам, хәлләр ничек?

Айсылу: Сәлам, бик яхшы, рәхмәт!

Рәшит: Синең иң якын дустың Фәридәме?

Айсылу: Әйе, иң якын дустым – Фәридә. Ул – минем сыйныфташым. Без - беренче сыйныфтан бирле якын дуслар.Ә синең иң якын дустың Булатмы?

Рәшит: Юк, Булат белән без – сыйныфташлар, ә якын дустым – Тимур. Без бергә бокс секциясенә йөрибез. Дуслашуыбызга берничә ел инде. Ул – бик яхшы егет. Һәрвакыт миңа ярдәм итәргә әзер.

Айсылу: Ә аның кем буласы килә, син беләсеңме?

Рәшит: Аның иң зур хыялы – очучы булу. Кечкенәдән шуның турында хыяллана. Ә синең дустыңның кем буласы килә? Син дә минем кебек беләсеңме?

Айсылу: Әйе, әлбәттә, беләм. Без бу турыда да еш сөйләшәбез, чөнки һөнәр сайлау – бик җаваплы эш. Әнием дә һәрвакыт шуны әйтеп тора.

Рәшит: Шуннан? Дустыңның кем буласы килгәнен әйтмәдең бит әле.

Айсылу: Ярар, әйтермен. Хәзерге вакытта аңа берничә һөнәр ошый: табибә, тәрбияче, төзүче һөнәрләре. Минемчә, ул соңгы һөнәрне сайлар. Аның заманча биналар төзисе килә.

Рәшит: Кызык! Уңышлар телик!

**[2 секунд пауза]**

**Прослушайте диалог второй раз.**

[язма икенче тапкыр яңгырый]

**[2 секунд пауза]**

**Бишенче сорау. Айсылуның нишлисе бар?**

Рәшит: Айсылу, буш вакытың булса, миңа ярдәм итәрсең әле.

Айсылу: Нәрсә булды, Рәшит?

Рәшит: Әнием авырый, хастаханәдә ята. Минем аңа ризыклар илтәсем бар. Ә кечкенә сеңелемне кем белән калдырырга белмим.

Айсылу: Һичшиксез, мин сиңа ярдәм итәргә әзер, дустым. Сәгать ничәгә сезгә килергә кирәк?

Рәшит: Миңа сәгать дүрттә өйдән чыгарга кирәк. Шуңа күрә дүртенче яртыга килсәң, шәп булыр.

Айсылу: Сеңелеңә ничә яшь? Аның исеме ничек? Ул нишләргә ярата?

Рәшит: Аның исеме – Мәликә. Аңа биш яшь. Ул курчаклары белән уйнарга ярата. Синең килүеңә ул бик шатланыр дип уйлыйм.

Айсылу: Әйе, без аның белән рәхәтләнеп уйнарбыз. Син борчылма. Минем дәресләрдән соң дәү әниемә дару кертеп чыгасым бар. Аңардан кайту белән, сезгә килермен.

Рәшит: Зур рәхмәт сиңа, дустым.

**[2 секунд пауза]**

**Диалогны икенче тапкыр тыңлагыз.**

[язма икенче тапкыр яңгырый]

**[2 секунд пауза]**

**Алтынчы сорау. Айсылу ял көнен кайда үткәргән?**

Рәшит: Айсылу, сәлам, якшәмбе көнне кайда булдың?

Айсылу: Әйтмим әле. Әйдә, үзең әйтеп кара. Синеңчә, мин ял көнемдә кайда булдым икән?

Рәшит: Әйтүе авыр. Син бит бик актив кеше. Бию белән дә шөгыльләнәсең, ипподромга да йөрисең, химиядән өстәмә дәресләр аласың. Шулай булгач, төгәл генә әйтә алмыйм. Әйт инде, сер түгелдер бит!

Айсылу: Ярар, әйтсәм әйтим инде. Мин бик кызыклы очрашуда булдым. Университетның Химия институтында ачык ишекләр көне булды. Сыйныфташым белән шунда бардык.

Рәшит: Кызык булдымы?

Айсылу: Әйе, миңа бик ошады. Безнең алдыбызда танылган профессорлар да, студентлар да чыгыш ясады. Студентлар тормышы шундый кызык икән. Алар төрле фестивальләр, бәйгеләр оештыралар. Минем дә шунда укыйсым килә. Ә син, Рәшит, ял көнендә нишләдең?

Рәшит: Кызганыч, мин беркая да бармадым, өйдә булдым. Рус әдәбиятыннан проект эше эшлисем бар иде. Көн буе шуның белән шөгыльләндем. Вакыт үткәнен сизми дә калдым.

Айсылу: Син дә көнеңне бик файдалы үткәргәнсең, кирәкле эш эшләгәнсең.

Рәшит: Әйе, шулай, һәрнәрсәне вакытында эшләргә кирәк.

Айсылу: Дөрес.

**[2 секунд пауза]**
**Прослушайте диалог второй раз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**

**Җиденче сорау. Рәшитнең абыйсы кем булып эшли?**

Рәшит: Айсылу, апаң университетта укыймы?

Айсылу: Юк, ул укуын тәмамлады инде. Хәзер шәһәр мэриясендә эшли.

Рәшит: Шулаймыни? Эше үзенә ошыймы соң?

Айсылу: Әйе, бик ошый. Ул да әтием кебек – программист. Хәзер андый белгечләр бик кирәк, чөнки һәр җирдә цифрлаштыру бара. Ә синең абыең кем булып эшли? Ул да югары уку йортын тәмамлады бит.

Рәшит: Абыем ике ел элек сәнгать институтын тәмамлады. Ул хәзер һөнәре буенча эшли.

Айсылу: Кайда? Биюче булыпмы?

Рәшит: Филармониядә эшли, ләкин ул биюче түгел. Ул - фольклор ансамбле җырчысы.

Айсылу: Белүемчә, бу бик танылган ансамбль. Ә син аның концертларына йөрисеңне?

Рәшит: Вакыт булганда, гаиләбез белән барабыз.

Айсылу: Абыең белән горурланасыңмы?

Рәшит: Әлбәттә.

**[2 секунд пауза]**
**Прослушайте диалог второй раз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]

**[2 секунд пауза]**

***Прослушайте разговор двух друзей. Определите, какие из приведенных утверждений 8 - 13 соответствуют содержанию текста, а какие – не соответствуют. Вы услышите аудиозапись дважды.***

**[пауза 20 секунд]**

Самат: Сәлам, Алсу!

Алсу: Сәлам, Самат! Әйт әле, синең татар концертына барасың киләме?

Самат: Ә кемнең концерты була?

Алсу: Киләсе атнада булачак танылган җырчы Филүс Каһировның концерты турында белдерү укыдым. Әйдә, барыйк.

Самат: Кайда булачак?

Алсу: "Пирамида" күңел ачу үзәгендә дип язылган.

Самат: Минем аның концертында булганым юк әле. Сиңа аның иҗаты ошыймы?

Алсу: Аны Татарстанның алтын тавышы дип атыйлар. Сиңа аның җырлавы ошар дип уйлыйм.

Самат: Сиңа ошагач, миңа да ошар инде, дустым. Синең белән концертка барырга мин каршы түгел. Билетларны онлайн алабызмы?

Алсу: Хәзер мин сайттан карыйм. Андый мөмкинлек бардыр. Хәзер бөтен тамашаларга билетлар шулай сатыла.

Самат: Бу җырчы турында миңа бераз сөйлә әле. Концертка барганчы, аның турында беләсем килә.

Алсу: Ул – Татарстанның һәм Башкортстанның атказанган артисты, берничә премия лауреаты. Филүс Каһиров халык көйләрен дә, опера партияләрен дә бик оста башкара.

Самат: Ә сиңа кайсы җырлары күбрәк ошый?

Алсу: "Сине эзләп" җырын тыңларга яратам. Гомумән, барлык җырларын да рәхәтләнеп тыңлыйм.

Самат: Ә тамашачылар аның чыгышларын ничек кабул итә?

Алсу: Аның концертларына халык бик яратып йөри. Тамашачылар эстрадада җырлавын да, симфоник оркестр белән классик чыгышларын да бик җылы каршы алалар.

Самат: Алайса мин дә канәгать калырмын дип уйлыйм.

Алсу: Менә күрәсеңме, сине ничек кызыксындыра алдым. Әле шуны да әйтергә онытканмын. Филүс Каһиров – "Татар җыры" фестиваленең Гран-при иясе. Бер күргәч, аның концертларына һәрвакыт барасың килер.

Самат: Ышанам. Бүләкләре дә күп икән.

Алсу: Әйе шул, зур дәрәҗәләр яулаган артист.

Самат: Сөйләштек. Якшәмбе көнне кичке сәгать җидедә "Пирамида"да очрашабыз!

**[2 секунд пауза]**
**Прослушайте диалог второй раз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**
**Внесите ответы в бланк ответов.**

## ҖАВАПЛАР

| Биремнең номеры | Дөрес җавап |
|---|---|
| 1 | 2 |
| 2 | 3 |
| 3 | 2 |
| 4 | 1 |
| 5 | 3 |
| 6 | 2 |
| 7 | 1 |
| 8 | 1 |
| 9 | 2 |
| 10 | 2 |
| 11 | 1 |
| 12 | 2 |
| 13 | 1 |
| 14 | 2 |
| 15 | 3 |
| 16 | 1 |
| 17 | 3 |
| 18 | 1 |
| 19 | 2 |
| 20 | 3 |
| 21 | 3 |
| 22 | 2 |
| 23 | 2 |
| 24 | 3 |
| 25 | 1 |
| 26 | 2 |
| 27 | 3 |
| 28 | 1 |

## 4 нче вариант
## Раздел 1

***Прослушайте 7 коротких диалогов. В заданиях 1 - 7 укажите правильный вариант ответа. Вы услышите аудиозапись дважды.***

**1** **Рәшит Айсылуга нинди киңәш бирә?**

1) китапханәдән эзләргә
2) сыйныф бүлмәсеннән карарга
3) кабул итү бүлмәсеннән сорарга

**2** **Дуслар нәрсә турында хыялланалар?**
1) имтиханнарны яхшы тапшыру
2) саф һавада йөрү
3) табигатькә чыгу

**3** **Рәшиткә китапханәнең яңа бинасы ни өчен ошый?**
1) махсус урыннар булганга
2) мөмкинлекләр күп булганга
3) теркәлү чикле булганга

**4** **Айсылу ни өчен авырган?**
1) туңдырма ашаган
2) урамда баш киемсез йөргән
3) салкын су эчкән

**5** **Айсылу туган көнен кайда үткәрергә тели?**
1) кафеда
2) табигатьтә
3) өйдә

**6** **Айсылуга кайсы яшелчә күбрәк ошый?**
1) кыяр һәм томат
2) кәбестә һәм кишер
3) суган һәм чөгендер

**7** **Айсылуның әбисе кем булган?**
1) тәрбияче
2) китапханәче
3) хисапчы

***Прослушайте разговор двух друзей. Определите, какие из приведенных утверждений 8 - 13 соответствуют содержанию текста (1), а какие – не соответствуют (2). Вы услышите аудиозапись дважды.***

**8** Дуслар халыкара телләр турында фикер алышалар.
1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**9** Алсу тарихтан проект эше яклаган.
1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**10** Укучылар күпмилләтле республикада яшиләр.
1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**11** Самат республика халыклары турында белми.
1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**12** Семык – мордва халкының милли бәйрәме.
1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**13** Ысыах сүзе байлыкны аңлата.
1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

## Раздел 2

***Прочитайте тексты в заданиях 14 – 16. После каждого текста определите правильный вариант ответа.***

| | | |
|---|---|---|
| **14** | Чәй бәйрәменә рәхим итегез!<br>15 нче декабрьдә шәһәр үзәгендә урнашкан “Чәй йортында” чәй көнен билгеләп үтәргә чакырабыз. Чәй – иң борынгы һәм файдалы эчемлекләрнең берсе. Бәйрәмдә сез татар халкының чәй традицияләре белән танышырсыз. Чәй табыны артында аның үзенчәлекләре һәм сортлары турында кызыклы чыгышлар тыңларсыз. Бәйрәм кунакларын хуш исле чәй һәм татар милли ризыклары белән сыйларбыз.<br>Бәйрәм көндезге сәгать бердә башлана. Казан халкы һәм шәһәр кунаклары, рәхим итегез!<br>Белешмәләр өчен телефон: 222-22-22 | **Белдерүдә нәрсә турында әйтелә?**<br>1) Шәһәр кунакларын чәй эчәргә чакыру турында.<br>2) Чәй көненә багышланган лекциягә чакыру турында.<br>3) Шәһәрдә чәй көнен билгеләп үтү турында. |
| **15** | Бөек Болгарга сәяхәткә чакырабыз!<br>Казаннан 200 км көньяккарак китүгә, сез XIII —XV нче гасырлар мөселман архитектурасы һәйкәлен күрә аласыз. Һиндстанның Таҗ-Махалын хәтерләткән Ак мәчет, борынгы бина | **Бу хәбәр нәрсә турында?**<br>1) Болгарда казу эшләре алып бару турында. |

хәрабәләре бөтен дөнья халыкларының игътибарын җәлеп итеп тора. Археологлар казу эшләре алып барсалар, сәяхәтчеләр Идел Болгары һәм Алтын Урданың кызыклы тарихы белән таныша алалар. Борынгы Болгарны барып күрергә киңәш итәбез. Бөек Екатерина һәм Петр Беренче булып киткән шәһәрдә нинди урыннар барлыгы турында сөйләрбез!

2) Борынгы Болгарга сәяхәтчеләрне чакыру турында.
3) Болгар һәм Алтын Урда тарихына игътибарны җәлеп итү турында.

**16**

Хәерле көн, Фирүзә! Укуларың ничек бара? Барысы да яхшымы?
Без барыбыз да исән-саулар. Сиңа яңалыклар турында хәбәр итәсем килә. Бәйрәм көннәрендә без сыйныфыбыз белән Мәскәүгә экскурсиягә бардык. Өч көн генә булсак та, күп әйберләрне күрә алдык. Әлбәттә, Мәскәү Кремле, Кызыл мәйдан, Александр бакчасы, Мәңгелек ут, Арбат урамы, Зарядье паркы, Мәскәү-Сити. Болар барысы да - халык яратып карый торган урыннар. Без дә аларга сокландык. Автобусларга утырып, башкалабызның тарихи урыннарын карап бардык. Шундый кызыклы сәяхәт булды! Синдә нинди яңалыклар бар? Хат яз, көтәм.
Сәлам белән дустың Айзилә.

**Электрон хатында Айзилә дустына нәрсә турында язган?**
1) Башкалада халык карый торган урыннар турында.
2) Башкаланың үзәгендә булу турында.
3) Илебезнең башкаласына сәфәр кылу турында.

***Прочитайте текст. В заданиях 17 - 20 укажите правильный вариант ответа.***

Чишмә

Аны ачкан кеше дөньяда юк инде. Ә ул менә тау астында инде ничә гасыр ага. Иртән аның суларында кошлар су коена, күбәләкләр, бал кортлары сусауларын баса. Чишмәне барысы да ярата. Тик кешеләр аңа карата мәрхәмәтсез була башладылар. Чишмә ярында учак ягып ял иткәч, алар чүпләрне шунда ташлап калдыралар. Хәтта изге саналган су юлын да, көтүдән таптатып, баткаклыкка әйләндерделәр. Болай дәвам итсә, сайрар кошлар да урманга китәр. Юк, моңа юл куярга ярамый. Кешеләрнең үзләре белән сөйләшергә кирәк. Шулай дип фикер йөртә Чишмә. Беренче булып Чишмә буена карт бабай төште.
— Йә Аллам, нишләттеләр сине? — диде ул, Чишмәне күргәч.
— Көчемдә вакытта мин сине чистартып тордым. Их, яшьрәк чагым булса... Гаепле мин синең алда. Балаларымны игелекле итеп тәрбияли алмадым... Шулай да мин улларым белән сөйләшим әле. Карт торып, өенә юл тотты. Кичен улы эштән кайткач, Чишмә турында сүз кузгатты. Тик ул елмаеп кына куйды.

— Әти, Чишмә кайгысымы соң?.. Үзең беләсең: көндез вакыт эштә уза. Ә иртәкичен малларны карыйсы бар. Шәһәрдә яшәүче уллары белән сөйләшү дә нәтиҗә бирмәде. Берсе ялын дача төзеп, ә икенчесе, акча эшләп уздырырга уйлый икән. Аптырагач, бабай оныгы белән сөйләште. Бәхеткә, Инсаф аны аңлады. Күрәсең, игелеккә өндәп үстерү файдасыз калмагандыр. Икенче көнне Инсаф, көрәк тотып, чишмә буена төште. Чүпләрне җыеп, җиргә күмде. Чишмә юлын чистартты. Чишмә җиңел сулап куйды.

— Рәхмәт сиңа, Инсаф, — диде ул.

— Инде суымны авыз ит.

Инсаф учларына су алды. Чишмә суы бик тәмле, тирә-якта кошлар сайрый, дөнья ямьле иде. (*Фирдәвес Зариф*)

**17** Кешеләр Чишмәгә карата нинди булганнар?

1) Мәрхәмәтле.
2) Миһербансыз.
3) Битараф.

**18** Карт бабай нәрсәгә борчылган?

1) Чишмәне чистартып торганга.
2) Кошлар урманнан киткәнгә.
3) Балалары тәрбияле булмаганга.

**19** Бабай кемнәрдән ярдәм сораган?

1) Күршеләреннән.
2) Оныкларыннан
3) Балаларыннан.

**20** Бабайның оныгы нинди булып үскән?

1) Игелекле.
2) Ялкау.
3) Ягымлы

## Раздел 3

***Прочитайте текст. В заданиях 21 – 28 определите правильный вариант ответа.***

Ашыгыч ярдәм

Айдар кошларны ярата. Кыш көннәрендә бакчадагы (21) ... җим салырга онытмый. Ә җәй көннәрендә (22) ... тавык, каз, үрдәкләрне карарга булыша. Бүген ишегалдында тагын ике ят кош күрде ул. «Әтием күркәләр алып кайтам дигән иде, шушылардыр инде», — дип (23) ... малай. Аның моңа кадәр бер дә күркә күргәне юк иде. «Тик берсенең муены чабырган икән. (24) ... ярдәм кирәк», — дип, өйгә кереп китте. Өйдән көнбагыш мае, марля алып чыкты. «Хәзер (25) ... . Май белән сөртәбез дә марля белән бәйләп куябыз», — дип сөйләнде Айдар. Әмма күркәләр аңа тоттырырга уйламадылар. Айдарның (26)

... муеннарын сузып карап тордылар да, малай якынаюга, эре-эре атлап китеп бардылар. Ә теге чабырган кызыл муенлысы, «голдыр-голдыр» дип ачуланып, Айдарның (27) ... тешләп алды. Айдар кулына көнбагыш (28) ... сөртте, марля урады. Күркә көлә иде. (*Заһирә Гомәрова*)

**21** 1) җиргә 2) җимлеккә 3) җилгә

**22** 1) әнисен 2) әнисенең 3) әнисенә

**23** 1) сөйләде 2) уйлады 3) карады

**24** 1) ашыгыч 2) тиз 3) әкрен

**25** 1) дәвалана 2) дәвалый 3) дәвалыйбыз

**26** 1) килгән 2) килүен 3) килгәнче

**27** 1) кулын 2) кулына 3) кулында

**28** 1) майлар 2) май 3) мае

## Раздел 4

***В заданиях 29-32 необходимо написать репли***
***ки в соответствии с заданной речевой ситуацией.***

**Сөйләм ситуациясенә туры килгән репликаларны языгыз.**

**29** Сообщите другу (подруге), что собираетесь поступать в театральное училище после окончания девятого класса.

**30** Спросите у друга (подруги), какую литературу он (она) любит читать.

**31** Предложите друзьям сходить вместе на фестиваль татарской песни.

**32** Спросите у друзей, с какими людьми им интересно общаться и почему.

**33** **Вы получили письмо от друга (подруги). Напишите ему (ей) письмо объемом не менее 60 слов, ответив на его (её) вопросы.**
**Для ответа на это задание используйте специальный бланк ответов.**

*... Мин ял көннәрендә туганнарыбызга кунакка барырга, алар белән аралашырга яратам. Без бергәләп чәй эчәбез, тәмле ризыклар ашыйбыз, яңалыклар турында сөйләшәбез.*

*... Ә син ял көннәреңне кемнәр белән үткәрергә яратасың?... Сез бергәләп нишлисез? ... Алар белән нәрсәләр турында фикер алышасыз?*

**Тыңлап аңлау биремнәре өчен текстлар**

**Прослушайте 7 коротких диалогов. В заданиях 1 - 7 укажите правильный вариант ответа. Вы услышите аудиозапись дважды.**

**Беренче сорау. Рәшит Айсылуга нинди киңәш бирә?**

Айсылу: Сәлам, Рәшит!

Рәшит: Сәлам, Айсылу! Хәлләрең ничек? Бик моңсу күренәсең.

Айсылу: Әйе шул. Кичә мәктәптә тарих дәреслеген югалттым. Кайда калдырганмын, исемә төшерә алмыйм. Тарих кабинетына да кереп карадым, коридорда тәрәзә төпләрен дә карап чыктым. Беркайда да юк.

Рәшит: Борчылма, дустым, табарбыз. Сыйныф җитәкчесеннән сорадыңмы? Бәлки ул күргәндер.

Айсылу: Сорадым. Әйтүче булмады диде.

Рәшит: Алайса болай эшлибез. Син кабул итү бүлмәсенә кереп, андагы хезмәткәргә әйт. Югалган әйберләрне аңа алып килә́ләр дип беләм. Кемдер тапкан булса, шунда керткәндер.

Айсылу: Әйе шул. Үзем бу турыда уйламадым да. Рәхмәт сиңа, дустым, киңәшең өчен. Дәрес бетүгә керермен.

Рәшит: Табылсын гына инде.

Айсылу: Бик рәхмәтле булыр идем. Ел ахырында китапханәгә тапшырырга кирәк бит.

**[2 секунд пауза]**
**Прослушайте диалог второй раз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**

**Икенче сорау. Дуслар нәрсә турында хыяллланалар?**

Рәшит: Айсылу, имтиханнар тәмамлангач, нишләргә уйлыйсың?

Айсылу: Ул турыда уйлаганым юк әле, көне-төне әзерләнәм. Яхшы укысам да, бик дулкынланам.

Рәшит: Борчылма, барысы да яхшы булыр. Син түгел, мин дә борчылмыйм. Ә син - сыйныфта иң яхшы укучыларның берсе. Барлык имтиханнарны бишлегә бирәчәксең.

Айсылу: Рәхмәт яхшы сүзләрең өчен. Ә син нинди планнар корасың? Имтиханнар бетүгә, кая барырга уйлыйсың?

Рәшит: Сыйныфыбыз белән табигатькә чыгарга хыялланам. Рәхәтләнеп ял итәр идек. Елга буенда кызынырга, су коенырга, волейбол уйнарга мөмкин. Учак ягып, балык ашы пешереп тә, шашлык кыздырып та була.

Айсылу: Әйе шул. Синең фикерең миңа ошый. Мин дә елга буенда яки урманда ял итәргә телим. Бергә-бергә бик күңелле булыр иде.

Рәшит: Имтиханнар беткәндә, мин бу фикерне башкаларга да әйтермен. Алар да синең кебек килешерләрдер. Һәркемнең дә ял итәсе килә бит. Минемчә, саф һавада булу – иң яхшы ял.

Айсылу: Бик дөрес. Имтиханнардан соң сәламәтлек турында кайгыртырга кирәк.

Рәшит: Әйе, шуңа күрә бу тәкъдим турында сиңа әйтергә булдым.

Айсылу: Мин сине хуплыйм.

**[2 секунд пауза]**
**Прослушайте диалог второй раз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый] **[2 секунд пауза]**

**Өченче сорау. Рәшиткә китапханәнең яңа бинасы ни өчен ошый?**

Рәшит: Айсылу, сәлам, әйдә, иртәгә Милли китапханәгә барабыз.

Айсылу: Анда нәрсә була? Очрашумы? Башка чарамы?

Рәшит: Берни дә булмый. Минем сиңа Милли китапханәнең яңартылган бинасын күрсәтәсем килә. Ул шундый заманча. Үткән атнада мин әнием белән анда булдым. Яңа уку заллары искиткеч! Алар шундый уңайлы. Аннан китәсе дә килми. Китап дөньясына чумасың.

Айсылу: Бик кызык! Минем бу турыда укыганым юк. Мин Интернеттан карармын әле.

Рәшит: Иң кызыгы шул: монда китап укыр өчен генә түгел, ә күргәзмәләр һәм спектакльләр карарга, дуслар белән аралашырга, компьютерда эшләргә, тәмле каһвә эчәргә, хәтта электрон пианинода уйнарга да киләләр.

Айсылу: Син шундый кызык мәгълүмат белән таныштырдың. Минем дә барасым һәм күрәсем килә.

Рәшит: Димәк, иртәгә кичен без синең белән әлеге могҗизаны күрергә барабыз. Андагы үзгәрешләргә син дә сокланырсың.

Айсылу: Түземсезлек белән көтәм.

**[2 секунд пауза]**
**Диалогны икенче тапкыр тыңлагыз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**

**Дүртенче сорау. Айсылу ни өчен авырган?**

Рәшит: Алло, Айсылу, сәлам, хәлләр ничек?

Айсылу: Сәлам, начар.

Рәшит: Нәрсә булды? Авырдыңмы әллә? Бүген мәктәпкә дә килмәдең.

Айсылу: Шулай шул, авырып киттем, тамагым авырта.

Рәшит: Табиб чакырттыгызмы? Температураң бармы?

Айсылу: Температура бар, ләкин бик югары түгел. Әйе, әнием табиб чакыртты. Ул мине тыңлады, тамагым бик шешкән диде, шуңа күрә кирәкле даруларны язып бирде.

Рәшит: Сиңа ярдәм кирәкме? Даруханәгә барырга кирәк түгелме?

Айсылу: Рәхмәт, әнием эштән кайтышлый алачак. Хәзер миңа тамакны чайкап торырга кирәк. Моның өчен өйдә дару бар. Лимон белән дә, мәтрүшкә белән дә чәй эчәм.

Рәшит: Нишләп авырдың, дустым? Урамда озак йөрдеңме?

Айсылу: Юк, озак йөрмәдем, салкын су да эчмәдем. Кичә мәктәптән кайтканда, Фәридә белән туңдырма алып ашадык. Шуның нәтиҗәседер инде.

**[2 секунд пауза]**
**Прослушайте диалог второй раз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**

**Бишенче сорау. Айсылу туган көнен кайда үткәрергә тели?**

Рәшит: Айсылу, сәлам, киләсе атнада синең туган көнең? Шулаймы?

Айсылу: Әйе. Туган көнем 25 нче майда.

Рәшит: Кайда бәйрәм итәргә җыенасың? Кемнәрне чакырасың? Уйладыңмы инде?

Айсылу: Дөресен әйткәндә, уйларга вакытым юк әле. Хәл итәргә кирәклеген аңлыйм инде. Син нәрсә киңәш итәсең? Кайда үткәрү яхшырак булыр: өйдәме, әллә дуслар белән табигатькә чыгумы?

Рәшит: Үзеңә ничек уңайлы, шулай эшлә. Миңа калса, кайда да күңелле булыр. Ел саен синең туган көнеңдә рәхәтләнеп күңел ачабыз. Яхшы дуслар белән кайда да күңелле.

Айсылу: Анысы шулай. Дусларыбыз һәрвакыт кызыклы уеннар оештыралар, конкурслар үткәрәләр, бииләр, җырлыйлар, шуңа күрә туган көн бәйрәме искиткеч күңелле үтә.

Рәшит: Синең белән килешәм. Шулай да бер урынны сайлыйк инде. Дусларга әйтергә кирәк була. Һәр кеше үз эшләрен алдан планлаштыра бит, белеп торсыннар.

Айсылу: Алайса өйдә үткәрик. Әнием тәмле ризыклар пешерер. Үзебез теләгәнчә ял итәрбез.

Рәшит: Нәкъ шулай, дустым. Син хаклы.

**[2 секунд пауза]**
**Диалогны икенче тапкыр тыңлагыз.**

[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**

**Алтынчы сорау. Айсылуга кайсы яшелчә күбрәк ошый?**

Рәшит: Айсылу, сәламәт булу өчен, син нәрсәләр эшлисең?

Айсылу: Мин гимнастика белән шөгыльләнәм, саф һавада еш булырга тырышам, бассейнда йөзәм. Ә син, Рәшит, нишлисең?

Рәшит: Мин дә синең кебек спорт белән шөгыльләнәм, иртән йөгерәм, дөрес тукланам.

Айсылу: Әйе, хәзерге вакытта ашамлыкларга зур игътибар бирәләр, чөнки һәр нәрсәне чама белән ашарга кирәк. Алар арасында файдалыракларын сайлый белү дә бик мөһим.

Рәшит: Синеңчә, иң файдалы ризыклар нindiләр?

Айсылу: Минемчә, балык, ит һәм сөт ризыклары. Әлбәттә, җиләк-җимеш һәм яшелчә.

Рәшит: Әйе шул, мин дә шулай уйлыйм. Әле тагын суны да онытмаска кирәк. Табиблар әйтүенчә, көн саен билгеле бер күләмдә су эчү дә организм өчен файдалы.Ә син кайсы яшелчәләрне аеруча файдалы дип саныйсың?

Айсылу: Миңа калса, алар арасында иң файдалысы - кәбестә белән кишер. Аларда витаминнар бик күп.

Рәшит: Ә миңа күбрәк кыяр һәм помидар ошый.

Айсылу: Аңлашылды.

**[2 секунд пауза]**
**Прослушайте диалог второй раз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**

**Җиденче сорау. Айсылуның әбисе кем булган?**

Рәшит: Айсылу, синең әбиең һәм бабаң бармы?

Айсылу: Әйе, алар Мамадыш районында яшиләр.

Рәшит: Алар әтиеңнең әнисе белән әтисеме?

Айсылу: Юк. Алар әниемнең әтисе белән әнисе. Ә синең әбиләрең, бабаларың бармы, Рәшит?

Рәшит: Әйе. Минем ике әбием һәм ике бабам бар. Алар Яр Чаллыда яшиләр. Алар лаеклы ялда инде. Мин аларда кунакта еш булам. Алар да безгә кунакка килергә яраталар. Гадәттә, гаилә бәйрәмнәрен без бергә үткәрәбез.

Айсылу: Әбиләрең кем булганнар, кайда эшләгәннәр, Рәшит?

Рәшит: Бер әбием тәрбияче булган, гомере буе балалар бакчасында эшләгән. Икенчесе һөнәре буенча – хисапчы. Ул “КамАЗ” заводында эшләгән. Ә синең әбиең нинди эштә эшләгән, Айсылу? Син беләсеңме?

Айсылу: Әлбәттә, беләм. Ул - гомерен китапка багышлаган кеше. Ул авыл китапханәсендә эшләгән.

Рәшит: Менә ничек. Димәк, син аңа охшагансың. Син дә китап укырга яратасың бит. Аның дәвамчысы булырсың.

Айсылу: Әйе. Миңа да бу һөнәр ошый. Заманча китапханәдә эшлисем килә.
**Рәшит:** Афәрин. Уңышлар сиңа.

**[2 секунд пауза]**
**Прослушайте диалог второй раз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**

***Прослушайте разговор двух друзей. Определите, какие из приведенных утверждений 8 - 13 соответствуют содержанию текста, а какие – не соответствуют. Вы услышите аудиозапись дважды.***

**[пауза 20 секунд]**

Самат: Сәлам, Алсу!

Алсу: Сәлам, Самат! Әйт әле, син беләсеңме, безнең республикада кайсы милләт вәкилләре яши?

Самат: Төгәл белмим, чөнки бу мәгълүмат белән кызыксынганым юк. Ә сиңа бу мәгълүмат ник кирәк булды?

Алсу: Мин татар теленнән “Теле барның- иле бар” темасына проект эше яздым. Шул вакытта бу сорауга да җавап эзләдем. Бездә яшәүче халыкларның саны шактый зур икән. Статистикага караганда, аларның саны 170 кә җитә.

Самат: Шулай күпме?

Алсу: Әйе, мин үзем дә гаҗәпләндем.

Самат: Татарстанның төп халкы татарлардан тыш, кайсылары күпчелекне тәшкил итә?

Алсу: Икенче урында руслар тора, ә өченче урында – чувашлар. Алардан башка мордва, мари, удмурт, башкорт, төрек, үзбәк һәм башка милләт халыклары да яши. Шуңа күрә Татарстанны күпмилләтле республика дип атыйлар.

Самат: Аңлашыла ки, соңгы елларда республикага башка өлкәләрдән килеп эшләүче һәм яшәүчеләрнең саны арта.

Алсу: Шунысы мөһим: республикабызда барлык милләтләр дус-тату яшиләр. Алар бер-берсенең гореф-гадәтләрен, милли бәйрәмнәрен беләләр, бергә бәйрәм итәләр.

Самат: Ә син проект эшеңдә бу бәйрәмнәр турында да яздыңмы?

Алсу: Әлбәттә. Төрле халыкларның милли бәйрәмнәре белән танышу шулай ук кызык булды. Татарларның милли бәйрәмнәрен без яхшы беләбез, ә менә башка халыкларныкы минем өчен ачыш булды.

Самат: Нинди бәйрәмнәр турында яздың?

Алсу: Мәсәлән, мариларның Семык бәйрәме миндә кызыксыну уятты. Ул мари халкының иң көтеп алган һәм яраткан бәйрәмнәреннән берсе булып санала. Бу бәйрәм җәйнең башлануын хәбәр итә икән.

Самат: Ул кайчан үткәрелә?

Алсу: Семык бәйрәме Пасхадан соң җиде атна узгач башлана һәм якшәмбе көнне тәмамлана.

Самат: Синең бу бәйрәмдә буласың киләме?

Алсу: Әйе, чөнки хәзерге вакытта бу бәйрәм мари халкының фольклор фестивале буларак үткәрелә.

Самат: Тагын кайсы халыкның милли бәйрәме турында сөйләдең?

Алсу: Тагын мин якут халкының Ысыах бәйрәме турында кызыклы язмалар таптым. Бу – җәй җитүгә багышланган бәйрәм.Ул табигать яңарышын белдерә.

Бәйрәм ахырында бөтен халык милли бию башкара. Бәйрәмнең исеме якут теленнән муллык дип тәрҗемә ителә.

Самат: Менә ничек яхшы әзерләнгәнсең. Миңа да бик кызык булды. Алга таба да сиңа уңышлар телим.

Алсу: Зур рәхмәт!

**[2 секунд пауза]**

**Прослушайте диалог второй раз.**

[язма икенче тапкыр яңгырый]

**[2 секунд пауза]**

**Внесите ответы в бланк ответов.**

## ҖАВАПЛАР

| **Биремнең номеры** | **Дөрес җавап** |
|---|---|
| 1 | 2 |
| 2 | 3 |
| 3 | 2 |
| 4 | 1 |
| 5 | 3 |
| 6 | 2 |
| 7 | 2 |
| 8 | 2 |
| 9 | 2 |
| 10 | 1 |
| 11 | 1 |
| 12 | 2 |
| 13 | 1 |
| 14 | 3 |
| 15 | 2 |
| 16 | 3 |
| 17 | 2 |
| 18 | 3 |
| 19 | 3 |
| 20 | 1 |

| | |
|---|---|
| 21 | 2 |
| 22 | 3 |
| 23 | 2 |
| 24 | 1 |
| 25 | 3 |
| 26 | 2 |
| 27 | 1 |
| 28 | 3 |

## 5 нче вариант

## Раздел 1

***Прослушайте 7 коротких диалогов. В заданиях 1 - 7 укажите правильный вариант ответа. Вы услышите аудиозапись дважды.***

**1** **Рәшит Айсылуны нәрсә белән котлый?**

1) бәйгедә бүләк алуы белән
2) ярышта җиңүе белән
3) чыгыш ясавы белән

**2** **Дуслар кемнәр белән очрашырга уйлыйлар?**

1) элеккеге дуслары
2) яңа танышлары
3) сыйныфташлары

**3** **Рәшит кемгә ярдәм итәргә тиеш?**

1) энесенә
2) әнисенә
3) әбисенә

**4** **Айсылуның нишлисе бар?**

1) уенда катнашасы бар
2) репетициягә барасы бар
3) дәрескә әзерләнәсе бар

**5** **Айсылуга кем ярдәм иткән?**

1) әти-әнисе
2) сыйныфташлары
3) күршеләре

**6** **Айсылуга кайсы һөнәр ошый?**

1) төзүче
2) башлангыч мәктәп укытучысы
3) тегүче

**7** **Рәшит кибеттә нәрсә сатып алган?**

1) каймак һәм эремчек
2) кыяр һәм кәбестә
3) балык һәм май

***Прослушайте разговор двух друзей. Определите, какие из приведенных утверждений 8 - 13 соответствуют содержанию текста (1), а какие – не соответствуют (2). Вы услышите аудиозапись дважды.***

**8** Алсу да, Самат та сәнгать белән кызыксыналар.
1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**9** Алсу дустын татар яшьләр театрына чакыра.
1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**10** Алар дуслык турындагы әсәрне карарга җыеналар.
1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**11** Саматка бу әсәрнең эчтәлеге таныш.
1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**12** Мәктәпне тәмамлагач, Саматның артист буласы килә.
1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**13** Бу әсәрнең төп фикере - кешеләр арасында тынычлык урнаштыру.
1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

## Раздел 2

***Прочитайте тексты в заданиях 14 – 16. После каждого текста определите правильный вариант ответа.***

**14**

Милли китапханәнең яңартылган бинасына чакырабыз!

Шәһәр үзәгендә Пушкин урамында урнашкан китапханәдә сезне көтеп калабыз. Биредә сез китап укудан тыш күргәзмәләр һәм спектакльләр карый аласыз. Шулай ук монда дусларыгыз белән очрашырга һәм аралашырга, компьютерда эшләргә, электрон пианинода уйнарга мөмкинлекләрегез дә бар. Китапханәдә газетлар һәм журналлар уку өчен, махсус заллар бар.
Китапханә – тарих белән хәзерге заманны берләштерә торган урын. Безгә рәхим итегез!

**Белдерүдә нәрсә турында әйтелә?**
1) Милли китапханәнең тарихы һәм хәзерге торышы турында.
2) Милли китапханәнең эшчәнлеге турында.
3) Милли китапхәнәнең бүлекләре турында.

| | | |
|---|---|---|
| **15** | “БиюМәйдан” биючеләр фестиваленә чакырабыз!<br>2 нче декабрьдә көндезге сәгать бердә район Мәдәният йортында балалар бакчалары, мәктәп коллективлары үзләренең чыгышларын күрсәтәчәк. Кичен төрле оешмаларның бию ансамбльләре жюри алдында чыгыш ясаячак.<br>Бәйгедә 5 яшьтән алып 60 яшькә кадәр үзешчән биючеләр катнаша ала.<br>Фестивальнең Гала–концерты киләсе атнада узачак. Биергә яратучы һәркемне фестивальдә көтеп калабыз. Аның максаты – бию сәнгатен үстерү, милли биюләргә кызыксыну уяту, бию осталарын халыкка таныту. | **Бу хәбәр нәрсә турында?**<br>1) Балаларны бию бәйгесендә катнашырга чакыру турында.<br>2) Бию фестиваленең төп максаты турында.<br>3) Төрле яшьтәге кешеләрне биючеләр бәйгесендә чыгыш ясарга чакыру турында. |
| **16** | Хәерле көн, Алисә! Хәлләрең әйбәтме? Укуларың ничек?<br>Минем хәлләрем шәп. Сиңа кайбер яңалыклар турында хәбәр итәргә ашыгам. Үткән якшәмбе көнне мин дусларым белән бик кызыклы чарада катнаштым. Шәһәребездә Яшьләр көнен билгеләп үттеләр. Шул уңайдан паркларда төрле чаралар узды. Без яшьләр экстрим-паркында булдык. Анда иҗади мастер-классларда катнаштык, волонтер булып эшләп карадык, кызыклы чыгышлар тыңладык, яңа дуслар таптык.. Вакытыбызны бик файдалы үткәрдек. Ә синең тормышыңда нинди яңалыклар бар? Вакыт табып, миңа хат яз, көтәм.<br>Сәлам белән дустың Әлфия. | **Электрон хатында Әлфия дустына нәрсә турында язган?**<br>1) Шәһәрдә үтәчәк Яшьләр көне турында.<br>2) Яшьләр көнендә уздырылган чараларда катнашуы турында.<br>3) Яшьләр көнен үткәрү урыны турында. |

***Прочитайте текст. В заданиях 17 - 20 укажите правильный вариант ответа.***

Кояштагы тап

Еракта, кояш йокларга кайта торган җирдә яшәгән, ди, бер малай. Малайның әнисе генә булган. Әнисе иртә торган, соң яткан, көннәр буе нидер эшләгән. Ә улы аңардан: «Әнием, син көннәр буе ниләр эшлисең?» — дип сорамаган, уйнаган да уйнаган. Бер көнне малайның әнисе авырган. Шунда ул урамнан улын чакырган да болай дигән:

— Улым, хәлем начар. Хәтта суга бара алмадым. Ә минем эчәсем килә. Берәр чиләк су алып кайтчы, балам.

Малай, уеннан бүлдергәнгә үпкәләп:

— Суны иртән алып кайтырга иде, — дигән.

— Иртүк алып кайтсам, җылыныр дигән идем. Син бит, уеннан кайткач, салкын су эчәргә яратасың, — дигән әнисе. Малай авырлык белән генә риза булган.
— Улым, — дигән әнисе, — суны Көймә тавы артындагы чишмәдән ал. Аның суы тәмле. Малай, чиләген күтәреп, урамга чыккан. Көймә тавы бик еракта булып күренгән аңа. Кояшы да кыздыра икән. «Мондый кызуда анда барганчы, суны якындагы чишмәдән алсам да ярар», — дип уйлаган малай һәм, чиләген куеп, уйнарга тотынган. Эчәсе килгәч кенә, суга барырга кирәклеге исенә төшкән. Менә ул су алып кайткан. Әнисе аңа: «Рәхмәт, улым», — дигән һәм суны эчкән. Эчкән саен, көче арткан. Бераздан сәламәтләнеп җиткән. Малай, сөенеп, урамга йөгергән.
«Әнием суның кайдан икәнлеген белмәде», — дип уйлаган ул. Шулчак кояш кинәт карала башлаган. Дөнья ямьсезләнгән. Кошлар ояларына качканнар. Малай өенә чапкан.
— Әни, кара, кояшның йөзе каралды, дигән. Әнисе кояшка караган да әйткән:
— Кемдер начарлык эшләгән, улым.
Кояшның шул кеше өчен оялудан йөзе каралган. Чөнки җирдә кояш күрмәгән бер генә эш тә юк.
— Әни, — дигән малай, — суны Көймә тавы артындагы чишмәдән алмадым, гафу ит. Малай әнисенә караган. Әнисе улын күкрәгенә кыскан. Шулвакыт кояштагы караңгылык кими башлаган. Дөнья яктырган, Бар нәрсә элекке хәленә кайткан, бары тик кояштагы кара тап кына бетеп җитмәгән. Әйе, дөньяда бер генә начарлык та эзсез калмый. Начарлыкны кояш та яндырып бетерә алмый. (*Фәнис Яруллин*)

**17** Әнисе улына нишләргә кушкан?
1) Бер чиләк су алып кайтырга.
2) Иртән тору белән суга барырга.
3) Җылы су бирергә.

**18** Малай суны кайдан алып кайткан?
1) Көймә тавы артындагы чишмәдән.
2) Якындагы чишмәдән.
3) Урамдагы чишмәдән.

**19** Кояш ни өчен карала башлаган?
1) Дөнья ямьсезләнгән.
2) Кояш начарлык эшләгән кеше өчен оялган.
3) Кояш начарлыкны күрмәгән.

**20** Улы әнисенә нәрсә турында әйткән?
1) Яхшы эше.
2) Ялганы.
3) Гафу үтенүе.

**Раздел 3**

***Прочитайте текст. В заданиях 21 – 28 определите правильный вариант ответа.***

Гап-гади Инсаф

Җир йөзендәге барлык малайларның да (21) ... була. Җирән чәчлеме ул, кара чәчлеме, сугыш чукмарымы — барыбер. (22) ... исемең, туганчы ук табылган. Табылган гына да түгел — тагылып ук куелган була. Мине Инсаф дип (23) ... башлаганнар. Миңа (24) ... . Хет әллә кем дип атаган булсыннар иде. Исемнәр күп бит. Дөнья тулы малайлар, дөнья тулы исем. Шулай булса да (25) ... ялгышмый. Хәбир дисәң, Хәбире «ә» ди, Җәмиле тик тора. Җәмил дисәң, анысы «җә» ди, Хәбире тик тора. Бу әти-әниләр исемнәрне ничек (26) ... бетерәләрдер. Башка малайлар беләләрме, юкмы, мин үземә нишләп Инсаф диюләрен беләм. Бер елны, мин авырганда, (27) ... әби килгән иде. Ул шунда миңа кипкән җиләк кайнатып эчерде. Инсафның ни икәнен дә ул әйтте. Әбисенең (28) ... тыңлап, әче суны эчкән, әмма тәрәзә бозын яламый торган әдәпле малайларны Инсаф дип йөртәләр икән. (*Газиз Мөхәммәтшин*)

**21** 1) исемле 2) исемнәр 3) исемнәре

**22** 1) синеке 2) сиңа 3) синдә

**23** 1) йөртә 2) йөртеп 3) йөртергә

**24** 1) бердәнбер 2) барыбер 3) битараф

**25** 1) кемдер 2) бернәрсә 3) беркем

**26** 1) язып 2) уйлап 3) сөйләп

**27** 1) авылына 2) авылыннан 3) авылында

**28** 1) чыгышын 2) җөмләсен 3) сүзен

## Раздел 4

***В заданиях 29-32 необходимо написать репли ки в соответствии с заданной речевой ситуацией.***

**Сөйләм ситуациясенә туры килгән репликаларны языгыз.**

**29** Сообщите другу (подруге), что вы хотите быть волонтером и участвовать в различных мероприятиях.

**30** Спросите у друга (подруги), на каких национальных праздниках приходилось бывать ему (ей).

**31** Предложите друзьям поехать на природу после окончания экзаменов.

**32** Спросите у друзей, кто из современных исполнителей нравится им больше всего и почему.

**33** **Вы получили письмо от друга (подруги). Напишите ему (ей) письмо объемом не менее 60 слов, ответив на его (её) вопросы.**
**Для ответа на это задание используйте специальный бланк ответов.**

| |
|---|
| ... *Минем буш вакытым аз, чөнки мин имтиханнарга әзерләнәм, өстәмә дәресләргә йөрим, күп укыйм, Интернеттан кирәкле мәгълүматны эзлим һәм өйрәнәм.*<br><br>... *Ә син имтиханнарга ничек әзерләнәсең?... Нинди фәннәрдән күбрәк мәгълүмат укыйсың? ... Нинди чыганаклардан файдаланасың?* |

## Тыңлап аңлау биремнәре өчен текстлар

**Прослушайте 7 коротких диалогов. В заданиях 1 - 7 укажите правильный вариант ответа. Вы услышите аудиозапись дважды.**
**Беренче сорау. Рәшит Айсылуны нәрсә белән котлый?**
Айсылу: Сәлам, Рәшит!
Рәшит: Сәлам, Айсылу! Укуларың ничек бара? Күптән күргәнем юк сине.
Айсылу: Барысы да әйбәт, рәхмәт. Соңгы вакытта эшләрем күп булды. Мәктәптә үткәрелгән төрле чараларда катнаштым.
Рәшит: Нинди чараларда? Мәктәптә төрле бәйгеләр, фестивальләр булдымы?
Айсылу: Андый чаралар да, фәнни чаралар да булды, спорт ярышлары да үтте. Ел саен районда укучыларның фәнни конференциясе уза, шуңа бик нык әзерләнергә туры килде.
Рәшит: Афәрин! Барысында да катнаштыңмы? Ничек җитешәсең син? Мин спорт ярышларында гына катнашам, башка бернәрсәгә вакытым җитми. Әле дәресләргә дә әзерләнергә кирәк бит.
Айсылу: Әлбәттә. Һәр эшкә өлгерергә туры килә. Мин кечкенәдән шулай өйрәнгәнмен инде. Концертларда да җырлыйм, чаңгыда да яхшы шуам. Хәзер менә төрле фәннәрдән уздырыла торган чараларда да чыгыш ясарга туры килә.

Рәшит: Сау-сәламәт бул инде, дустым. Котлыйм сине уңышларың белән!
Айсылу: Рәхмәт. Сиңа да спортта уңышлар!

**[2 секунд пауза]**
**Прослушайте диалог второй раз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**

**Икенче сорау. Дуслар кемнәр белән очрашырга уйлыйлар?**
Рәшит: Айсылу, сәлам, мин сине шәһәр үзәгендә йөрергә чакырам. Иртәгә вакытың бармы?
Айсылу: Бәлки ял көнендә барырбыз, вакыт та күбрәк булыр?
Рәшит: Ярый, ничек әйтәсең, мин шуңа риза. Минем күптән шәһәр үзәгендә булганым юк. Җәй беткәнче, матур урыннарны карап кайтыйк.
Айсылу: Әлбәттә, бик яхшы фикер. Казансу буенда, Казан Кремлендә һәрвакыт туристлар күп була. Алар шәһәребезнең матурлыгына сокланалар. Без дә сокланып кайтырбыз.
Рәшит: Шулай шул. Үз шәһәребезнең истәлекле һәм тарихи урыннарын карарга вакытыбыз җитми, ә кешеләр башка илләрдән сәяхәткә киләләр, Казан, Бөек Болгар белән танышалар.
Айсылу: Рәшит, син ничек уйлыйсың, әйдә, җәй көне лагерьда танышкан яңа дусларыбызны да очрашуга чакырабыз. Бергә-бергә тагын да күңеллерәк булыр. Саф һавада йөргәннән соң, "Түбәтәй" кафесына кереп, тәмле чәй эчәрбез, татар милли ашлары ашарбыз.
Рәшит: Шәп фикер. Мин аларга шалтыратып сөйләшермен. Риза булсалар, очрашу вакытын һәм урынын билгеләрбез.
Айсылу: Якшәмбегә кадәр! Чакыруың өчен зур рәхмәт сиңа!

**[2 секунд пауза]**
**Прослушайте диалог второй раз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый] **[2 секунд пауза]**

**Өченче сорау. Рәшит кемгә ярдәм итәргә тиеш?**
Рәшит: Айсылу, сәлам, хәлләрең әйбәтме?
Айсылу: Беркөе, рәхмәт. Син кая юл тотасың?
Рәшит: Мин даруханәгә барам әле.
Айсылу: Нәрсә булды? Әниең авырыймы, әллә әтиеңме?
Рәшит: Юк, алар исән-саулар. Әнием командировкада әле, Мәскәүдә. Әтием эштә.
Айсылу: Ә кемгә дарулар кирәк соң?
Рәшит: Әбиемнең бүген хәле начарланды. Йөрәге авырта, даруы беткән.
Айсылу: Ә нинди дару алырга кирәклеген беләсеңме? Минем дә әбием йөрәк даруы эчә. Кирәк булса, аннан сорармын.

Рәшит: Рәхмәт, Айсылу. Нинди дарулар кирәклеген мин беләм. Ярдәм генә итсен. Әбинең сәламәтлеге өчен бик борчылабыз.
Айсылу: Барысы да яхшы булыр.
[2 **секунд пауза]**
**Диалогны икенче тапкыр тыңлагыз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**

**Дүртенче сорау. Айсылуның нишлисе бар?**
Рәшит: Айсылу, сәлам, хәлләр ничек?
Айсылу: Сәлам, бик яхшы, рәхмәт!
Рәшит: Син үткән атнада нинди чарада катнаштың?
Айсылу: Мин бит Шаяннар һәм Тапкырлар клубында уйныйм, шәһәр командасында. Үткән атнада без булачак уеннарга әзерләндек, көн саен дәресләрдән соң клубка барырга һәм берничә сәгать дәвамында репетицияләр үткәрергә туры килде.
Рәшит: Ә агымдагы уен кайчан булачак? Минем дә барасым килә. Гадәттә ул кайда була?
Айсылу: Уен “Уникс” спорт комплексында үтә. Теләсәң, мин сиңа билетлар алып куярмын. Бер билет кирәкме?
Рәшит: Мөмкин булса, ике билет алырсың әле. Дустым Айдарны да үзем белән чакырырмын. Синең җанатарларың булырбыз. Тагын кайсы командалар катнашачак?
Айсылу: Мин әле төгәл белмим. Ярымфинал булачак. Шуңа күрә бик җаваплы уен. Финалга чыгу өчен, без җиңәргә тиеш.

**[2 секунд пауза]**
**Прослушайте диалог второй раз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**

**Бишенче сорау. Айсылуга кем ярдәм иткән?**

Рәшит: Айсылу, бүген кичен нишләргә уйлыйсың?
Айсылу: Бүген эшләрем шулкадәр күп, нишләргә дә белмим.
Рәшит: Нәрсә булды? Ярдәм кирәк булса, әйт. Мин һәрвакыт сиңа булышырга әзер.
Айсылу: Беренчедән, миңа бәйгедә катнашу өчен, оештыру комитетына үзем турында эссе җибәрергә кирәк. Икенчедән, иртәгә әтиемнең туган көне, аңа бүләк алып җитешергә кирәк. Өченчедән, иртәгә әдәбият дәресендә төркемебез белән проект эшен якларга кирәк, аның презентациясен ясап бетерәсе бар.
Рәшит: Әйе, чыннан да, эшләрең бигрәк күп икән шул. Барысы да бер көнгә җыелган. Әйдә, нәрсәдән башлыйбыз?
Айсылу: Үзем дә уйлап утырам әле. Эссе җибәрергә озак вакыт кирәк түгел, анысын үзем дә эшләрмен. Әтигә бүләк алырга әни белән барырбыз дип уйлыйм.

Ә менә  әдәбият дәресендә ясыйсы чыгышны сыйныфташларым язып бетерергә булышыр дип өметләнәм.
Рәшит: Менә ничек яхшы, бергә-бергә уйлашкач-сөйләшкәч, мәсьәләләрне хәл итү юлларын таптык. Тынычланып эшлисе генә калды.
Айсылу: Рәхмәт сиңа, дустым.

**[2 секунд пауза]**
**Диалогны икенче тапкыр тыңлагыз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**

**Алтынчы сорау.  Айсылуга  кайсы һөнәр ошый?**
Рәшит: Айсылу, 9 нчы сыйныфтан соң син укуыңны мәктәптә дәвам итәчәксеңме?
Айсылу: Юктыр, мин киләчәктә тегүче булырга, заманча киемнәр тегәргә хыялланам, шуңа күрә тугызынчы сыйныфтан соң колледжга китәргә кирәк дип уйлыйм.
Рәшит: Нинди колледж? Шундый махсус уку йорты безнең шәһәрдә бармы?
Айсылу:  Әйе, ул технологияләр һәм дизайн колледжы дип атала. Анда тегүчеләрне дә әзерлиләр.
Рәшит: Анда ничә ел укыйлар?
Айсылу: Сайтларында 3 ел һәм 10 ай укырга кирәк дип язылган. Аннары шушы юнәлеш буенча университетка укырга кереп була. Заманча киемнәр тегү өчен, белемле булырга кирәк бит.
Рәшит: Әйе шул. Кызык һөнәр сайлагансың, Айсылу. Син бик матур киенәсең, шуңа күрә яхшы белгеч булырсың дип ышанам. Дустың Фәридә дә шул колледжга барамы?
Айсылу: Юк, ул педагогика колледжында укырга тели, чөнки аңа башлангыч мәктәп укытучысы һөнәре ошый.
Рәшит: Ул да яхшы һөнәр сайлаган. Уңышлар сезгә!
Айсылу: Рәхмәт!

**[2 секунд пауза]**
**Прослушайте диалог второй раз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**

**Җиденче сорау. Рәшит кибеттә нәрсә сатып алачак?**
Рәшит: Айсылу, синең кибеткә барасың бармы?
Айсылу: Әйе. Гадәттә, әнием ашамлыклар сатып ала, ләкин ул авылга әбинең хәлен белергә кайтып китте. Шуңа күрә ашамлыкларны мин алырга тиеш булам.
Рәшит: Кайсы кибеткә барасың килә? Мин үзем “Магнит” кибетенә йөрергә яратам, чөнки ул йортыбыздан ерак түгел. Анда сайлау мөмкинлеге дә зуррак.
Айсылу: Әйе, мин дә күбрәк шул кибеттән ашамлыклар алам. Әйдә, ничәдә очрашабыз? Биштәме? Син минем подъезд янына килерсең дә бергә китәрбез.

Рәшит: Ярар, шулай уңайлырак булыр. Син нәрсәләр алырга кирәклеген беләсеңме?
Айсылу: Көн саен без кара икмәк, күмәч, сөт, каймак, эремчек алабыз. Иртән мин көн саен каймак белән эремчек ашыйм. Ә сиңа нәрсәләр алырга кирәк, Рәшит?
Рәшит: Миңа әнием яшелчәләр алып кайтырга кушты, башка ашамлыклар әле бар диде. Мин иртән һәрвакыт яшелчә салаты ашыйм, шуңа кыяр һәм кәбестә алырмын.
Айсылу: Әйе, җиләк –җимеш һәм яшелчә бик файдалы, көн саен ашарга кирәк.
Рәшит: Өйдән чыгар алдыннан сиңа шалтыратырмын.

**[2 секунд пауза]**
**Прослушайте диалог второй раз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**

***Прослушайте разговор двух друзей. Определите, какие из приведенных утверждений 8 - 13 соответствуют содержанию текста, а какие – не соответствуют. Вы услышите аудиозапись дважды.***

**[пауза 20 секунд]**

Самат: Сәлам, Алсу!
Алсу: Сәлам, Самат! Әйт әле, синең кызыклы спектакль карыйсың киләме?
Самат: Премьера буламы? Кайсы театрда?
Алсу: Кариев театрында. Синең анда булганың бармы?
Самат: Юк әле, без күбрәк Камал театрына яки Тинчурин театрына йөрибез.
Алсу: Менә алайса театр белән дә танышырсың, премьера да карарбыз. Кариев театры - милли яшьләр театры ул. Ә афишаларга бу спектакль – яңа сезонның беренче премьерасы дип язылган.
Самат: Ә нинди спектакльгә барабыз? Исемен әйт инде.
Алсу: Аның исеме сиңа бик таныш, чөнки ул - мәңге искерми торган дөнья классикасы. Аның эчтәлеген дә яхшы беләсеңдер дип уйлыйм. Без синең белән бөек Шекспирны татарча карарга барабыз. Спектакльнең исеме - “Ромео һәм Джульетта”.
Самат: Кызык! Әлбәттә, мин бу әсәрне беләм. Ул бит беренче мәхәббәт турында.
Алсу: Әйе, бик дөрес.
Самат: Ә төп рольне кем башкара? Афишаларда бу турыда язылганмы?
Алсу: Джульетта ролен театр училищесы студенты Алия Фәйзиева башкара дип язылган. Бу – аның беренче зур роле.
Самат: Ә Ромеоны кем уйный? Ул да студентмы?
Алсу: Юк. Бу рольне Кариев театры артисты Булат Гатауллин башкара. Танышларым әйтүенчә, ул – бик сәләтле артист.

Самат: Алсу, син ничек уйлыйсың, бу әсәрдә нинди мәсьәлә яктыртылган? Театрга барганчы, бу турыда сөйләшеп алыйк әле. Анда нинди каршылык күрсәтелә?
Алсу: Минемчә, бу әсәр бик катлаулы мәсьәләне яктырта: гаиләләр арасындагы мөнәсәбәтләр, шул исәптән халыклар, илләр арасындагы бәйләнешләр дип әйтә алабыз. Нинди генә каршылык чыкса да, тынычлык урнаштыруга омтылырга кирәк. Бу әсәрнең төп фикере шуннан гыйбарәт дип уйлыйм.
Самат: Син миңа күп кызыклы мәгълүмат җиткердең, дустым. Чыннан да, бу мәхәббәт тарихын яшьләр театрында бик тә карыйсым килә.
Алсу: Бик яхшы! Димәк, без синең белән җомга көнне бергә классик әсәр карарга барабыз.
Самат: Мин ике куллап риза. Шундый яхшы тәкъдимең өчен мин сиңа рәхмәтле. Син барлык яңалыкларны беләп торасың, кайда нәрсә булачагын әйтеп бирәсең.
Алсу: Мин сәнгать белән кызыксынам, үзем дә, мәктәпне тәмамлагач, театр училищесында укырга телим. Шуңа күрә барлык яңалыклар белән хәбәрдар.
Самат: Шундый дустым булуына мин бик куанам.
Алсу: Рәхмәт.
**[2 секунд пауза]**
**Прослушайте диалог второй раз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**
**Внесите ответы в бланк ответов.**

## ҖАВАПЛАР

| Биремнең номеры | Дөрес җавап |
|---|---|
| 1 | 3 |
| 2 | 2 |
| 3 | 3 |
| 4 | 1 |
| 5 | 2 |
| 6 | 3 |
| 7 | 2 |
| 8 | 2 |
| 9 | 1 |
| 10 | 2 |
| 11 | 1 |
| 12 | 2 |
| 13 | 1 |
| 14 | 2 |
| 15 | 3 |
| 16 | 2 |
| 17 | 1 |

| | |
|---|---|
| 18 | 3 |
| 19 | 2 |
| 20 | 2 |
| 21 | 3 |
| 22 | 2 |
| 23 | 1 |
| 24 | 2 |
| 25 | 3 |
| 26 | 2 |
| 27 | 2 |
| 28 | 3 |

## 6 нчы вариант

## Раздел 1

***Прослушайте 7 коротких диалогов. В заданиях 1 - 7 укажите правильный вариант ответа. Вы услышите аудиозапись дважды.***

**1** **Әминә ни өчен икеләнә?**
1) курайда уйныйсы бар
2) дуэт җырлыйсы бар
3) киногa барасы килми

**2** **Гали нишләргә яратмый?**
1) әдәби әсәр укырга
2) мәкаләләр укырга
3) сочинение язарга

**3** **Айдар ни өчен походка барырга теләми?**
1) тубы һәм рюкзагы юк
2) табигатьтә ял итәргә яратмый
3) кәефе начар

**4** **Сәлим иртән нишләргә тиеш?**
1) энесен бакчага илтергә
2) соңга калмаска
3) мәктәпкә беренче килергә

**5** **Зәринә кая барган?**
1) ювелир әйберләре кибетенә
2) архивка
3) музейга

**6** **Гөлия Гомәрне кайчанга кунакка чакыра?**
1) бүгенгә
2) хәзер
3) якшәмбегә

**7** **Айрат нәрсәгә борчыла?**
1) олимпиаданың шәһәр турына үтүенә
2) химия олимпиадасында җиңүче булуына
3) кагыйдәне аңлый алмавына

***Прослушайте разговор двух друзей. Определите, какие из приведенных утверждений 8 - 13 соответствуют содержанию текста (1), а какие – не соответствуют (2). Вы услышите аудиозапись дважды.***

**8** Алсу дәрес материалын аңламавы турында әйтә.

1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**9** Айрат информатикадан ярдәм итү тәҗрибәсе барлыгын белдерә.

1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**10** Алсуга өстәмә дәресләргә йөрергә киңәш иткәннәр.

1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**11** Айрат сишәмбе көнне бассейнга бара.

1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**12** Алсуның пәнҗешәмбе көнне бию түгәрәгенә барасы бар.

1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**13** Айрат белән Алсу бер урамда яшиләр.

1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

## Раздел 2

***Прочитайте тексты в заданиях 14 – 16. После каждого текста определите правильный вариант ответа.***

**14**

Шигырь яратучы дуслар!

Сезне 23 нче декабрьдә узачак “Яңа ел бизәкләре” дип аталган шигърият кичәсенә чакырабыз. Кичәдә танылган шагыйрьләрнең сүзләренә язылган җырлар тыңларсыз, яшь шагыйрьләр иҗаты белән танышырсыз, шигырь язу серләрен белерсез. Яңа ел алдыннан үзегез дә шигырьләр иҗат итәргә өйрәнерсез.

Кичәдә алдан язылу буенча катнашып була. Урыннар чикләнгән. Язылу өчен телефон: 89196857154.

Кичә “Татарстан - Яңа гасыр” телестудиясендә узачак. Адресы: Казан шәһәре, Шамил Усманов урамы, 2 нче йорт.

**Белдерүдә нәрсә турында әйтелә?**

1) Яңа ел бәйрәменә чакыру турында.

2) “Татарстан-Яңа гасыр” телестудиясендә узачак чарага чакыру турында.

3) Шигърият кичәсендә яңгыраячак җырлар, сөйләнәсе шигырьләр турында.

<table>
<tr><td>15</td><td>Халыкара конференциягә рәхим итегез!<br>2023 нче елның 21 нче февралендә Казан университетында мәктәп укучылары өчен “ Төрки халыклар мәдәниятендә уртак һәм аермалы яклар” дип аталган халыкара конференция үткәрелә. Анда Төркия, Кытай, Үзбәкстан, Казахстаннан да катнашучылар булачак. Конференциядә катнашу өчен, 20 нче гыйнварга кадәр оештыру комитетына чыгышыгызның тезисларын һәм үзегез турында мәгълүматны konferenciyz2023@mail.ru электрон адресына җибәрергә кирәк. Конференция материаллары җыентыкка тупланып басылып чыгачак.<br>Үзегезне сынап карагыз! Фән дөньясына рәхим итегез.!</td><td>Бу хәбәр нәрсә турында?<br>1) Конференциянең мәгълүмат хаты турында.<br>2) Казан университетында узачак конференциядә чит илдән килгән укучыларның да катнашуы турында.<br>3) Фән белән кызыксынучы укучыларга конференциядә катнашу мөмкинлеген белдерү турында.</td></tr>
<tr><td>16</td><td>Сәлам, Алсу! Хәлләрең ничек?<br>Үткән атнада син абыеңның туе булачагын һәм аңа әзерләнүегез турында язган идең. Әзерлек эшләре тәмамландымы әле? Әминә апа борчылмасын, бар да яхшы булачак. Туй узгач, нигә борчылдым икән, бер борчылыр нәрсә дә булмады бит, дип әйтәчәк әле.<br>Алсу, син яңа күлмәк сатып алырга өлгердеңме? Мин кичә шәһәр үзәгенә бардым һәм анда бер бутикта бик матур күлмәк күрдем. Минемчә ул сиңа килешәчәк. Әгәр туйга күлмәк тапмаган булсаң, мин бу бутикның адресын сиңа җибәрәм. Мин күлмәкне фотога да төшердем, ул фотоны да карарсың. Сорауларың булса яз.<br>Сәлам белән дустың Кәримә.</td><td>Электрон хатында Кәримә дустына нәрсә турында язган?<br>1) Бутикта матур күлмәк күрүе һәм дустына килешәчәге турында.<br>2) Үткән атнада яңа хәбәр ишетүе турында.<br>3) Әминә апаның сәбәпсез борчылуы турында.</td></tr>
</table>

***Прочитайте текст. В заданиях 17 - 20 укажите правильный вариант ответа.***

Кыш көне туган балалар Укчы, Кәҗәмөгез, Сукояр йолдызлыгына керәләр. Әлеге ел фасылында туган кешеләр тормышны, хезмәтне яратып, уңышларына сөенеп яши. Сабыр, бик акыллы һәм белемле булу белән аерылып торалар. Үскәч, яхшы җитәкче, инженер, галим, икътисадчы, укытучы, археолог булырга мөмкиннәр.

Көз көне туган балалар Кыз, Үлчәү, Чаян йолдызлыгына туры киләләр. Алар — нык характерлы, шат күңелле, кешелекле кешеләр. Белемгә омтылулары

чиксез. Кешеләр арасында ихтирам казаналар. Үскәч, адвокат, дипломат, журналист, артист, хирург була алалар.

Җәй көне туган балалар Игезәкләр, Кысла, Арыслан йолдызлыгына туры киләләр. Алар акыллы, сөйкемле, бөтен нәрсә белән кызыксына, киң күңелле, шәфкатьлеләр. Алар — шәп дус, иптәш, ярдәмчеләр. Үскәч, галим, музыкант да булырга мөмкиннәр.

Яз көне туган балалар Балык, Кучкар, Үгезбозау йолдызлыгына туры киләләр. Алар башлы, хәтерле, белемгә сәләтле, сәнгатьне яраталар. Үскәч, шәп рәссам, сынчы-скульптор, музыкант, табиб, талантлы гаскәр башлыгы, журналист, тегүче, пешекче була алалар.

(*Вакытлы матбугаттан*)

**17** Яхшы җитәкчеләр кайсы йолдызлык астында туалар?
1) Укчылар яки Сукоярлар.
2) Кучкар яки Балык.
3) Кысла яки Кыз.

**18** Көзен туучыларның холкы нинди була?
1) Тиз кызып китүчән.
2) Белемгә омтылучан.
3) Сәнгатькә гашыйклар.

**19** Астрологлар фикеренчә, иң шәп дуслар кайсы ел фасылында туалар?
1) язын
2) кышын
3) җәен

**20** Яхшы музыкантлар кайчан туалар?
1) җәен яки язын
2) кышын яки көзен.
3) көзен һәм язын.

## Раздел 3

***Прочитайте текст. В заданиях 21 – 28 определите правильный вариант ответа.***

Әдәплелек — кешеләр (21) ... аралашу осталыгы. Кешеләр һәрвакыт бер-берсенә ярдәм итәргә тиешләр.

Төзүчеләр (22) ... өчен йортлар төзиләр. Табиблар (23) ... дәвалыйлар. Кемнәрдер урманнар, ә кемнәрдер икмәк үстерәләр, матур киемнәр тегәләр. Кешеләр бер-берсенә (24) ... булырга, яхшылык эшләргә тиешләр. Трамвайда олы кешегә (25) ... бирергә, очрашканда, кешеләр белән исәнләшергә, аерылышканда, хушлашырга, авыру кешенең хәлен белергә кирәк. Бу бер дә

авыр түгел. Өйдә дә әти-әнигә, өлкәннәргә һәм кечкенәләргә булышырга кирәк. (26) ... белән аралашканда, кешеләргә рәхәт булсын.

Димәк, әдәпле (27)..., сине дусларың да, туганнарың да, бөтенләй таныш булмаган кешеләр дә (28) ... итәрләр.

*(Л. Васильева-Гангнустан )*

**21** 1) өчен 2) белән 3) турында

**22** 1) безнең 2) безгә 3) без

**23** 1) кешеләр 2) кешеләргә 3) кешеләрне

**24** 1) битараф 2) игътибарлы 3) сак

**25** 1) юл 2) билет 3) урын

**26** 1) синң 2) син 3) синең

**27** 1) булсаң 2) булып 3) булырга

**28** 1) хөрмәт 2) ял 3) рәхмәт

## Раздел 4

***В заданиях 29-32 необходимо написать реплики в соответствии с заданной речевой ситуацией.***

**Сөйләм ситуациясенә туры килгән репликаларны языгыз.**

**29** Сообщите одноклассникам, что в среду во время второго урока в школе состоится встреча с олимпийской чемпионкой..

**30** Спросите у друга (подруги), какие книги он(а) любит читать и почему.

**31** Предложите младшей сестре сходить в выходные в аквапарк с родителями.

**32** Посоветуйте бабушке и дедушке посетить концерт «Болгар радиосы» в концертном зале “Пирамида”

33

**Вы получили письмо от друга (подруги). Напишите ему (ей) письмо объемом не менее 60 слов, ответив на его (её) вопросы.**
**Для ответа на это задание используйте специальный бланк ответов.**

*... Мин Яңа ел бәйрәменә әзерләнә башладым инде. Дусларыма һәм туганнарыма бүләкләр әзерләдем, мәктәптә буласы кичәгә костюм тектем, чыгышымны өйрәндем. Миңа әнием дә булышты. Бәйрәм вакытында ел саен без сыйныфыбызда маскалар конкурсы үткәрәбез. Мин быел да анда катнашырга һәм җиңәргә уйлыйм.*

*... Ә син Яңа елны каршыларга әзерме инде? ... Син чирекне нинди билгеләргә тәмамлыйсың? ... Мәктәбегездә Яңа ел алдыннан нинди чаралар үткәрелә һәм син кайсыларында катнашасың?*

**Тыңлап аңлау биремнәре өчен текстлар**

**Прослушайте 7 коротких диалогов. В заданиях 1 - 7 укажите правильный вариант ответа. Вы услышите аудиозапись дважды.**
**Беренче сорау. Әминә ни өчен икеләнә?**
Азат: Әминә, син иртәгә сыйныфташлар белән киногa барасыңмы?
Әминә: Белмим әле, Азат. Өлгерерменме икән? Иртәгә “Сәйдәш” мәдәният йортында концерт була. Мин анда җырлыйм.
Азат: Син ул концертта катнашасыңмыни?
Әминә: Әйе. Дуэт җырлыйбыз.
Азат: Мин дә анда булам. Мин курайда уйныйм.
Әминә: Ә син кино карарга барасыңмы соң?
Азат: Минем барасым килә. Концерттан соң, әйдә, бергә барабыз.
Әминә: Яхшы. Барырбыз, мин риза.
.
**[2 секунд пауза]**
**Прослушайте диалог второй раз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**

**Икенче сорау. Гали нишләргә яратмый?**
Гали: Галия, син укырга яратасыңмы?
Галия: Әйе, яратам. Ә син яратмыйсыңмыни, Гали?
Гали: Яратам, ләкин мин күп укымыйм. Мин әдәби әсәрләр укыйм, фактик мәгълүматлы мәкаләләр укырга яратам. Ә син нәрсә турында китаплар укыйсың?
Галия: Миңа әдәби әсәрләр ошый. Татар әдәбиятын яратам.
Гали: Сиңа маҗаралы әсәрләр дә ошыймы?
Галия: Миңа төрле әсәрләр ошый.

Гали: Алайса, син  әсәрләрне күп беләсең инде. Миңа сочинение язарга булышырсың әле. Мин сочинение язу белән дус түгел.
Галия: Карармын.

**[2 секунд пауза]**
**Прослушайте диалог второй раз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый] **[2 секунд пауза]**
**Өченче сорау.  Айдар ни өчен походка барырга теләми?**
Айдар:  Алия,  син иртәгә урмангаа барасыңмы?
Алия: Әйе, сыйныфыбыз белән барабыз бит, Айдар.   Син бармыйсыңмы әллә?
Айдар: Барам, ләкин мин табигатьтә ял итәргә яратмыйм. Анда салкын, җил.
Алия: Табигатьтә ял итү бик рәхәт. Сыйныфташлар белән бергә бик кызык булачак.
Айдар: Мин үзем белән нәрсәләр алыйм?
Алия: Рюкзак ал. Ашамлыклар һәм туп ал.
Айдар: Ярый.
Алия: Иң мөһиме кәефең яхшы булсын. Яхшы кәеф белән туңмыйсың да, күңелсезләнмисең дә.
**[2 секунд пауза]**
**Диалогны икенче тапкыр тыңлагыз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**

**Дүртенче сорау.  Сәлим иртән нишләргә тиеш?**

Сара: Сәлим, син иртән сәгать ничәдә йокыдан торасың?
Сәлим: Сәгать алтыда, Сара. Ә син?
Сара: Мин дә алтыда торам.
Сәлим: Тиз генә җыенам да мәктәпкә китәм.
Сара: Сез ерак яшисезме?
Сәлим: Юк, бик ерак түгел. Башта энемне балалар бакчасына кертәм, аннары мәктәпкә барам. Вакыт шулай үтә.
Сара: Ләкин син һәрвакыт мәктәпкә беренче киләсең? Ни  өчен?
Сәлим: Мин соңга калырга яратмыйм. Алданрак килү яхшырак.

**[2 секунд пауза]**
**Прослушайте диалог второй раз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**

**Бишенче сорау.  Зәринә кая барган?**
Зиннур:  Зәринә,  син музейда булдыңмы?
Зәринә: Әйе, Зиннур, булдым. Анда бик матур милли киемнәр, савыт-саба күрдем.
Зиннур: Миңа архив документлары ошады. Сугышчыларның хатлары, боерыклар, яшерен язмалар турында бик кызык сөйләделәр.

Зәринә: Әйе, мин дә тыңладым. Нәкъ карт бабай сөйләгәнчә булды.
Зиннур: Зәринә, сиңа нәрсә ошады соң?
Зәринә: Борынгы бизәнү әйберләре. Алар бик матур.
Зиннур: Кызларның шул булыр инде. Башка әйбер карамагансыңдыр да әле.

**[2 секунд пауза]**
**Диалогны икенче тапкыр тыңлагыз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**

**Алтынчы сорау. Гөлия Гомәрне кайчан кунакка чакыра?**

Гөлия: Гомәр, син нинди татар ризыклары яратасың?

Гомәр: Мин барысын да яратам. Гөбәдия дә, пәрәмәч тә, бәлеш тә, кыстыбый да...

Гөлия: Хәзер нәрсә ашарга теләр идең?

Гомәр: Барысын да... Шаяртам! Хәзер кыстыбыйдан баш тартмас идем.

Гөлия: Минем дә кыстыбый ашыйсым килә. Әйдә, алайса, кафега барабыз. Мәктәп янында “Кыстыбый” кафесы ачканнар, татып карыйк.

Гомәр: Мин тагын үзең пешергән кыстыбый белән сыйлыйсың дип уйлаган идем.

Гөлия: Гомәр, мин хәзер мәктәптә бит. Монда кыстыбый пешереп булмый. Якшәмбе көнне пешергәч, сине кунакка чакырырмын. Бүген кафеныкын гына ашыйк.

Гомәр: Ярар. Киттек.

**[2 секунд пауза]**
**Прослушайте диалог второй раз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**

**Җиденче сорау. Айрат нәрсәгә борчыла?**
Айрат: Алсу, син бүген рус теле дәресенә бардыңмы?
Алсу: Әйе, Айрат, булдым. Дәрестә яңа кагыйдә өйрәндек. Укытучы мине тактада күнегү эшләргә дә чыгарды.
Айрат: Мин тагын кагыйдәне аңламам инде. Олимпиадага баргач, дәресне калдырырга туры килде.
Алсу: Син олимпиадада идеңмени? Уңышларың нинди?
Айрат: Химиядән олимпиадада идем. Җиңүче булдым. Хәзер шәһәр турына барасым булачак.
Айрат: Котлыйм! Бик яхшы булган. Рус теле өчен борчылма, кагыйдәне аңлатырмын. Катлаулы түгел ул.
Алсу: Рәхмәт! Грамматика белән дус түгел шул мин. Менә химиядән мәсьәлә чишәсе булса, рәхәтләнеп эшләр идем.
Айрат: Бу кагыйдә дә химия мәсьәләсеннән катлаулырак түгел. Борчылма!

**[2 секунд пауза]**
**Прослушайте диалог второй раз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**

***Прослушайте разговор двух друзей. Определите, какие из приведенных утверждений 8 - 13 соответствуют содержанию текста, а какие – не соответствуют. Вы услышите аудиозапись дважды.***

**[пауза 20 секунд]**

Айрат: Сәлам, Алсу!
Алсу: Сәлам, Айрат! Әйт әле, син информатикадан өстәмә дәресләргә йөрисеңме?
Айрат: Әйе, өстәмә дәресләргә дә, “Балалар үзәгендә”ге түгәрәккә дә йөрим.
Алсу: Мин информатикадан соңгы теманы аңламадым. Өстәмә дәресләргә язылсам, анда дәрестәге материалны аңлау мөмкинлеге бармы?
Айрат: Юк, анда дәрес материалын аңлатмыйлар. Без өстәмә дәресләрдә катлаулырак мәсьәләләр чишәбез, төрле программалар язабыз.
Алсу: Ә миңа нишләргә инде? Укытучыбыз өстәмә дәресләргә язылырга тәкъдим итте.
Айрат: Минемчә, сиңа укытучы янына барырга һәм аннан теманы кабат аңлатуын сорарга кирәк. Аның вакыты булмаса, мин сиңа ярдәм итеп карармын. Ләкин минем башкаларга дәрес биргәнем юк.
Алсу: Айрат, алайса ярдәм итче. Киләсе атнада контроль эш булачак, аңа кадәр теманы аңларга телим. Синең бүген вакытың бармы?
Айрат: Бүген мин дәресләрдән соң бассейнга барам. Аннан соң кайтачакмын. Иртәгә яки җомга көнне, берсекөнгә кич очраша алабыз.
Алсу: Миңа җомга көнне уңайлырак. Иртәгә минем бию түгәрәгенә барасым бар. Аннан кайткач арырмын, информатика материалын аңлый алмам.
Айрат: Яхшы, җомга көнне кичке биштә килермен.
Алсу: Рәхмәт сиңа. Син безнең адресны беләсеңме?
Айрат: Син нәрсә инде, Алсу! Без бит бер урамда торабыз. Әлбәттә, беләм.
Алсу: Шаярттым гына.
**[2 секунд пауза]**
**Прослушайте диалог второй раз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**

**Внесите ответы в бланк ответов.**

**ҖАВАПЛАР**

| Биремнең номеры | Дөрес җавап |
|---|---|
| 1 | 2 |
| 2 | 3 |
| 3 | 2 |
| 4 | 1 |
| 5 | 3 |
| 6 | 3 |
| 7 | 3 |
| 8 | 1 |
| 9 | 2 |
| 10 | 1 |
| 11 | 2 |
| 12 | 1 |
| 13 | 1 |
| 14 | 2 |
| 15 | 3 |
| 16 | 1 |
| 17 | 1 |
| 18 | 2 |
| 19 | 3 |
| 20 | 1 |
| 21 | 2 |
| 22 | 1 |
| 23 | 3 |
| 24 | 2 |
| 25 | 3 |
| 26 | 3 |
| 27 | 1 |
| 28 | 1 |

## 7 нче вариант

## Раздел 1

***Прослушайте 7 коротких диалогов. В заданиях 1 - 7 укажите правильный вариант ответа. Вы услышите аудиозапись дважды.***

**1** **Әнвәр белән Айсылуның абыйлары ничек танышлар?**
1) университетта бергә укыйлар
2) сыйныфташлар булганнар
3) физиканы яхшы белгәннәр

**2** **Раил китапханәдә нишли?**
1) реферат язарга әзерләнә
2) конкурска әзерләнә
3) әнисе янына килгән

**3** **Салих нишләргә тели?**
1) концерт карарга
2) репетицияне күрергә
3) секциягә барырга

**4** **Әнисә нишли?**
1) сеңелесен бакчадан ала
2) җиләкле йогурт ярата
3) ашамлыклар алырга бара

**5** **Алмаз ни өчен Айназга шалтыраткан?**
1) кинога чакырырга
2) чана шуарга чыгарга
3) өстәл уены уйнарга чакырырга

**6** **Марат кемнән бүләк көтә?**
1) әнисеннән
2) дусларыннан
3) Мәдинәдән

**7** **Булат дәрестән соң нишли?**
1) велосипедта йөри
2) сәяхәт итә
3) хоккей уйный

***Прослушайте разговор двух друзей. Определите, какие из приведенных утверждений 8 - 13 соответствуют содержанию текста (1), а какие – не соответствуют (2). Вы услышите аудиозапись дважды.***

**8** Самат дәрестән соң да мәктәптә калган.

1) текстка туры килә  2) текстка туры килми

**9** Самат шимбә көнне шахмат турнирында җиңәргә тели.

1) текстка туры килә  2) текстка туры килми

**10** Алсу кечкенә авкытта шахмат уйнаган.

1) текстка туры килә  2) текстка туры килми

**11** Самат белән Сәлим укучыларның уеннарын күзәтәчәкләр.

1) текстка туры килә  2) текстка туры килми

**12** “Сәйдәш” мәдәният үзәгендә республикакүләм бию конкурсы узачак.

1) текстка туры килә  2) текстка туры килми

**13** Алсу дусларын конкурса чакыра.

1) текстка туры килә  2) текстка туры килми

## Раздел 2

***Прочитайте тексты в заданиях 14 – 16. После каждого текста определите правильный вариант ответа.***

**14**

“Чәкчәк бәйрәме”нә чакырабыз!

Киләсе якшәмбедә, 15нче августта, шәһәрнең үзәк паркында беренче тапкыр “Чәкчәк” кулинария фестивале узачак. Бу көнне милли тәм-томнар пешерү буенча мастер-класслар һәм бәйгеләр, төрле халыклар ризыклары турында лекцияләр узачак. Барлык чараларда теләгән һәркем катнаша ала. Чараларда катнашу түләүсез, алдан теркәлү соралмый.

Бәйгеләрдә җиңүчеләрне һәм призёрларны оештыручылардан бүләкләр көтә.

Бәйрәм 12.00 сәгатьтә башлана.

Милли ризыкларны авыз итеп карау, чәй эчү дә каралган.

**Белдерүдә нәрсә турында әйтелә?**

1) Якшәмбе көнне шәһәр паркында уздырылачак чәй эчертү чарасы турында.

2) “Чәкчәк бәйрәме” үткәрелү һәм чарага чакыру турында.

3) Үзәк паркта җиңүчеләрне һәм призерларны котлау чарасы булуы турында.

| | | |
|---|---|---|
| **15** | “Сәйлән” яшьләр ансамбленә рәхим итегез!<br>25 нче сентябрьдән 25 нче октябрьгә кадәр мәдәният йортында эшләп килә торган “Сәйлән” яшьләр ансамбленә яңа состав җыела. Ансамбльгә 12-14 яшьтәге җыр, бию, нәфис сүз белән дус булган укучылар чакырыла. Ансамбльгә кабул ителү өчен, seylen@mail.ru адресына гариза һәм ирекле формада язылган үзең турында мәгълүмат җибәрергә кирәк. Шуннан соң укытучылар сезнең белән элемтәгә керәчәкләр. Ә 1 нче ноябрь көнне сәгать көндезге өчтә оештыру җыелышы булачак.<br>Белешмәләр өчен телефон: 231-18-28. | **Бу хәбәр нәрсә турында?**<br>1) Мәдәният йортында эшли торган ансамбльләр эшчәнлеге турында.<br>2) “Сәйлән” ансамбленә яңа состав туплау турында.<br>3) 12-14 яшьлек укучыларны биергә, җырларга, нәфис сүз сөйләргә өйрәтү турында. |
| **16** | Хәерле көн, Азат! Хәлләрең ничек? Каникулда ничек ял иттең?<br>Мин футбол төркемебез белән каникул вакытында Байкал күле янындагы лагерьда булдым. Лагерьда тренировкаларыбыз дәвам итте, ял итәргә дә өлгердек, матур табигатьне дә күзәттек. Төркемдә 28 кеше булсак та, 17 уенчы гына бара алды. Кызганыч, алар күп нәрсәләрне күрми калдылар, чөнки ял , чыннан да, искиткеч булды. Анда саф һава, матур табигать спорт белән шөгыльләнергә күп көч бирәләр.<br>Әгәр мөмкинлек булса, син дә Байкалга барырга тырыш. Үкенмәссең.<br>Син ял вакытында нәрсәләр белән шөгыльләндең? Планнарыңны тормышка ашыра алдыңмы? Миңа җавап яз, көтәм.<br>Сәлам белән дустың Алмаз. | **Электрон хатында Алмаз дустына нәрсә турында язган?**<br>1) Лагерьда ял итүе турында.<br>2) Байкал табигатенең матурлыгы турында.<br>3) Төркемнәрендәге уенчылар турында. |

***Прочитайте текст. В заданиях 17 - 20 укажите правильный вариант ответа.***

Безгә аклы-сарылы песи баласы кереп ияләште. Безнең үзебезнең бер песиебез бар иде инде. Ул песиебез үзе ап-ак, маңгаенда кара тап бар. Без аны матурлыгы өчен генә түгел, акыллылыгы өчен дә яратабыз. Ул, үзе бик шаян булса да, ашамлыкка тими, күршеләргә дә кереп йөрми.

Ә күршедән кергән песи бик тәртипсез булып чыкты. Бертуктаусыз «мияу-мияу» ди. Ашарга бирсәң, ризыкны төрле җиргә тарата башлый да идәнне

пычрата. Өстәлгә менеп, икмәк сыныкларын тартып төшерә. Тагын әллә нинди тәртипсезлекләр эшли.

Беркөнне минем белән уйнарга иптәш кызым Мәйсәрә керде. Ул:

— Бу юньсез песине нигә керттегез? Ул инде бик күп кешегә йөрде. Бездә дә булды. Аны бөтен кеше дә куып чыгарды. Ул акылсыз, сөйкемсез песи,— диде.

— Ә мин аны куып чыгармыйм, тәртипкә өйрәтәм,— дидем мин. Абыем Шамил дә:

— Әйдә, өйрәтеп карыйк, өйрәнми икән - үзенә үпкәләр,— диде.

Без абыем белән икәүләп песине өйрәтә башладык. Аңа ашарга да, йокларга да урын әзерләдек. Бер атнадан соң песи бөтенләй үзгәрде: матурланды, акыллыланды.

Хәзер Мәйсәрә песине үзенә алырга тели:

— Сезнең үз песиегез бар бит, бусын миңа бирегез әле,— ди. Без абыем белән көләбез.

— Юк инде, хәзер без аны беркемгә дә бирмибез,— дибез. Песи дә, сүзне аңлаган кебек, иркәләнеп койрыгын болгый башлый.

*(Ә. Бикчәнтәевадан)*

**17** Ап-ак маңгайлы песи үзен ничек тота?

1) Ул матур, ләкин тәртипсез.
2) Ул шаян, ләкин тәртипле.
3) Ул акылсыз һәм куркак.

**18** Мәйсәрә песине ни өчен яратмый?

1) Күп кешедә йөргәнгә.
2) Аклы-сарылы булганга.
3) Акылсыз, тәртипсез булганга.

**19** Шамил белән сеңелесе нишләргә уйлыйлар?

1) Песине тәртипкә өйрәтергә.
2) Песигә ашарга бирергә.
3) Песине куып чыгарырга.

**20** Аклы-сарылы песи бер атнадан соң нишли?

1) Тәртиплегә әйләнә.
2) Мәйсәрәләргә китә.
3) Тәртипсезләнүен дәвам итә.

## Раздел 3

***Прочитайте текст. В заданиях 21 – 28 определите правильный вариант ответа.***

Энҗе чәчәк һәм аның җимеше, женьшень, песи үләне һәм (21) … тамырлары - болар барысы да дару үләннәре. Бу исемлеккә сары һәм зәңгәр

мәтрүшкәне, кара бөтнекне, эт (22) …, ярмабашны һәм башка бик күп үләннәрне өстәргә мөмкин. Алар авыруларны (23) … булышалар.

Кара (24) … плантацияләрдә үстерәләр. Бөтнек маеның төп (25) … булган ментол, әлбәттә, теш пастасына хуш ис өсти.

Күргәнегез бардыр: энҗе чәчәк — урманда, песи үләне (26) … һәм дымсу болыннарда үсә. Ә менә сары мәтрүшкә, кызылбаш, ярмабаш, андыз болында (27) … үсәләр. Дару үләннәрен аяз көнне, чык кипкәч җыялар һәм күләгәдә (28) …

Энҗе чәчәк зур агачлар күләгәсендә, куе үлән арасында үсә. Аннан йөрәк авыруларын дәвалау өчен дару ясыйлар.

*(Вакытлы матбугаттан)*

**21** 1) алар 2) аларның 3) аларны

**22** 1) тигәнәген 2) тигәнәге 3) тигәнәгендә

**23** 1) булдырырга 2) җиңәргә 3) җиңелергә

**24** 1) җимешне 2) җиләкне 3) бөтнекне

**25** 1) өлеш 2) өлеше 3) өлешенә

**26** 1) аланнарда 2) аланнарга 3) аланнардан

**27** 1) гына 2) ук 3) бит

**28** 1) куялар 2) җәяләр 3) киптерәләр

## Раздел 4

***В заданиях 29-32 необходимо написать реплики в соответствии с заданной речевой ситуацией.***

**Сөйләм ситуациясенә туры килгән репликаларны языгыз.**

**29** Сообщите одноклассникам, что сегодня последнего урока не будет, и вы с классом поедете на экскурсию.

**30** Спросите у друга (подруги), какого цвета одежда нравится ему (ей) больше всего и почему.

**31** Предложите подруге сходить в воскресенье в цирк и взять с собой младших братьев.

**32** Посоветуйте дяде и тете посетить выставку молодых татарстанских художников, где имеются и ваши работы.

**33** **Вы получили письмо от друга (подруги). Напишите ему (ей) письмо объемом не менее 60 слов, ответив на его (её) вопросы.**
**Для ответа на это задание используйте специальный бланк ответов.**

| |
|---|
| *... Безнең мәктәптә очрашулар еш була. Соңгы тапкыр без танылган язучы Равил Фәйзуллин белән очраштык. Равил абый безгә яңа шигырьләрен укыды, ә без аның шигырьләрен сөйләдек, шигырьләренә язылган җырлар җырладык. Мин Равил абыйдан автограф та алдым.*<br><br>*... Ә сезнең мәктәптә нинди чаралар үткәрелә? ... Бу чараларда син ничек катнашасың? ... Тагын нинди чара булуын теләр идең?* |

## Тыңлап аңлау биремнәре өчен текстлар

**Прослушайте 7 коротких диалогов. В заданиях 1 - 7 укажите правильный вариант ответа. Вы услышите аудиозапись дважды.**
**Беренче сорау. Әнвәр белән Айсылуның абыйлары ничек танышлар?**

Айсылу: Әнвәр, синең туганың кайда укый? Ул табиб булачакмы?

Әнвәр: Ул Казанда медуниверситетта укый, Айсылу. Әйе, ул балалар табибы булачак. Ә син аны каян беләсең?

Алсу: Абыең минем абый белән бер сыйныфта укыган. Ул әйтте.

Әнвәр: Ә синең абыең хәзер кайда укый, Айсылу?

Айсылу: Абыем энергетика университетында укый. Ул технолог булачак.

Әнвәр: Минемчә, сиңа да энергетика белән бәйле гамәлләр ошый. Шулаймы?

Алсу: Юк, ни өчен алай уйлыйсың?

Әнвәр: Син физика дәресендә һәрвакыт бик теләп тәҗрибәләрдә катнашасың. Аларны һәрвакыт әйбәт аңлатасың.

Алсу: Әйе, физиканы мин яхшы беләм, аңлыйм. Ләкин минем табибә буласым килә.

Әнвәр: Минемчә, синнән бик яхшы физика укытучысы чыгар иде.

Алсу: Рәхмәт, Әнвәр.

**[2 секунд пауза]**
**Прослушайте диалог второй раз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**

**Икенче сорау. Раил китапханәдә нишли?**

Раил: Раилә, син якшәмбе көнне дә китапханәдә нишлисең?

Раилә: Сәлам, Раил. Миңа Әмирхан Еники турында материаллар кирәк. Реферат язам. Ә син нинди китапка килдең?

Раил: Мин китапка килмәдем. Монда әнием эшли. Бүген өй ачкычын онытып калдырган. Аңа ачкыч кертергә килдем. Без хәзер әтием белән авылга китәбез. Әниемнең бүген эш көне.

Раилә: Ә мин дүшәмбегә әдәбияттан реферат язарга тиеш. Минем әти-әнием дә авылга киттеләр. Эшем булгач, мин бара алмадым.

Раил: Ни өчен кичә әзерләмәдең?

Раилә: Кичә мин конкурста идем, соң кайттым.

Раил: Ярый алайса, уңышлар сиңа, Раилә!

Раилә: Рәхмәт! Хәерле юллар!

**[2 секунд пауза]**

**Прослушайте диалог второй раз.**

[язма икенче тапкыр яңгырый] **[2 секунд пауза]**

**Өченче сорау. Салих нишләргә тели?**

Салих: Әминә, син бу дәрестән соң кая барасың?

Әминә: Салих, миңа дәрестән соң актлар залына барырга кирәк. Иртәгә концерт була. Без анда катнашабыз.

Салих: Син биисеңме, Әминә?

Әминә: Юк, без спектакльдән өзек күрсәтәбез. Мин Мәйсәрә ролендә уйныйм, җырлыйм.

Салих: Минем сәгать өчкә кадәр ярты сәгать вакытым бар. Аннары секциягә китәм. Репетициягезне карасам ярыймы?

Әминә: Әйдә, киттек, алайса. Чыгыш турында тәнкыйди фикереңне әйтерсең.

Салих: Мин риза, Әминә!

**[2 секунд пауза]**

**Диалогны икенче тапкыр тыңлагыз.**

[язма икенче тапкыр яңгырый]

**[2 секунд пауза]**

**Дүртенче сорау. Әнисә нишли?**

Әмир: Әнисә, сәлам! Син кая ашыгасың?

Әнисә: Сәлам, Әмир! Кибеткә барам. Ашамлыклар аласы бар, аннары сеңелемне дә бакчадан алырга кирәк.

Әмир: Мин дә балалар бакчасыннан сеңелемне алырга барам. Әйдә, мин аларның икесен дә алып чыгам. Аннары ашамлыклар кибете янында очрашабыз.

Әнисә: Бик яхшы булыр иде, Әмир! Рәхмәт сиңа. Сезгә сөт алырга кирәкмиме?

Әмир: Юк, сөт кирәкми, сеңелемә кечкенә йогурт алчы. Мин аңа вәгъдә иткән идем.

Әнисә: Бананлынымы яки җиләкленеме? Безнең Әминә җиләклене ярата.
Әмир: Гөлсем дә җиләклене ярата.
Әнисә: Яхшы, хәзер икесенә дә алам.

**[2 секунд пауза]**
**Прослушайте диалог второй раз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**

**Бишенче сорау. Алмаз ни өчен Айназга шалтыраткан?**

Алмаз: Айназ, син кышкы каникулда кайда ял иттең? Телефоның эшләмәде.

Айназ: Алмаз, син шалтыраттыңмыни? Без авылда идек. Телефоным ватылды, эшләмәде.

Алмаз: Әйе, сине киногa чакырырга шалтыраткан идем. Без сыйныфташлар белән яңа фильм карарга бардык. Син авылда нишләдең? Телефон булмагач, күңелсез булгандыр инде.

Айназ: Бик кызык булды. Бөтен туганнар җыелган иде. Без тауга бардык, чана шудык, хоккей карадык. Аннары мичтә пешкән коймак белән чәй эчтек. 3 көн буе аралашгтык. Мин телефон турында уйлап та карамадым.

Алмаз: Кызык, ә кичен нишләдегез?

Айназ: Фотолар карадык. Дәү әнием үзенең балачагы турында сөйләде. Аннары өстәл уеннары уйнадык.

Алмаз: Телефонсыз да көннәр күңелле үтә аламыни?

Айназ: Әлбәттә!

**[2 секунд пауза]**
**Диалогны икенче тапкыр тыңлагыз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**

**Алтынчы сорау. Марат кемнән бүләк көтә?**

Марат: Мәдинә, син бәйрәмгә туганнарыңа нинди бүләкләр әзерләдең?

Мәдинә: Открыткалар яздым, фото кую өчен рамкалар ясадым.

Ә син нәрсәләр бүләк итәргә уйлыйсың, Марат?

Марат: Мин дусларыма китаплар, өстәл уеннары бүләк итәргә телим, ә әби белән бабайга фотоальбом бирермен. Алар альбом карарга яраталар. Әниемә яулык, әтиемә каеш алырга телим.

Мәдинә: Мин дә әнигә бисердан беләзек ясадым. Ләкин ул аңа ошармы, юкмы, белмим.

Марат: Ошар, әлбәттә, Мәдинә. Сәлимә апага син ясаган һәрнәрсә ошый инде. Ул – бик нечкә күңелле кеше.

Мәдинә: Әйе, әнием шундый. Ә син нинди бүләк алырга теләр идең, Марат?

Марат: Мин әниемнең бәлешен ашарга телим. Ул аны шундый тәмле пешерә!

Мәдинә: Бәйрәм бәлеше һәрвакыт тәмле була инде.

**[2 секунд пауза]**
**Прослушайте диалог второй раз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**

**Җиденче сорау. Булат дәрестән соң нишли?**

Булат: Бану, син буш вакытта нишләргә яратасың?

Бану: Дус кызларым белән аралашырга, рәсем ясарга һәм биергә яратам. Рәсем ясаганда, мин хыялланам. Ә син нишләргә яратасың, Булат?

Булат: Мин велосипедта йөрергә, хоккей, волейбол уйнарга яратам. Җәен сәяхәт итәм.

Бану: Син кемнәр белән хоккей уйныйсың? Командагыз бармы?

Булат: Сыйныфташ малайлар белән уйныйбыз. Командабыз бар, ләкин тренерыбыз юк.

Бану: Ә сез кайда хоккей уныйсыз?

Булат: Мәктәп ишегалдында. Кышын анда бик уңайлы. Дәрестән соң шунда калабыз.

Бану: Сезне карарга килергә ярыймы?

Булат: Ярый.

**[2 секунд пауза]**
**Прослушайте диалог второй раз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**

***Прослушайте разговор двух друзей. Определите, какие из приведенных утверждений 8 - 13 соответствуют содержанию текста, а какие – не соответствуют. Вы услышите аудиозапись дважды.***

**[пауза 20 секунд]**

Самат: Исәнме, Алсу!

Алсу: Сәлам, Самат! Син һаман мәктәптәмени әле? Дәресләр күптән бетте бит инде.

Самат: Соң үзең дә мәктәптә йөрисең бит. Кайтмагансың.

Алсу: Мин бию түгәрәгендә идем. Шимбә көнне конкурска барабыз, шуңа күрә һәр көнне репетицияләргә йөрибез. Өйгә кайтып өлгерә алмыйм, дәресләрдән соң ук бию кабатларга калам.

Самат: Мин дә шахмат түгәрәгендә идем. Башлангыч сыйныф укучылары өчен иртәгә мәктәп турниры була. Мине һәм Сәлимне судья итеп куйдылар. Без шул чарага әзерләндек.

Алсу: Турнирда безнең мәктәп укучылары гына катнашачакмы?

Самат: Юк, күрше мәктәптән дә укучылар киләчәкләр. 8-10 команда булыр дип көтәбез.

Алсу: Мәктәбебездә шахмат түгәрәгенә йөрүче укучылар күпме, Самат?

Самат: Әйе. Укучылар бик теләп йөриләр. Шахмат башны эшләтә, фикерләү сәләтен арттыра бит.

Алсу: Килешәм. Башлангыч сыйныфта укыганда, мин дә бу түгәрәккә йөрдем. Хәзер сеңелем белән ял вакытларында шахмат уйныйбыз. Кызык спорт төре.

Самат: Алсу, ә сез нинди конкурска әзерләнәсез? Ул кайда булачак?

Алсу: Шимбә көнне Казанның “Сәйдәш” мәдәни үзәгендә татар биюләре конкурсы узачак. Бу- республика күләмендә үткәрелә торган конкурс. Без шуңа әзерләнәбез.

Самат: Җиңәчәксезме соң?

Алсу: Җиңүче яки призер булырга телибез. Моның өчен һәр көн биюебезне кабатлыйбыз бит инде.

Самат: Тырышкач булыр. Уңышлар сезгә!

Алсу: Сез дә шахмат турнирын яхшы үткәрегез.

Самат: Рәхмәт!

**[2 секунд пауза]**

**Прослушайте диалог второй раз.**

[язма икенче тапкыр яңгырый]

**[2 секунд пауза]**

**Внесите ответы в бланк ответов.**

## ҖАВАПЛАР

| Биремнең номеры | Дөрес җавап |
|---|---|
| 1 | 2 |
| 2 | 3 |
| 3 | 2 |
| 4 | 3 |
| 5 | 1 |
| 6 | 1 |
| 7 | 3 |
| 8 | 1 |
| 9 | 2 |
| 10 | 1 |
| 11 | 1 |
| 12 | 1 |
| 13 | 2 |
| 14 | 2 |

| | |
|---|---|
| 15 | 2 |
| 16 | 1 |
| 17 | 2 |
| 18 | 3 |
| 19 | 1 |
| 20 | 1 |
| 21 | 2 |
| 22 | 1 |
| 23 | 2 |
| 24 | 3 |
| 25 | 2 |
| 26 | 1 |
| 27 | 1 |
| 28 | 3 |

## 8 нче вариант

### Раздел 1

***Прослушайте 7 коротких диалогов. В заданиях 1 - 7 укажите правильный вариант ответа. Вы услышите аудиозапись дважды.***

**1** **Әнвәр бакчада нишли?**

1) чәчәкләр үстерә
2) җир казый, су сибә
3) чүп утый, су сибә

**2** **Сәрвәр белән Саматның авылларында нинди охшашлык бар?**

1) анда чишмә, елга, урман бар
2) анда чишмә, елга, күлләр бар
3) анда чишмә, күл, урман бар

**3** **Ирек кем булырга хыяллана?**

1) тренер
2) футболчы
3) хоккейчы

**4** **Айсылу кайдан сөйләшә?**

1) башка шәһәрдән
2) цирктан
3) өеннән

**5** **Диләрә Айратны ничек шаккатырган?**

1) соравы белән
2) мавыгуы белән
3) сөйләме белән

**6** **Кәримне нәрсә кызыксындыра?**

1) Әнисәнең кем белән баруы
2) хайваннарның төрләре
3) хайваннарның үз-үзләрен тотышлары

**7** **Әсмага сәяхәттә аеруча нәрсә ошаган?**

1) ачыла торган күперләр
2) Аврора крейсеры
3) танылган рәссамнарның эшләре

***Прослушайте разговор двух друзей. Определите, какие из приведенных утверждений 8 - 13 соответствуют содержанию текста (1), а какие – не соответствуют (2). Вы услышите аудиозапись дважды.***

**8** Танышлар мәктәптәге хәлләре турында сөйләшәләр.
1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**9** Саматның бик талантлы сыйныфташы бар.
1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**10** Саматның дусты конкурста катнашачак.
1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**11** Марат үзлегеннән уен коралларында уйнарга өйрәнгән.
1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**12** Конкурста халык җырларын гына башкарырга ярый.
1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**13** Мәдинә кичен конкурс нәтиҗәләрен хәбәр итүне сорый.
1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

## Раздел 2

***Прочитайте тексты в заданиях 14 – 16. После каждого текста определите правильный вариант ответа.***

**14**

Хөрмәтле авылдашлар!
Сезне 28 нче декабрь көнне авылыбыз Мәдәният сараенда узачак Кыш бабай һәм Кар кызын каршы алу чарасына чакырабыз. Чара Мәдәният сарае каршындагы мәйданда узачак. Чарага барлык авыл халкын көтеп калабыз. Кыш бабай һәм Кар кызына шигырьләр сөйләргә, җырлар җырларга, һөнәрләрегезне күрсәтергә әзерләнеп килегез. Чарада лотерея да уйнатылачак.
Чара ачык һавада үткәрелү сәбәпле, җылы киенергә онытмагыз.
Кыш бабай һәм Кар кызы безнең авылга 19.00 сәгатькә килеп җитәчәкләр.

**Белдерүдә нәрсә турында әйтелә?**
1) Мәдәният сараенда үтәчәк лотерея уйнату турында.
2) Кыш бабайга сөйләр өчен шигырьләр, җырлар өйрәнә тору хакында.
3) Авыл Мәдәният сараенда узачак Яңа ел чарасы турында.

**15**

Бию осталары бәйгесенә рәхим итегез!
Ноябрь аенда мәктәбебездә биючеләр бәйгесе үтәчәк. Анда 4 – 9 нчы сыйныф укучылары катнаша ала. Бәйге ике номинациядә үтә. 1 нче

**Бу хәбәр нәрсә турында?**

| | |
|---|---|
| номинация – күмәк бию; 2 нче номинация – ялгыз бию. Гаризалар 10 нчы октябрьгә кадәр кабул ителә. Чараның йомгаклау этабы 24 нче ноябрьдә “Көзге бал”да узачак. Анда җиңүчеләр билгеле булачак һәм аларга истәлекле бүләкләр тапшырылачак. Бәйгенең шартлары белән мәктәп сайтында танышырга була.<br>Белешмәләр өчен: 231-18-28. | 1) Мәктәп этабында җиңүчеләрне бүләкләү турында.<br>2) Яшь биючеләр бәйгесенең нәтиҗәләре турында.<br>3) Яшь биючеләр арасында үткәреләчәк бәйге турында. |

| | | |
|---|---|---|
| **16** | Хәерле көн, Әминә! Хәлләрең ничек? Ялларың ничек үтте?<br>Мин бу ялларда зоопаркта булдым. Әле Казанның яңа зоопаркында булганым юк иде. Анда бик матур һәм кызык икән. Бу зоопарк бик чиста, урын күп. Хайваннарга да анда бик уңайлыдыр дип уйлыйм. Без зоопаркка энем белән бардык, аның маймыллар күрәсе килгән иде. Ул рәсем ясарга ярата бит. Сәнгать мәктәбендә аңа маймыл рәсеме ясарга кушканнар. Зоопаркта без бик күп төрле маймылларны күрдек. Энем эскизлар ясады. Аңа бик ошады.<br>Синең бу зоопаркта булганың бармы? Барырга киңәш итәм. Миңа хәбәр бир. Көтәм. Сәлам белән дустың Камилә. | **Электрон хатында Камилә дустына нәрсә турында язган?**<br>1) Ял көнен энесе белән үткәрүе турында.<br>2) Энесенә сәнгать мәктәбендә өй эше бирүләре турында.<br>3) Энесенең хайваннар эскизларын ясарга яратуы турында. |

***Прочитайте текст. В заданиях 17 - 20 укажите правильный вариант ответа.***

Борын-борын заманда гүзәл Чулман елгасының чал Иделгә койган җирендә Болгар дәүләте булган. Халкы гаҗәеп эшчән, туфрагы уңдырышлы икән. Монда күп итеп терлек асраганнар, мул итеп иген иккәннәр, күннән әйберләр теккәннәр, балчыктан савыт-саба ясаганнар. Болгар осталарының даны бөтен дөньяга таралган. Кызлары - бик чибәр, егетләре батыр булган. Болгар дәүләтенең матурлыгын мактап, көн-төн кошлар сайраган. Ул заманда барлык агачлар да ямь-яшел яфрак ярып утырганнар.

Көннәрдән бер көнне шушы тыныч, имин Болгар дәүләтенә кара яу килгән. Баһадир ирләр яуга күтәрелгәннәр. Җәнлекләр качып киткәннәр. Ләкин зифа каеннар, горур наратлар торып калганнар. Кызларныкыдай нечкә күңелләре сызланудан каеннар яфракларын койганнар. Егетләрдәй төз чыршы-наратлар кайгыларын эчкә йотканнар, һәм аларның яфраклары урынына энәләр барлыкка килгән. Шуннан башлап яфраклы агачлар һәр көз саен яфракларын коя, ә чыршы-наратлар, сабырлыкларын саклап, горур тора бирәләр, имеш.

(Балалар фольклорыннан)

**17** Болгар дәүләте кайда урнашкан булган?
1) Идел елгасы буенда.
2) Чулман елгасы буенда.
3) Хәзерге Казан шәһәре урынында.

**18** Болгарда нинди һөнәрчеләр булган?
1) игенчеләр, терлекчеләр, күнчеләр
2) игенчеләр, тегүчеләр, алтын коючылар
3) җиһаз ясаучылар, йорт салучылар.

**19** Көннәрдән бер көнне нәрсә булган?
1) Сугыш башланган.
2) Көз җиткән.
3) Чит дәүләтләргә күчеш башланган.

**20** Чыршыларда энәләр барлыкка килү нәрсәдән булган?
1) Кайгыдан, яфраклары коелудан.
2) Сугышка каршы энәләр әзерләүдән.
3) Кайгыларын эчкә йотып, сабыр булудан.

## Раздел 3

***Прочитайте текст. В заданиях 21 – 28 определите правильный вариант ответа.***

Син дөньяда үзеңнең иң ышанычлы һәм иң якын (21) ... беләсеңме? Алар — синең әниең һәм әтиең. Алар һәрвакыт (22) ... янында: бәйрәмнәрдә дә, иң авыр минутларда да. Алар һәрчак сине якларлар, сакларга тырышырлар, (23) ... ташламаслар.

Әниең көне буена күпме эш эшләргә өлгерә: (24) ... аш әзерләргә, табын җыештырырга, балаларны мәктәпкә, бакчага озатырга. Ул үзе дә эшендә ничә сәгать эшләп кайта бит әле. Ләкин (25) ... барырга да, кичке аш пешерергә дә, синең белән китап укырга да, энең белән уйнарга һәм юындырып яткырырга да өлгерә. Аннан соң кер юарга, тегәргә, бәйләргә һәм тагын бик күп эшләр (26)... вакыт таба.

Әлбәттә, әтиең һәм сез булмасагыз, бу эшләрне үзенә генә эшләргә әниеңә бик авыр булыр иде. Шуңа күрә мөмкин булган кадәр, аңа булышырга, әниеңнең (27) ... киметергә тырышырга кирәк. Ул да ял итсен, күңел ачарга вакыты булсын.

Әниең һәм әтиең сезне бик яраталар. Шуңа күрә син дә аларны хөрмәт итәргә һәм беркайчан да аларга (28) ... китермәскә тиеш. Үскәч тә, әти-әни һәрчак баласы турында кайгырта, син дә аларны онытма.

(Л. ВасильеваТангнустан )

**21** 1) дусларың 2) дусларыңны 3) дусларыңның

**22** 1) син 2) сиңа 3) синең

**23** 1) файдаларыннан 2) булышудан 3) ярдәмнәреннән

**24** 1) иртә 2) иртәнге 3) иртәгә

**25** 1) кибеттә 2) кибеттән 3) кибеткә

**26** 1) эшләргә 2) эшләп 3) эшләгәч

**27** 1) эшләр 2) эшләре 3) эшләрен

**28** 1) күңелсезлек 2) тәртипсезлек 3) файдасызлык

## Раздел 4

***В заданиях 29-32 необходимо написать реплики в соответствии с заданной речевой ситуацией.***

**Сөйләм ситуациясенә туры килгән репликаларны языгыз.**

**29** Сообщите одноклассникам, что на следующей неделе у вас день рождения и вы всех приглашаете к себе на праздник.

**30** Спросите у друга (подруги), во сколько начнется конкурс молодых талантов и будет ли он(а) там выступать.

**31** Предложите старшей сестре сходить в магазин и купить вам новые белые кеды для физкультуры.

**32** Посоветуйте своим родным посетить татарский театр и посмотреть премьеру нового спектакля.

**33** **Вы получили письмо от друга (подруги). Напишите ему (ей) письмо объемом не менее 60 слов, ответив на его (её) вопросы.**
**Для ответа на это задание используйте специальный бланк ответов.**

*... Быел без җәйне бакчада үткәрдек. Мин әбием белән җиләк-җимешләр үстердем, аларга су сиптем, чүпләрен утадым. Әбием белән болынга барып, җиләк һәм мәтрүшкә дә җыйдым. Әбием мине дару үләннәре җыярга да өйрәтте. Кичләрен без җиләкле чәй эчеп, телевизор карый идек.*

*... Ә син җәйге ял вакытында кайда булдың? ... Җәй көне нинди яңа һөнәрләрә өйрәндең? ... Җәйге кичләрдә син нишли идең?*

**Тыңлап аңлау биремнәре өчен текстлар**

**Прослушайте 7 коротких диалогов. В заданиях 1 - 7 укажите правильный вариант ответа. Вы услышите аудиозапись дважды.**

**Беренче сорау. Әнвәр бакчада нишли?**

Әнвәр: Әминә, сезнең бакчагыз бармы?

Әминә: Әйе, Әнвәр, Идел буенда бик матур бакчабыз бар.

Әнвәр: Безнең бакча зур түгел, ләкин анда кыяр да, помидор да, кишер дә, чөгендер дә, кабак та үсә. Әнием бик күп чәчәкләр дә үстерә.

Әминә: Безнең бакчада да күп яшелчәләр үсә. Кыяр, помидор, кишер, чөгендер бар. Борчак һәм баклажан да үстерәбез.

Әнвәр: Син бакчада нишлисең?

Әминә: Яшелчәләр утыртырга булышам, су сибәм, чүп утыйм. Ә син нишлисең?

Әнвәр: Җир казыйм, су сибәм. Мин чүп утарга яратмыйм.

Әминә: Ә яшелчәләр ашарга яратасыңмы?

Әнвәр: Әлбәттә! Алар файдалы бит

**[2 секунд пауза]**

**Прослушайте диалог второй раз.**

[язма икенче тапкыр яңгырый]

**[2 секунд пауза]**

**Икенче сорау. Сәрвәр белән Саматның авылларында нинди охшашлык бар?**

Самат: Сәрвәр, син авылны яратасыңмы?

Сәрвәр: Әлбәттә, Самат. Әбием белән бабам, туганнарым авылда яшиләр. Без авылга кайтырга яратабыз. Ә син кайда яшисең?

Самат: Мин – авыл егете. Авылыбыз зур һәм матур. Сәрвәр, ә сезнең авылда чишмә бармы?

Сәрвәр: Әйе, ике чишмә, елга, таулар һәм урман бар.

Самат: Ә безнең авылда бер чишмә, елга, ике күл бар. Авылның бер ягында куе ылыслы урман да бар.

Сәрвәр: Син елгада су коенасыңмы, әллә күлдәме?

Самат: Елга тирән түгел. Без анда балык тотабыз. Күлдә су коенабыз. Сәрвәр, ә син җиләк җыярга яратасыңмы?

Сәрвәр: Әйе, бакчада җиләк җыям.

**[2 секунд пауза]**

**Прослушайте диалог второй раз.**

[язма икенче тапкыр яңгырый] **[2 секунд пауза]**

**Өченче сорау. Ирек кем булырга хыяллана?**

Ирек: Иркә, син җәйге ялга лагерьга барасыңмы?

Иркә: Юк, Ирек, быел лагерьга бармыйм. Әбием һәм бабам янында авылда булам. Ә син нишләячәксең?

Ирек: Мин бер айга спорт лагерена барам. Анда тренировкаларыбыз булачак. Безгә яңа тренер килде.

Иркә: Ирек, ә син нинди спорт белән шөгыльләнәсең? Футбол уйныйсыңмы?

Ирек: Футбол да уйныйм, ләкин хоккейны күбрәк яратам. Хоккейчы булырга телим.

Иркә: Син лагерьда хоккей уйнаячаксыңмы?

Ирек: Юк, анда төрле күнегүләр ясыйбыз. Йөгерәбез, сикерәбез, су коенабыз. Без спорт лагеренда ял да итәбез, спорт белән дә шөгыльләнәбез.

Иркә: Кызык! Ә мин су коенырга, кояшта кызынырга телим.

Ирек: Уңышлар сиңа! Теләкләрең чынга ашсын!

Иркә: Рәхмәт!

**[2 секунд пауза]**

**Диалогны икенче тапкыр тыңлагыз.**

[язма икенче тапкыр яңгырый]

**[2 секунд пауза]**

**Дүртенче сорау. Айсылу кайдан сөйләшә?**

Илһам: Сәлам, Айсылу! Син өйдәме?

Айсылу: Сәлам, Илһам. Юк, өйдә түгел. Мин Минзәләдә.

Илһам: Анда нишлисең?

Айсылу: Бу шәһәрдә туганнарыбыз яши. Апаларга әтием һәм әнием белән кунакка килдек, хәзер чәй эчәбез. Иртәгә кайтабыз. Син нишлисең?

Илһам: Энем белән циркка килдек. Хәзер антракт вакыты. Энем туңдырма ашый. Мин синең белән сөйләшәм.

Айсылу: Тамаша кызыкмы? Минем дә барасым килгән иде.

Илһам: Әйе, бик кызык. Хайваннар күп, артистлар авыр күнегүләр ясыйлар. Миңа ошый.

Айсылу: Шәһәргә кайткач, без дә барабыз алайса.

**[2 секунд пауза]**

**Прослушайте диалог второй раз.**

[язма икенче тапкыр яңгырый]

**[2 секунд пауза]**

**Бишенче сорау. Диләрә Айратны ничек шаккатырган?**

Диләрә: Айрат, син балык тотарга яратасыңмы?

Айрат: Артык исем китми, ләкин бабай һәм әти белән җәен күлдә балык тотарга барам.

Диләрә: Ничек инде, Айрат?! Балык тоту шулкадәр кызык бит ул. Ул кешене табигатькә якынайта, тынычландыра. Балык тотканда, нинди генә хыялга бирелмисең...

Айрат: Диләрә, син балык тотасыңмы әллә?

Диләрә:  Әйе, мин әтием белән һәрвакыт балык тотарга йөрим. Ул мине өйрәтте. Без җәен дә, кышын да ял көннәрендә балык тотабыз. Бу атнада миңа 4 чабак һәм бер кызылканат эләкте.

Айрат: Мин балык тотарга яратучы кыз кешене беренче тапкыр күрәм. Афәрин!

Диләрә: Рәхмәт! Ләкин бу - бик кызык  шөгыль.

**[2 секунд пауза]**

**Диалогны икенче тапкыр тыңлагыз.**

[язма икенче тапкыр яңгырый]

**[2 секунд пауза]**

**Алтынчы сорау.   Кәримне нәрсә кызыксындыра?**

Әнисә: Кәрим, мин шимбә көнне сеңелләрем белән зоопаркта булдым. Миңа Казан зоопаркы бик ошады. Синең булганың бармы?

Кәрим: Әнисә**,** яңа зоопарктамы? Ул кайда урнашкан? Минем ишеткәнем бар, ләкин булганым юк.

Әнисә: Зоопарк Кабан күле янында. Бу зоопарк зур һәм чиста. Ул бөтенләй башкача төзелгән. Иске зоопарк кечкенә һәм пычрак иде.

Кәрим: Зоопаркта хайваннар күпме? Безнең яклар өчен сирәк хайваннар бармы?

Әнисә: Арысланнар, филләр, маймыллар, аюлар, төлкеләр. Алар зур читлекләрдә яшиләр. Аларны карыйлар, ашаталар.

Кәрим: Алар нәрсәләр ашыйлар икән?

Әнисә: Витаминнар һәм файдалы ризыклыар.

**[2 секунд пауза]**

**Прослушайте диалог второй раз.**

[язма икенче тапкыр яңгырый]

**[2 секунд пауза]**

**Җиденче сорау.  Әсмага сәяхәттә аеруча нәрсә ошаган?**

Әсма: Әмир, сториста минем  яңа фотоларны күрдеңме?

Әмир: Әйе, күрдем, Әсма. Сез кайда булдыгыз?

Әсма: Кышкы каникул вакытында без гаиләбез белән бер атна Петербургта булдык.

Әмир: Шәп! Шәһәр ошадымы?

Әсма: Шәһәр бик матур. Без бик күп  музейларда булдык. Аврораны күрдек, иске шәһәр буенча сәяхәт иттек, ачыла торган күперләрне күзәттек.

Әмир: Сез отельдә яшәдегезме? Экскурсияләргә ничек йөрдегез?

Әсма: Петербургта әтиемнең дусты яши.  Без Әнвәр абыйларда тордык. Ул безнең экскурсоводыбыз булды, һәр җиргә  үзе алып барды.

Әмир: Бик яхшы булган.  Иң ошаганы нәрсә булды?

Әсма: Эрмитаж. Рәссамнарның картиналарын карадым, талантларына таң калдым.

Әмир: Барлык истәлекле урыннарны да карарга өлгерденңме соң?

Әсма: Аларны карап бетерергә бер айлык сәяхәт тә җитмәс, Әмир.

**[2 секунд пауза]**

**Прослушайте диалог второй раз.**

[язма икенче тапкыр яңгырый]

**[2 секунд пауза]**

***Прослушайте разговор двух друзей. Определите, какие из приведенных утверждений 8 - 13 соответствуют содержанию текста, а какие – не соответствуют. Вы услышите аудиозапись дважды.***

**[пауза 20 секунд]**

Самир: Мәдинә, хәерле көн!

Мәдинә: Исәнме, Самир! Син кая җыендың? Кемне көтәсең?

Самир: Без сыйныфташым Марат белән Казан федераль университетына барабыз. Бүген Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтында "Милли хәзинә" конкурсының йомгаклау этабы үтә.

Мәдинә: Шулаймы? Сез анда катнашасызмы?

Самир: Марат катнаша, ә мин җанатар буларак барам.

Мәдинә: Марат концертта җырлыймы яки бииме?

Самир: Ул төрле уен коралларында уйный. Тамашачыларга һәм жюрига татар халык җырларыннан попурри тәкъдим итәчәк.

Мәдинә: Ул ансамбльгә йөриме? Музыка мәктәбендә укыймы?

Самир: Әйе, ул "Сорнай" ансабленә йөри. Ләкин конкурста үзе генә катнаша. Марат – бик оста музыкант.

Мәдинә: Самир, бу конкурста татар халык әсәрләре белән генә катнашып буламы?

Самир: Юк, төрле жанрдагы чыгышлар белән үзеңне күрсәтергә була. Анда эстрада һәм халык җырлары да, бию дә, нәфис сүз дә ярый. Һәркем үзенең талантын күрсәтә ала.

Мәдинә: Бик кызык. Уңышлар сезгә! Җиңеп кайтыгыз.

Самир: Рәхмәт, Мәдинә!

Мәдинә: Кичен нәтиҗәләрне шалтыратып әйтерсең, Самир!

Самир: Ярар, шалтыратырмын.

**[2 секунд пауза]**

**Прослушайте диалог второй раз.**

[язма икенче тапкыр яңгырый]

**[2 секунд пауза]**

**Внесите ответы в бланк ответов.**

# ҖАВАПЛАР

| Биремнең номеры | Дөрес җавап |
|---|---|
| 1 | 2 |
| 2 | 3 |
| 3 | 2 |
| 4 | 1 |
| 5 | 3 |
| 6 | 3 |
| 7 | 3 |
| 8 | 1 |
| 9 | 2 |
| 10 | 1 |
| 11 | 2 |
| 12 | 1 |
| 13 | 1 |
| 14 | 2 |
| 15 | 3 |
| 16 | 1 |
| 17 | 1 |
| 18 | 2 |
| 19 | 3 |
| 20 | 1 |
| 21 | 2 |
| 22 | 1 |
| 23 | 3 |
| 24 | 2 |
| 25 | 3 |
| 26 | 3 |
| 27 | 1 |
| 28 | 1 |

## 9 нчы вариант

## Раздел 1

***Прослушайте 7 коротких диалогов. В заданиях 1 - 7 укажите правильный вариант ответа. Вы услышите аудиозапись дважды.***

**1** **Әлфия нәрсәгә ышанган?**
1) аяз күккә
2) радио хәбәрчеләренә
3) атналык һава торышы күзәтүенә

**2** **Наилнең ни өчен буш вакыты юк?**
1) күп укыганга
2) һәркөн шөгыльләнгәнгә
3) һәрвакыт кино караганга

**3** **Рәшит  нәрсә белән мавыга?**
1) көй яздыру белән
2) компьютер программалары белән
3) яңа фильмнар белән

**4** **Дуслар кая барырга булалар?**
1) велосипед алырга
2) икенче йортка
3) паркка

**5** **Сәлимә ни өчен мультфильмны кунак бүлмәсендә карамый?**
1) анда "Яңалыклар" карыйлар
2) анда өй эшләре эшлиләр
3) анда сериал карыйлар

**6** **Рамил нәрсә сорый?**
1) түбәтәй
2) кибет адресы
3) бүләк иясен

**7** **Айрат бабасыннан нәрсәгә өйрәнгән?**
1) су сибәргә
2) агачларны танырга
3) дуслар табарга

***Прослушайте разговор двух друзей. Определите, какие из приведенных утверждений 8 - 13 соответствуют содержанию текста (1), а какие – не соответствуют (2). Вы услышите аудиозапись дважды.***

**8** Салаватның хәле начар булган.

1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**9** Әнисе табиб чакырткан.

1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**10** Табиб үләннәр генә эчәргә кушкан.

1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**11** Миләүшә Салаватка сакланырга кушкан.

1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**12** Салават укытучыдан яңа темаларны сораган.

1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**13** Миләүшә белән Салават төрле йортларда яшиләр.

1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

## Раздел 2

***Прочитайте тексты в заданиях 14 – 16. После каждого текста определите правильный вариант ответа.***

**14**

"Сәйдәш" мәдәният сараена чакырабыз!
5 нче февральдә мәдәният сараенда беренче тапкыр әти-әниләр һәм балалар катнашында мәдәни фестиваль узачак. Бу көнне җыр, бию, музыка уен коралларында уйнау буенча мастер-класслар һәм бәйгеләр узачак, тавышны дөрес кую буенча киңәшләр бирәчәкләр. Барлык чараларда теләгән һәр гаилә катнаша ала. Төп шарт- командада өлкән кеше һәм бала булу. Чараларда катнашу бушлай, теркәлү урында уздырыла. Фестиваль җиңүчеләрен һәм призёрларын оештыручылардан бүләкләр көтә.
Фестиваль 13.00 сәгатьтә башлана. Рәхим итегез.

**Белдерүдә нәрсә турында әйтелә?**

1) Мәдәният сараенда узачак түләүсез чаралар турында.
2) "Сәйдәш" Мәдәният сараенда узачак чарага чакыру турында.
3) Мастер-классларда өлкәннәр һәм балалар катнашуы турында.

**15**

Сатып алучылар игътибарына!
Казан шәһәренең "Франт" сәүдә үзәгендә 20 нче декабрьдән яңа бутиклар ачыла. Сез

**Бу хәбәр нәрсә турында?**

| | |
|---|---|
| үзегезгә охшаган кием-салым, аяк киемнәре, йорт кирәк-яракларын биредә таба алачаксыз. Яңа ел алдыннан туганнарыгызны һәм дусларыгызны сөендерер өчен, истәлекле һәм кирәкле бүләкләр дә биредә күп. Килегез һәм сатып алыгыз.<br>Сәүдә үзәгенең беренче катында азык-төлек, яшелчә һәм җиләк җимешләр сатып алу мөмкинлеге дә бар. Бәйрәмгә җыенсагыз, “Франт” сәүдә үзәгенә рәхим итегез!<br>Адресы: Казан шәһәре, Ю.Фучик урамы, 90 нчы йорт.<br>Белешмәләр өчен: 231-18-28. | 1) Яңа елга хәзерләнү турында.<br>2) Яңа сәүдә үзәге ачылу турында.<br>3) Сәүдә үзәгендә яңа мөмкинлекләр булдырылу турында. |

| | | |
|---|---|---|
| **16** | Сәлам, Әмир! Хәлләрең ничек? Иртәгә җыр конкурсында чыгыш ясарга син әзерме?<br>Кызганычка каршы, мин иртәгә чыгыш ясый алмаячакмын. Салкын тидердем, тамагым авырта. Температурам да бераз югары. Мин иртәгә мәктәпкә дә бара алмам инде. Дару эчеп, берничә көн дәваланырга туры киләчәк. Мин сиңа конкурста уңышлар телим. Җиңеп кайт! Мәктәбебездә синең җиңүгә өметләнәләр.<br>Конкурстан соң хәбәр бирерсең. Мин көтәчәкмен.<br>Сәлам белән дустың Кәрим. | **Электрон хатында Кәрим дустына нәрсә турында язган?**<br>1) Иртәгә җыр конкурсы булуы турында.<br>2) Үзенең авырып китүе һәм конкурста катнаша алмаячагы турында.<br>3) Әмирнең конкурска ничек әзерләнүе турында. |

***Прочитайте текст. В заданиях 17 - 20 укажите правильный вариант ответа.***

Ни өчен табигатьне сакларга кирәк? Шул турыда берничә сүз әйтик әле.

Кешеләргә өй салырга бүрәнәне, ягарга утынны, язарга кәгазьне, сулар өчен саф һаваны урман бирә. Урман — киек җәнлекләрнең һәм кош-кортларның туган йорты да.

Киң елгалар, чишмәләр, күлләр эчәргә су, үсемлекләргә дым бирәләр. Судан башка яшеллек тә, тереклек тә юк. Су — балыкларның, күп төрле җәнлекләрнең һәм кошларның төп йорты.

Урманнар янып бетсә, сулыклар кипсә, Җир йөзендә ни булыр?

Хәзер җир йөзендә куе урманнар, яшел болыннар, кыйммәтле җәнлекләр һәм кошлар, бөҗәкләр һәм үсемлекләрнең саны елдан-ел кими бара. Моны ничек туктатырга мөкин?

Табигать байлыкларын, аның гүзәллеген саклап калу өчен, безнең илебездә зур эшләр башкарыла. Шуның бер мисалы — табигатьне саклау буенча Кызыл китап булдыру.

Бу китапка аеруча игътибар белән сакларга кирәк булган җәнлекләрнең, кошларның, бөҗәкләрнең һәм үсемлекләрнең исемнәре язылган. Кызганычка каршы, китапта язулар елдан - ел арта бара, ә бу бөҗәкләр, җәнлекләр, кош-кортларның төрләре кимү турында сөйли.

Димәк, безгә табигатькә игътибарлырак булырга, кулыбыздан килгән кадәр аның яңаруына ярдәм итәргә кирәк.

(*Татар календареннан)*

**17** Урманны саклау ни өчен кирәк?
1) Ул кешегә һава, азык, ягулык, материаллар бирә.
2) Урманда җәнлекләр күп.
3) Урман - яшеллек чыганагы.

**18** Җирдәге тереклеккә иң беренче нәрсә кирәк?
1) су
2) ризык
3) кешеләр

**19** Хәзер җир йөзендә нинди үзгәрешләр бара?
1) Җирдәге тереклек төрләре елдан-ел арта.
2) Җирдәге тереклек бертөрлеләнә бара.
3) Җирдәге тереклек төрләре елдан-ел кими.

**20** Кызыл китап нәрсәгә ярдәм итә?
1) Югалып бара торган төрләрне саклап калырга.
2) Югалып бара торган төрләрне теркәп калырга.
3) Табигатьтәге үзгәрешләрне теркәп барырга.

## Раздел 3

***Прочитайте текст. В заданиях 21 – 28 определите правильный вариант ответа.***

— Бар, улым, әтиеңне (21)…. Ул ишегалдында кар көри,— диде Фәһимгә (22)… .

Өстәл өстенә ак (23) … ябылган. Һәркем алдына тәлинкә, кашык һәм чәнечке куелган. Фәһимнең әнисе икмәк (24)…, тәлинкәләргә аш бүлде.

Менә әтисе дә керде. Фәһим белән әтисе, (25)… юып, ашарга утырдылар. Фәһим кашыгын алды да ашыга-ашыга ашарга кереште.

— Нигә ул кадәр кабаланасың? (26)…! Ашыгып ашасаң, ашказаныңны бозарсың. Ашаганда, дөрес утыр, кашык, чәнечкеләрне дөрес тот. Азыкны (27) … чәйнә,— дип киңәш бирде әтисе Фәһимгә.

— Бик ашыйсым килгән иде шул, уйнарга да чыгасы бар,— диде Фәһим.

Моннан соң ул һәрвакыт (28) … сүзләрен исендә тотты һәм ашыкмыйча гына ашый торган булды.

*(Әхлак китабыннан)*

**21** 1) чакыр 2) чакыра 3) чакырды

**22** 1) әни 2) әнисе 3) әниең

**23** 1) тастымал 2) сөлге 3) ашъяулык

**24** 1) турады 2) кисте 3) өзде

**25** 1) кулларны 2) кулларга 3) кулларын

**26** 1) ашыкма 2) ашыкмагыз 3) ашык

**27** 1) яхшыдан 2) яхшылап 3) яхшыга

**28** 1) әтисенә 2) әтисен 3) әтисенең

## Раздел 4

***В заданиях 29-32 необходимо написать реплики в соответствии с заданной речевой ситуацией.***

**Сөйләм ситуациясенә туры килгән репликаларны языгыз.**

**29** Сообщите одноклассникам, что классный руководитель просил передать всем тетради по татарскому языку.

**30** Спросите у друга (подруги), какие музыкальные произведения нравятся ему (ей) больше всего и почему.

**31** Предложите старшему брату сходить послезавтра в кино, так как там будет новый фильм об инопланетянах.

**32** Предложите соседям вместе сходить на горку, чтобы покататься на лыжах.

**33** **Вы получили письмо от друга (подруги). Напишите ему (ей) письмо объемом не менее 60 слов, ответив на его (её) вопросы.**

**Для ответа на это задание используйте специальный бланк ответов.**

*... Без сыйныфташлар белән нәсел шәҗәрәләребезне ясадык һәм әти-әниләребез каршында чыгыш ясадык. Бу чарада һәр укучы катнашты. Безнең эшләр өлкәннәргә бик ошады. Иң яхшы шәҗәрәләрне без шәһәр конкурсына да җибәрдек.*
*... Ә син сыйныфташларыгыз белән нинди уртак эшләр эшлисез? ...Сезнең нинди конкурсларда катнашканыгыз бар? ...Әгәр конкурста җиңсәгез, сез нишләрсез?*

**Тыңлап аңлау биремнәре өчен текстлар**

**Прослушайте 7 коротких диалогов. В заданиях 1 - 7 укажите правильный вариант ответа. Вы услышите аудиозапись дважды.**

**Беренче сорау. Әлфия нәрсәгә ышанган?**

Камил: Кара әле, Әлфия, урамда яңгыр ява! Нинди матур! Кояш та бар, яңгыр да.

Әлфия: Әйе, һавасы да бик саф! Әнә елга өстендә салават күпере чыкты!

Камил: Әйе, син җиде төсен дә күрәсеңме?

Әлфия: Күрәм. Бик матур. Без хәзер яңгырда өйгә ничек кайтабыз инде?

Камил: Синең зонтигың бармы? Булмаса, минеке астында бергә кайтабыз.

Әлфия: Зонтигым юк шул. Бүген иртән көн кояшлы иде бит. Яңгыр ява дип радиодан да әйтмәделәр. Мин зонтик алмадым. Атналык күзәтүдә дә яңгыр юк иде.

Камил: Минем зонтик зур. Әйдә, бергә кайтабыз. Ләкин тизрәк булыйк, тиздән футбол матчы башлана. Өйгә кайтып җитәргә өлгерергә кирәк.

Әлфия: Син футбол карыйсыңмыни? Бер дә бу кызыксынуың турында әйтмәгән идең.

Камил: Минемчә, һәр ир-ат футбол карый. Әйдә, киттек.

**[2 секунд пауза]**

**Прослушайте диалог второй раз.**

[язма икенче тапкыр яңгырый]

**[2 секунд пауза]**

**Икенче сорау. Наилнең ни өчен буш вакыты юк?**

Ләйлә: Айнур, син буш вакытта нишлисең?

Наил: Мин фильмнар карыйм.

Ләйлә: Нинди фильм карыйсың? Чит ил фильмнары карыйсыңмы яки безнең илнекенме?

Наил: Мин иске комедияләр карарга яратам. Бүген “Шурик маҗаралары”н кабат карадым.

Ләйлә: Әйе, ул фильмны мин дә яратам. Син һәр көн комедияләр карыйсыңмы?

Наил: Юк инде, вакыт булганда. Кызганычка каршы, буш вакыт сирәк була.

Ләйлә: Ни өчен? Син төрле секцияләргә йөрисеңме?

Наил: Мин футболга йөрим. Безнең һәр көнне тренировкалар бар. Аннары өй эшләрен дә эшләргә кирәк. Аларны эшләп бетергәч, кино карыйсы килми инде.

**[2 секунд пауза]**
**Прослушайте диалог второй раз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый] **[2 секунд пауза]**

**Өченче сорау. Рәшит нәрсә белән мавыга?**
Әлфия: Рәшит, сезнең фатирыгыз ничә бүлмәле?
Рәшит: Өч бүлмәле.
Әлфия: Ә синең бүлмәңдә нинди җиһазлар бар?
Рәшит: Анда караватъ, компьютер өстәле бар. Китап һәм кием шкафы тора. Көй яздыру аппаратурасы бар. Идәндә кечкенә келәм.
Әлфия: Бүлмәңдә телевизор юкмыни?
Рәшит: Юк. Ул миңа кирәкми. Мин телевизор карамыйм.
Әлфия: Рәшит, син хәзер нәрсә белән шөгыльләнәсең?
Рәшит: Музыка яздырам. Киләчәктә бу өлкәдә эшлисем килә. Компьютерны да яхшы беләм.
Әлфия: Син гитарада да яхшы уйныйсың бит. Минем тыңлаганым бар.
**[2 секунд пауза]**
**Диалогны икенче тапкыр тыңлагыз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**

**Дүртенче сорау. Дуслар кая барырга булалар?**
Рәшит: Лилия, синң өй эшләрен эшләп бетердеңме инде?
Лилия: Әйе, Рәшит, кичә үк әзерләп бетердем.
Рәшит: Бүген көн бик матур. Үзе җылы, кояшлы. Велосипедта йөрергә чыгарга теләмисеңме?
Лилия: Бик телим, ләкин минем велосипедым юк.
Рәшит: Бездә сеңелемнең велосипеды бар. Әйдә аны алып торабыз.
Лилия: Мин риза. Зур рәхмәт! Ә кая барабыз?
Рәшит: Паркка барыйк. Анда юл яхшы.
Лилия: Яхшы. Алсуны да чакырыйк. Аның да урамда йөрисе килгән иде.
Рәшит: Чакыр. Ничәдә очрашабыз?
Лилия: Унбиш минуттан мин әзер булам.
Рәшит: Яхшы, мин сине өченче яртыда бишенче йорт янында көтәм. Алсу да шунда килсен.

**[2 секунд пауза]**
**Прослушайте диалог второй раз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**

**Бишенче сорау. Сәлимә ни өчен мультфильмны кунак бүлмәсендә карамый?**

Сәлимә: Мансур абый, син телевизор карыйсыңмы?

Мансур: Әлбәттә, Сәлимә. Мин һәр көнне “Яңалыклар” һәм “Хәбәрләр” тапшыруларын карап барам. “ Ак Барс” уеннарын да калдырмыйм. Ник сорыйсың?

Сәлимә: Минем “ШАЯН ТВ” каналында яраткан мультфильмым башлана. Миңа аны карарга мөмкинме?

Мансур: Әлбәттә, мөмкин. Ни өчен дәү әниең белән кунак бүлмәсендә карамыйсың?

Сәлимә: Анда дәү әни сериал карый. Мультфильмны сериал беткәч кенә карарга рөхсәт итә. Ул вакытта мультфильм да бетә бит.

Мансур: Әйе шул, дөрес. Ә өй эшләреңне әзерләп бетердеңме соң?

Сәлимә: Бетердем. Мультфильмны карыймчы.

Мансур: Болай сорагач, ничек каратмыйсың инде. Кара.

Сәлимә: Рәхмәт, абыем.

**[2 секунд пауза]**

**Диалогны икенче тапкыр тыңлагыз.**

[язма икенче тапкыр яңгырый]

**[2 секунд пауза]**

**Алтынчы сорау. Рамил нәрсә сорый?**

Әдилә: Рамил, кара әле, бу түбәтәй сиңа ошыймы?

Рамил: Әйе, Әдилә, матур. Кайдан сатып алдың?

Әдилә: Мин аны сатып алмадым, үзем тектем. Аны әтиемә туган көненә бүләк итәргә телим.

Рамил: Бик яхшы бүләк булачак! Ә сине түбәтәй тегәргә кем өйрәтте?

Әдилә. Интернеттан өйрәндем.

Рамил: Бик яхшы килеп чыккан. Миңа да бер түбәтәй тегеп бир әле.

Әдилә: Ярар, туган көнеңә әзерләрмен. Сиңа чигүле түбәтәй ошыймы, чигүсезме?

Рамил: Миңа икесе дә ошый. Чигүлесе тагын да матуррак буладыр инде.

Әдилә: Ярар. Тырышырмын.

**[2 секунд пауза]**

**Прослушайте диалог второй раз.**

[язма икенче тапкыр яңгырый]

**[2 секунд пауза]**

**Җиденче сорау. Айрат бабасыннан нәрсәгә өйрәнгән?**

Вәлия: Сәлам, Айрат! Авылдан кайчан килдең?

Айрат: Кичә, Вәлия. Каникул бетә бит, укулар башлана.

Вәлия: Әйе. Син ничек ял иттең?

Айрат: Яхшы ял иттем. Яңа дуслар таптым, урманга, күлгә бардым.

Вәлия:Урманга кем белән йөрдең?

Айрат: Бабай белән. Ул элек урманчы булган. Урманны бик ярата һәм белә. Мине дә агачларны танырга, урманда адашмаска өйрәтте.

Вәлия: Айрат, син урманда нишләдең?

Айрат: Җиләк һәм дару үләннәре җыйдым. Саф һава суларга бардым.

Вәлия: Әбиең дә сезнең белән урманга йөрдеме?

Айрат: Юк. Ул өйдә генә торды. Бакчада эшләде.

Вәлия: Ә син аңа булыштыңмы?

Айрат: Әлбәттә. Яшелчәләргә су сиптем, чүп утадым.

Вәлия: Сиңа ял ошадымы соң?

Айрат: Бик ошады.

**[2 секунд пауза]**

**Прослушайте диалог второй раз.**

[язма икенче тапкыр яңгырый]

**[2 секунд пауза]**

***Прослушайте разговор двух друзей. Определите, какие из приведенных утверждений 8 - 13 соответствуют содержанию текста, а какие – не соответствуют. Вы услышите аудиозапись дважды.***

**[пауза 20 секунд]**

Салават: Миләүшә, сәлам!

Миләүшә: Сәлам, Салават! Сине бер атна күрмәдем. Син конкурста катнаштыңмы?

Салават: Юк. Авырдым, салкын тиде, тамагым авыртты.

Миләүшә: Хастаханәдә идеңме?

Салават: Юк. Табибны өйгә чакырттык. Әйе. Температурам югары булды.

Миләүшә: Табиб нәрсә әйтте? Дарулар яздымы?

Салават: Әйе, дарулар, үләннәр дә эчәргә кушты.

Миләүшә: Син даруларны эчеп бетердеңме инде?

Салават: Юк әле. Тагын ике көн эчәсем бар. Хәлем яхшыргач, мәктәпкә килдем. Дәресләрем күп кала бит.

Миләүшә: Тулысынча терелмәгән килеш мәктәпкә килергә ярамый. Тагын авырып китәргә мөмкин. Сиңа хәзер сакланырга кирәк.

Салават: Әйе, беләм. Ләкин миңа табиб рөхсәт итте. Физкультура дәресенә генә кермәскә кушты.

Миләүшә: Ярар. Дәрестә нидер аңлашылмаса, сорарсың. Без инде математикадан 3 яңа тема үттек.

Салават: Әйе, миңа синең ярдәм кирәк булачак, Миләүшә.

Миләүшә: Ярдәм итәрмен.

Салават: Рәхмәт, күрше.

**[2 секунд пауза]**

**Прослушайте диалог второй раз.**

[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**

**Внесите ответы в бланк ответов.**

## ҖАВАПЛАР

| Биремнең номеры | Дөрес җавап |
|---|---|
| 1 | 3 |
| 2 | 1 |
| 3 | 2 |
| 4 | 1 |
| 5 | 3 |
| 6 | 2 |
| 7 | 3 |
| 8 | 1 |
| 9 | 2 |
| 10 | 1 |
| 11 | 2 |
| 12 | 2 |
| 13 | 1 |
| 14 | 2 |
| 15 | 3 |
| 16 | 2 |
| 17 | 1 |
| 18 | 1 |
| 19 | 3 |
| 20 | 2 |
| 21 | 1 |
| 22 | 2 |
| 23 | 3 |
| 24 | 2 |
| 25 | 3 |
| 26 | 1 |
| 27 | 2 |
| 28 | 3 |

## 10 нчы вариант

### Раздел 1

***Прослушайте 7 коротких диалогов. В заданиях 1 - 7 укажите правильный вариант ответа. Вы услышите аудиозапись дважды.***

**1** **Айдар нәрсәгә борчыла?**

1) йорт хайваннары булмаганга
2) песие картайганга
3) күрше песие ашамаганга

**2** **Дуслар нәрсә турында сөйләшәләр?**

1) мәктәп ашханәләре турында
2) сыйныфташлары турында
3) мәктәпкә бару турында

**3** **Фаилне нәрсә борчый?**

1) туганы белән мөнәсәбәте
2) Фәниянең туганнары
3) дусты белән аралашу

**4** **Гомәр нинди бүләк алачак ?**

1) курчак
2) күлмәк
3) уенчык

**5** **Фәридә бу елларда нишләячәк?**

1) тимеряакта шуарга барачак
2) ул әле белми
3) йөзү буенча ярышта катнашачак

**6** **Гөлшат кайда яши?**

1) шәһәрдә
2) төп йортта
3) күрше авылда

**7** **Дания кая барырга ризалаша?**

1) китапханәгә
2) музыка мәктәбенә
3) кибеткә

***Прослушайте разговор двух друзей. Определите, какие из приведенных утверждений 8 - 13 соответствуют содержанию текста (1), а какие – не соответствуют (2). Вы услышите аудиозапись дважды.***

**8** Мәрзия Казанда бер көн була.

1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**9** Марат шәһәрдә истәлекле урыннар күплеге турында әйтә.

1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**10** Мәрзия шәһәр үзәге белән кызыксына.

1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**11** Марат шәһәр үзәгенә автобус йөрүе турында әйтә.

1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**12** Мәрзия Милли музейга барырга тели.

1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**13** Марат музейның Кремль каршында булуын хәбәр итә.

1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

## Раздел 2

***Прочитайте тексты в заданиях 14 – 16. После каждого текста определите правильный вариант ответа.***

**14**

Хөрмәтле югары сыйныф укучылары, укытучылар!
Сезне 13 нче май көнне башлангыч сыйныф укучылары тарафыннан әзерләнгән концертка чакырабыз. Концерт беренче озын тәнәфес вакытында 11 сәгать 15 минутта башлана.
Сез милли биюләр карарсыз, моңлы җырлар тыңларсыз, танылган татар шагыйрьләренең шигырьләрен ишетерсез. Концертта республика конкурслары призеры Марат Салиховның баянда уйнавын да күрерсез.
Чара мәктәпнең актлар залында узачак. Концертыбызга рәхим итегез!

**Белдерүдә нәрсә турында әйтелә?**

1) Мәктәп күләмендә озачак чара турында.
2) Укучыларны озын тәнәфестә конкурска чакыру турында.
3) Республика конкурслары призеры Марат Салихов концертына чакыру турында.

| | | |
|---|---|---|
| **15** | 3 -5 нче сыйныф укучылары игътибарына!<br>Мәктәптә гитарада уйнарга өйрәтү түгәрәге эшли башлаячак. Түгәрәк атнага ике тапкыр дүшәмбе һәм җомга көннәрендә сәгать 15.00 дән 16.30 га кадәр үткәреләчәк.<br>Гитарада уйнау түгәрәгенә йөрергә теләүчеләрне 15 нче сентябрьдә сәгать бердә 214 нче кабинетта көтеп калабыз. Үзегез белән туу турында таныклыгыгызның күчермәсен алып килергә кирәк.<br>Белешмәләр өчен телефон: 231-18-28. | **Бу хәбәр нәрсә турында?**<br>1) Мәктәптә гитарада уйнау түгәрәге эшләве турында.<br>2) Гитарада уйнарга өйрәнүчеләрне түгәрәккә чакыру турында.<br>3) Гитарада уйнау түгәрәгенә йөрүчеләргә туу турында таныклыкның күчермәсен алып килергә кирәклеге турында. |

| | | |
|---|---|---|
| **16** | Хәерле көн, Әминә! Хәлләрең әйбәтме? Шахмат ярышы ничек үтте?<br>Без кичә бию төркемебез белән Самарадан кайттык. Анда милли биюләр конкурсында катнаштык, лауреат булдык. Конкурс безгә бик ошады. Анда Россиянең төрле төбәкләреннән милли бию коллективлары килгән иде. Без татар һәм рус биюләрен башкардык. Башка төркемнәрнең грузин, чечен, удмурт, мари, башкорт һ.б. халык биюләрен башкаруларын карадык. Бик көчле коллективлар бар иде. Безгә конкурс ошады. Синең шахмат турниры ничек үтте? Финалга чыга алдыңмы? Тагын кайсы шәһәрләрдән укучылар бар иде? Миңа җавап яз, көтәм.<br>Сәлам белән дустың Кәримә. | **Электрон хатында Кәримә дустына нәрсә турында язган?**<br>1) Шахмат турнирының ничек үтүе турында.<br>2) Самарага кемнәр баруы турында.<br>3) Бию коллективы белән конкурста катнашуы турында. |

***Прочитайте текст. В заданиях 17 - 20 укажите правильный вариант ответа.***

Колибри - дөньяда иң кечкенә һәм, мөгаен, иң матур коштыртыр.Гадәттә, алар гади шөпшә зурлыгында була һәм авырлыгы бары тик бер ярым - ике граммга гына җитә. Карлыгач зурлыгындагы иң зур колибрилар баһадирлар дип йөртеләләр. Бу кошлар бик ачык төстә һәм яктылык ничек төшүгә карап, күз алдында ук үзгәрүчән булалар.

Кошларның башларындагы вак каурыйлар кайчагында озын булып күпереп тора, ә кайбер төрләренең койрыклары бик озын яки каурыйлары төрле формада була.

Колибрилар, бертуктаусыз очып йөргәнгә, бик күп энергия сарыф итәләр, шуның өчен көн буена үз авырлыкларыннан ике тапкыр күбрәк ашыйлар. Колибрилар ашамыйча озак тора алмыйлар.

Ана колибрилар агач ботакларында җыйнак кына оялар ясыйлар. Вак төрләрнең оялары чикләвек кабыгы кадәр генә була. Ана колибри шундый ояга авырлыгы нибары 2—3 миллиграмм гына булган ике ак йомырка сала. Алардан бик кечкенә кошчыклар шәрә һәм сукыр булып туа, ана колибри аларны ояда өч атна буе ашатып яши.

Матур канатларына кызыгып, кешеләр колибриларны бик озак вакытлар буена юк итә килгәннәр. Шуның аркасында күп төрләре инде сирәгәйгән. Табигатьне саклау буенча халыкара оешмалар колибриларны киләчәктә юкка чыгудан сакларга тырышалар.

*( «Кем ул? Нәрсә ул?» китабыннан)*

**17** Гади колибриның зурлыгы күпме?

1) Шөпшәдән бераз гына зуррак.
2) Шөпшәдән кечерәк.
3) Шөпшә зурлыгында.

**18** Кошларның нинди үзлекләре бар?

1) Кошлар аксыл төстә генә булалар.
2) Аларның каурыйларының төсләре үзгәрә.
3) Күп кошлар кара төскә генә керәләр.

**19** Колибрилар ничек туклананалар?

1) Алар бик еш ашыйлар.
2) Алар бик аз ашыйлар.
3) Алар ашамыйлар диярлек.

**20** Ни өчен колибриларны сакларга кирәк?

1) Кешеләр, каурыйларына кызыгып, аларны тоталар.
2) Алар табигатьтә сирәк калганнар.
3) Аларны зоопаркларда гына күрергә мөмкин.

## Раздел 3

***Прочитайте текст. В заданиях 21 – 28 определите правильный вариант ответа.***

Бервакыт бер бәләкәй малай (21)… адашып калган. Ул юлны озак (22) …, әмма таба алмаган. Кич көтмәгәндә, аңа бер карт (23) …. Шатлыгыннан малай аны кочаклап алган. «Мин адаштым,— дигән ул,—

миңа урманда бик тә куркыныч. Минем (24) … килә. Үтенеп сорыйм, ярдәм итегез миңа».

Бабай сабыйга карап алган да (25)… чайкаган һәм китеп барган.

Малай аның артыннан йөгергән һәм бертуктаусыз (26) …: «Минем ашыйсым килә, минем ашыйсым килә…» Ләкин бабай бу юлы да аңа ярдәм күрсәтмәгән.

Бераздан малай картның ни эшләгәнен күзәтә башлаган: бабай җиләк (27) … һәм агачтан чикләвекләр өзгән. Малай да карт эшләгәннәрне кабатларга керешкән. Шулай итеп ул тамагын туйдырган. Бераз хәл алгач, өйгә кайтыр (28) … да тапкан.

Бабай ялгызың гына кара урманда калганда нишләргә кирәклеген белгән, һәм малай да аңардан күп нәрсәгә өйрәнгән.

*( «Әхлак дәресләре» китабыннан)*

**21** 1) урманга 2) урманда 3) урманны

**22** 1) эзләгәч 2) эзләргә 3) эзләгән

**23** 1) очраган 2) очраткан 3) күргән

**24** 1) ашыйсың 2) ашыйсыбыз 3) ашыйсым

**25** 1) башы 2) башны 3) башын

**26** 1) кабатлаган 2) калган 3) караган

**27** 1) җыя 2) җыйган 3) җыячак

**28** 1) юлны 2) юлда 3) юлның

## Раздел 4

***В заданиях 29-32 необходимо написать реплики в соответствии с заданной речевой ситуацией.***

**Сөйләм ситуациясенә туры килгән репликаларны языгыз.**

**29** Сообщите одноклассникам, что вчера команда вашего класса победила в шахматном турнире и вас наградили грамотами.

**30** Спросите у друга (подруги), какие стихи он(а) читает и какие авторы нравятся ему (ей) больше.

**31** Предложите тете сходить вместе в торговый центр и купить подарок маме на день рождения.

**32** Посоветуйте своим родителям сходить в кинотеатр и посмотреть новый триллер.

**33** **Вы получили письмо от друга (подруги). Напишите ему (ей) письмо объемом не менее 60 слов, ответив на его (её) вопросы. Для ответа на это задание используйте специальный бланк ответов.**

*... Мин көзге табигатьне бик яратам. Миңа агач яфракларының төрле төскә керүе, җилдә еракларга кадәр очуы һәм туктаусыз вак яңгыр сибәләве ошый. Мондый көннәрдә мин тәрәзәдән карап торырга һәм рәсем ясарга яратам.*
*... Ә сиңа кайсы ел фасылы ошый? ... Көзге кичләрдә, гадәттә, син нишлисең? ... Ә кышкы ялларыңны кайда үткәрергә яратасың.*

## Тыңлап аңлау биремнәре өчен текстлар

**Прослушайте 7 коротких диалогов. В заданиях 1 - 7 укажите правильный вариант ответа. Вы услышите аудиозапись дважды.**

**Беренче сорау. Айдар нәрсәгә борчыла?**

Айдар: Хәлләр ничек, Ләйсән?

Ләйсән: Яхшы, рәхмәт, Айдар!

Айдар: Ләйсән, сезнең йорт хайваннарыгыз бармы?

Ләйсән: Әйе, минем песием һәм ташбакам бар.

Айдар: Алар яшьме әле?

Ләйсән: Мыраужан карт инде, аңа 11 яшь. Ул бик йомшак һәм ягымлы. Кечкенә вакытта туплар, уенчыклар белән уйнарга ярата иде, хәзер безгә сырпаланып ята..

Айдар: Ә ул нәрсә ашый?

Ләйсән: Балык, сөт һәм ит ашый. Син песи алырга булдыңмы әллә?

Айдар: Юк. Мин алар белән бик “дус “ түгел. Күршеләр ялга киттеләр, песиләрен безгә калдырдылар. Ә ул кибет ризыгын ашамый. Шуңа сорыйм.

Ләйсән: Син аңа сөт һәм балык биреп кара, минемчә, барлык песиләр дә балык яраталар.

Айдар: Сөт бирдем, эчми. Бүген балык биреп карармын инде. Минемчә, ул хуҗаларын сагына.

Ләйсән: Ә алар кайчан кайтачалар?

Айдар: Бер айдан соң.

**[2 секунд пауза]**
**Прослушайте диалог второй раз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**

**Икенче сорау. Дуслар нәрсә турында сөйләшәләр?**

Булат: Камилә, сезнең сыйныфта ничә укучы бар?

Камилә: 26. Без - 12 малай һәм 14 кыз.

Булат: Сез дусмы? Тәнәфесләрдә нишлисез?

Камилә: Без шахмат уйныйбыз, ял итәбез. Өченче дәрестән соң ашханәдә көндезге ашны ашыйбыз.

Булат: Безнең ашханәдә пешекче апалар бик тәмле пешерәләр. Мин, аеруча, тавык ите белән бәрәңге яратып ашыйм. Кесәл дә бик, тәмле.

Камилә: Ә синең сыйныф дусмы соң?

Булат: Әлбәттә, Камилә. Без сыйныфта 32 кеше. Күбебез балалар бакчасыннан ук танышлар. Хәзер бер гимназиядә, бер сыйныфта укыйбыз. Бигрәк тә авыр өй эшләрен бергә әзерләргә яратабыз, бергә киногa, театрга йөрибез, паркта ял итәбез.

Камилә: Шәп! Ә тәнәфестә нишлисез?

Булат: Сөйләшеп утырабыз.

Камилә: Һәр тәнәфестәме?

Булат: Ашханәгә барасы булмаса, әйе.

**[2 секунд пауза]**
**Прослушайте диалог второй раз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый] **[2 секунд пауза]**
**Өченче сорау. Фаилне нәрсә борчый?**

**4.**Фаил Хәерле көн, Фәния! Без сине бик көттек.

Фәния: Исәнме, Фаил! Сине күрүемә шатмын! Хәлләрегез ничек?

Фаил Рәхмәт, яхшы. Фәния, син абыең һәм энең белән дусмы?

Фәния: Мин аларны яратам. Без дус яшибез. Беләсеңме, күптән түгел энем белән театрга спектальгә бардык. Анда Шүрәле турында тамаша карадык. Антракт вакытында артистлар белән фотога төштек. Шундый күңелле булды!

Фаил: Ә абыең белән сез дусмы?

Фәния: Әлбәттә. Абыем быел мәктәпне тамамлый. Ул миңа һәрчак ярдәм итә. Без бергә әти-әнигә булышабыз. Ә син апаң белән дусмы?

Фаил: Без бер-беребезне аңламыйбыз. Ул мине һәрвакыт өйрәтә. Ә мин өйрәткәнне яратмыйм. Мин апамны яратам, ләкин аның белән һәрвакыт килешмим.

Фәния: Зурлар яхшыга өйрәтәләр инде. Аны да аңларга тырыш. Ул начарга әйтми бит.

Фаил: Беләм, кызлар һәрвакыт кызларны яклыйлар инде алар. Ярар, аңларга тырышырмын...

**[2 секунд пауза]**
**Диалогны икенче тапкыр тыңлагыз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**

**Дүртенче сорау. Гомәр нинди бүләк алачак ?**

Гөлия: Дамир, мин сине туган көнгә чакырам. Иртәгә кичке 7 дә безгә кил.

Гомәр: Синең туган көнең бер айдан гына бит. Кемнең туган көне?

Гөлия: Сеңелемнеке. Асиягә 4 яшь тула. Ул сине бик ярата бит.

Гомәр: Ярар, килермен. Мин дә Асияне яратам. Ул бик кызык кыз. Аңа нинди бүләк алыйм? Мин курчаклар, күлмәкләр ала белмим, кызларга бүләк алганым юк. Аңа нәрсә ошый, Гөлия?

Гөлия: Бүләкне сорап алмыйлар инде, ул сер булырга тиеш. Бүләкне чын күңелдән сайларга кирәк, шул вакытта ул кирәкле һәм истәлекле булачак.

Гомәр: Ә мин нинди бүләк алырга белмим...

Гөлия: Асия кечкенә бит әле, аңа уенчыклар ошый. Син биргән уенчыкка ул сөенәчәк.

Гомәр: Чынлапмы?

Гөлия: Әлбәттә, мин аны яхшы беләм.

Гомәр: Ярый, киңәшең өчен рәхмәт.

Гөлия: Иртәгәгә кадәр! Сау бул!

Гомәр: Очрашырбыз!

**[2 секунд пауза]**
**Прослушайте диалог второй раз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**

**Бишенче сорау. Фәридә бу ялларда нишләячәк?**

Фәрит: Фәридә, бу ял көннәрендә нишләячәксез?

Фәридә: Гадәттәгечә. Әтием ял көннәрендә балыкка йөрергә, телевизордан хоккей карарга ярата. Яраткан командасы җиңү яуласа шатлана. Бу атнада да шулай булыр.

Фәрит: Ә әниең нишләр, Фәридә?

Фәридә: Мин белмим. Ләкин ул ял көннәрендә китап укырга, кайвакыт музыка тыңларга ярата. Кайвакыт без бергә шугалакка тимераякта шуарга барабыз. Бу яллар турында сөйләшмәдек әле. Фәрит, ә син ял көннәрен, буш вакытыңны ничек уздырасың?

Фәрит: Мин шахмат һәм теннис уйнарга яратам.

Фәридә: Син бассейнга да йөрисең бит. Йөзәргә еш барасыңмы? Көнгә ничә сәгать йөзәсең?

Фәрит: Атна саен җомга һәм якшәмбе көнне бассейнга барам. Бер сәгать йөзәм.

Фәридә:Фәрит, син ярышларда катнашасызмы?

Фәрит: Әйе, катнашам. Йөзү буенча шәһәр, республика һәм төбәкара ярышларда катнаштым. Без Әлмәт, Бөгелмә, Лениногорск шәһәрләрендә ярышларда булдык. Призлы урыннарым да бар.

**[2 секунд пауза]**

**Диалогны икенче тапкыр тыңлагыз.**

[язма икенче тапкыр яңгырый]

**[2 секунд пауза]**

**Алтынчы сорау. Гөлшат кайда яши?**

Таһир: Гөлшат, син Сабан туен көтәсеңме?

Гөлшат: Әйе, Таһир. Мин аны бик көтәм. Без Сабан туена тәмле бәлешләр, өчпочмаклар пешерәбез, чөнки бәйрәмгә шәһәрдән, күрше авыллардан туганнарыбыз кайтачак. Гаиләбез һәр ел Сабан туе көннәрендә авылда төп йортта җыела.

Таһир: Бәйрәм ничек үтә?

Гөлшат: Сабан туе матур урман аланында, яшел болында уза. Бөтен авыл халкы мәйданда җыела. Бу бәйрәмдә картлар да, яшьләр дә, балалар да катнаша. Һәр җирдә җырлар, баян тавышлары яңгырый.

Таһир: Син ул көнне нишлисең, ничек бәйрәм итәсең? Сиңа Сабан туенда нинди ярышлар ошый?

Гөлшат: Сабан туенда төрле милли уеннар: көрәш, ат чабышы, йөгерү, күзне бәйләп чүлмәк вату кебек уеннар оештырыла. Ә төп ярыш – татарча көрәш. Миңа бигрәк тә көрәш ошый, чөнки минем әтием - көрәшче. Сабан туенда без һәрвакыт әтием өчен җанатабыз. Әтиемнең авылда батыр булып калганы да бар. Гомумән, Сабан туенда һәркемгә күңелле.

.

**[2 секунд пауза]**

**Прослушайте диалог второй раз.**

[язма икенче тапкыр яңгырый]

**[2 секунд пауза]**

**Җиденче сорау. Дания кая барырга ризалаша?**

Идрис: Дания, минем белән барырга теләмисеңме?

Дания: Ә син кая барасың? Миңа музыка мәктәбенә кереп чыгарга кирәк, ноталарым калган.

Идрис: Яңа китапханәгә барасы идем. Минем анда булганым юк. Бик матур дип әйттеләр.

Дания: Мин анда булдым инде. Чыннан да, анда бар да бик матур һәм уңайлы. Без анда автобуста барабызмы, җәяүме?

Идрис: Җәяү барырга да мөмкин. Бүген һава торышы әйбәт.

Дания: Мин риза. Әмма башта ноталарны гына алып чыгам. Мине 5 минут көтеп торчы.

Идрис: Ярар. Мин кибеткә кереп чыгам. Бик нык эчәсем килде, су алырга кирәк. Сиңа да алыйммы?

Дания: Юк, рәхмәт!

**[2 секунд пауза]**
**Прослушайте диалог второй раз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**

***Прослушайте разговор двух друзей. Определите, какие из приведенных утверждений 8 - 13 соответствуют содержанию текста, а какие – не соответствуют. Вы услышите аудиозапись дважды.***

**[пауза 20 секунд]**

Мәрзия: Марат, сезнең шәһәрдә тарихи урыннар, музейлар бармы? Мин тарих белән кызыксынам. Самолетка кадәр бер тәүлек вакытым бар, мин кая бара алам?

Марат: Казанда музейлар да күп. Шәһәр үзәгендә күренекле татар шагыйрьләре Г. Тукай, М. Җәлил музейлары, Татарстанның Милли музее бар. Аның каршында ук Кремль урнашкан. Кремль янында Муса Җәлилгә һәйкәлне дә күрерсең. Җиде катлы Сөембикә манарасы да Кремль территориясендә. Анда Эрмитаж филиалы да бар.

Мәрзия: Күп икән... Миңа бер тәүлек җитмәскә дә мөмкин.

Марат: Әйе, Казанда музейлар бик күп. Шәһәр үзәгендә тагын әллә никадәр музей бар. Бер көн җитмәсә, Казанга тагын килерсең.

Мәрзия: Әйе, килешәм. Гафу ит, ә Кремльгә кадәр ничәнче автобус яки трамвай йөри, яисә җәяү барып буламы?

Марат: Юк, кунакханәдән җәяү ерак булачак. Казан Кремленә метрода бару бик уңайлы. Җиңү Проспектында утырасың да бишенче тукталышта төшәсең.

Мәрзия: Ә нинди тукталышта төшәргә кирәк?

Марат: “Кремль” станциясендә чыксаң, уңайлы булачак.

Мәрзия: Минем Милли музейны да күрәсем килә.

Марат: Музей Казан Кремленең Спас манарасы каршында урнашкан. Метродан чыккач та уң якта – музей, сул якта Кремль булачак.

Мәрзия: Бик уңайлы икән. Музейның эш вакытын һәм билет бәясен белмисеңме?

Марат: Музей сәгать уннан алтыга кадәр эшли. Билет бәясе 150 сум.

Мәрзия: Рәхмәт! Ул иртәгә ял итмиме?
Марат: Юк. Аның ял көне – дүшәмбе.

**[2 секунд пауза]**
**Прослушайте диалог второй раз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**

**Внесите ответы в бланк ответов.**

## ҖАВАПЛАР

| Биремнең номеры | Дөрес җавап |
|---|---|
| 1 | 3 |
| 2 | 2 |
| 3 | 1 |
| 4 | 3 |
| 5 | 2 |
| 6 | 2 |
| 7 | 1 |
| 8 | 1 |
| 9 | 1 |
| 10 | 2 |
| 11 | 2 |
| 12 | 1 |
| 13 | 2 |
| 14 | 1 |
| 15 | 2 |
| 16 | 3 |
| 17 | 3 |
| 18 | 2 |
| 19 | 1 |
| 20 | 2 |
| 21 | 2 |
| 22 | 3 |
| 23 | 1 |
| 24 | 3 |
| 25 | 3 |
| 26 | 1 |
| 27 | 2 |
| 28 | 1 |

**Татар теле буенча имтихан эшен бәяләү системасы**

1-28 нче биремнәрдә дөрес күрсәтелгән һәр җавап 1 балл белән бәяләнә. Җаваплар биремнәрне үтәү күрсәтмәсендәгечә язылган булса һәм дөрес җавап үрнәге белән тулысынча туры килсә, бирем дөрес үтәлгән дип санала.

**29-32 нче биремнәрне бәяләү критерийлары**

Сөйләм ситуациясенә караган репликалар язу. 29-32 нче биремнәр максималь 2 балл белән бәяләнә.

*1 нче таблица*

| *№* | *Бәяләү критерийлары* | *Баллар* |
|---|---|---|
| *I* | *Язылган текстның эчтәлеге* | |
| К1 | Сөйләм ситуациясенә караган репликаны формалаштыру | |
| | Имтихан бирүче, сөйләм ситуациясенә караган репликаны аңлап, җавабын дөрес формалаштырган. Коммуникатив бурыч төгәл үтәлгән.<br>Фактик хаталар юк. | 1 |
| | Имтихан бирүче сөйләм ситуациясенә караган репликаны дөрес формалаштырмаган.<br>***Яки*** Сөйләм ситуациясенә караган реплика өлешчә генә формалаштырылган<br>***Яки*** дөрес формалаштырмаган.<br>***Яки*** Фактик хаталар бар.<br>***Яки*** Имтихан **бирүче башка сөйләм ситуациясенә караган реплика язган**. | 0 |
| *II* | *Грамоталылык* | |
| К2 | Орфография һәм сөйләм нормаларының үтәлеше | |
| | Репликада орфографиягә тел нормаларының үтәлешенә караган (грамматик, орфографик, стилистик. пунктуацион) хаталар юк.<br>***Һәм/ яки*** төрле нормаларга караган 2 хата бар. | 1 |
| | Репликада тел нормаларының үтәлешенә караган 3 яки күбрәк хата бар. | 0 |

| | | |
|---|---|---|
| | ***Яки*** Имтихан **бирүче башка сөйләм ситуациясенә караган реплика язган**. | |
| Язма эш өчен максималь балл | | 2 |

**33 нче биремне бәяләү критерийлары**

**Шәхси хат язу биремен бәяләү критерийлары**

*2 нче таблица*

| К | Бәяләү критерийлары | 3 балл | 2 балл | 1 балл | 0 балл |
|---|---|---|---|---|---|
| К1 | Коммуникатив бурычны үтәү | ***Эш тулысынча башкарылган:*** 3 сорауга да тулы җавап бирелгән. Мөрәҗәгать итү, саубуллашу һәм имзалау фразалары дөрес сайланган. Алынган хатка рәхмәт белдерелгән | ***Эш башкарылган:*** 3 сорауга да җавап бирелгән, әмма берсенә бирелгән җавап тулы түгел. Хат стилен бозган 1-2 төгәлсезлек бар ***һәм/яки*** алынган хатка рәхмәт белдерелмәгән | ***Эш өлешчә башкарылган***: 2 сорауга гомуми җавап бирелгән, әмма 1 сорауга бирелгән җавап тулы түгел ***яки*** бер сорауга гомумән җавап юк. Хат стилен бозган 3 яки күбрәк төгәлсезлек бар, итагатьлелек формалары сакланмаган | ***Эш башкарылмаган:*** 2 сорауга җавап бирелмәгән ***яки*** текстның күләме тулмый |
| К2 | Текстны оештыру | | Текст логик эзлеклелектә төзелгән һәм абзацларга бүленештә хаталар юк; тел чаралары дөрес | Текст, гомумән алганда, логик эзлеклелектә төзелгән, ләкин логик бәйләнешләр | Текст төзелешендә логик эзлеклелек сакланмаган; язма текст |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | кулланылган; хатның төзелеше язма этикет нормаларына туры килә | дә ***һәм /яки*** абзацларга бүленештә ***яки*** хатның төзелешендә 1-2 төгәлсезлек бар | төзелешендә 3 яки күбрәк хата бар, ***яки*** хатның төзелеше язма этикет нормаларына туры килми. |
| К3 | Текстның лексик-грамматик төзелеше | Коммуникатив бурычны үтәү өчен кирәк булган төрле лексик һәм грамматик чаралар файдаланылган (текстны аңлауга зыян китермәгән 1-2 төгәлсезлек рөхсәт ителә) | Текстны аңлауга зыян китермәгән тел чараларына караган хаталар бар (3-4 тупас булмаган хата рөхсәт ителә) ***яки*** тел хаталары юк, ләкин артык гади лексик һәм грамматик чаралар кулланылган | Текстны аңлауга зыян китермәгән тел чараларына караган хаталар бар (5-6 тупас булмаган хата рөхсәт ителә) ***һәм /яки*** текстны аңлауга зыян китерә торган 1-2 грамматик хата бар | Текстны аңлауга зыян китерә торган хаталар 6 дан күбрәк |
| К4 | Орфография һәм пунктуация | | Орфографик һәм пунктуацион хаталар юк, **яки** текст эчтәлеген аңлауга зыян китерми торган 1-2 хата бар | Текст эчтәлеген аңлауга зыян китерми торган 3-4 орфографик һәм пунктуацион хата бар | Текст эчтәлеген аңлауга зыян китерә торган орфографик һәм пунктуацион хаталар 4 тән күбрәк |

Шәхси хат язу биреме К1-К4 критерийлары буенча тикшерелә. Максималь **10 балл** алырга мөмкин.

Текстның эчтәлеге биремгә туры килмәсә (язма хат характерында булмаса, **тәкъдим ителгән сорауларга җавап урынына башка мәгълүмат язылса**, тәкъдим ителгән хат күчереп кенә язылса) бу бирем өчен 0 балл куела.

Хатның күләме 3**0** сүздән ким булса, К3 һәм К4 критерийлары буенча максималь балл куелмый.

Эшнең күләмен билгеләгәндә, беренче сүздән алып соңгысына кадәр (шулай ук адрес, язылу вакыты, имза да) исәпкә алына. **Хатта укучы үзенең чын исемен, адресын күрсәткән очракта эш тикшерелми.**

**Имтихан эше өчен түбәндәге билгеләр куела:**

0 - 12 балл – «2» ле билгесе;

13 - 22 балл – «3» ле билгесе;

23 - 33 балл – «4» ле билгесе. Искәрмә: бу очракта укучының тыңлап аңлау биремнәре өчен (1-13 нче биремнәр) баллары 7 дән кимрәк булмаска тиеш. Әгәр укучының тыңлап аңлау биремнәре өчен баллары 7 дән кимрәк булса, «3» ле билгесе куела.

34 - 46 балл – «5» ле билгесе. Искәрмә: бу очракта укучының тыңлап аңлау биремнәре өчен баллары 10 нан кимрәк булмаска тиеш. Әгәр укучының тыңлап аңлау биремнәре өчен баллары 10 нан кимрәк булса, «4» ле билгесе куела.